**Ф. В. Хәзрәтова, З. Г. Шәрәфетдинова,**
**И. Җ. Хәбибуллина**

# Туган телдә сөйләшәбез

**Балалар бакчасында татар телендә тәрбия һәм белем бирү**
**(*беренче кече яшьтәгеләр төркеме*)**

Тәрбиячеләр өчен методик кулланма

*Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан рөхсәт ителгән*

КАЗАН • ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ • 2012

УДК 373.3/4:811.512.145*00
ББК 74.102:81.2Тат
Х84

Рецензентлары:
*Д. Ш. Гыйльманов,* педагогика фәннәре кандидаты, Яр Чаллы педагогика институты доценты;
*Л.И.Мөхәммәтдинова*, Яр Чаллы шәһәренең 39 нчы балалар бакчасы мөдире;
*Р. Р. Бикиева*, Яр Чаллы шәһәренең 26 нчы балалар бакчасы өлкән тәрбиячесе

*Охраняется действующим законодательством об авторских и смежных правах (Гражданский кодекс РФ, ч. 4, гл. 70). Воспроизведение всей книги или её части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.*

**Хәзрәтова, Ф. В.**
Х84 Туган телдә сөйләшәбез. Балалар бакчасында татар телендә тәрбия һәм белем бирү (беренче кече яшьтәгеләр төркеме): тәрбиячеләр өчен методик кулланма/ Ф. В. Хәзрәтова, З. Г. Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2012.— 191 б.
ISBN 978-5-298-02258-3

Методик кулланмада беренче кече яшьтәгеләр төркеменә (2 яшьтән 3 яшькә кадәр) йөрүче балаларның сөйләмен үстерү, аларны ана теленә өйрәтүнең методик нигезләре һәм заманча технологияләре бирелә.
Кулланма милли балалар бакчасында эшләүче тәрбиячеләргә, әти-әниләргә, педагогик уку йортында белем алучы студентларга тәкъдим ителә.

УДК 372.3/4:811.512.145*00
ББК 74.102:81.2Тат

ISBN 978-5-298-02258-3
© Хәзрәтова Ф. В., Шәрәфетдинова З. Г., Хәбибуллина И. Җ., 2012
© Татарстан китап нәшрияты, оригинал-макет, 2012

## АҢЛАТМА ЯЗУЫ

«Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татарстан Республикасы Законында һәм Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасында мәктәпкәчә милли белем бирү өчен кирәкле шартлар булдыру каралган. Бу — республикабызда эшләп килә торган милли балалар бакчалары өчен кадрлар әзерләү, аларның белемен күтәрү һәм методик ярдәм күрсәтү мәсьәләләрен үз эченә ала. 2010—2015 елларга мәгариф системасын үстерү стратегиясендә дә балалар бакчаларында балаларга туган телне өйрәтү, сөйләм үстерү юнәлешен тормышка ашыру максаты куелган. Туган телдә сөйләшергә өйрәтү гаиләдә башлана һәм мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә дәвам итә. Мәктәпкәчә учреждениеләр, мәгариф системасының беренче баскычы буларак, нәниләрне туган телгә өйрәтүдә башлангыч роль уйный.

«Туган телдә сөйләшәбез» дип аталган методик комплект балалар бакчасында эшләүче тәрбиячеләргә кулланма буларак тәкъдим ителә. Комплектка, балаларның яшь үзенчәлекләренә карап, методик кулланма, күрсәтмә әсбаплар (темалар буенча рәсемнәр) һәм аудиоязмалар туплап бирелә, уртанчылар төркеменнән башлап, эш дәфтәрләре дә кертелә. Методик комплектлар биш яшь төркеме (беренче кече яшьтәгеләр, икенче кече яшьтәгеләр, уртанчылар, зурлар, мәктәпкә әзерлек төркемнәре) өчен әзерләнә, һәм аларның барысы да «Туган телдә сөйләшәбез» дип исемләнә. Бу комплектларның төп максаты балаларны ана телендә дөрес һәм яхшы итеп сөйләшергә өйрәтү булса, төп үзенчәлеге — тел системасының фонетик, лексик, грамматик төзелеше дәрәҗәләрен формалаштыру, бәйләнешле сөйләм үстерү, тел һәм сөйләм күренешләрен аңлау, телне тоемлау сәләте булдыру.

Федераль дәүләт таләпләреннән чыгып, методик әсбап танып белү, сөйләм үстерү, матур әдәбият белән таныштыру кебек белем бирү өлкәләрен үз эченә ала. Балалар эшчәнлеген оештыру комплекслы-тематик планлаштыру нигезендә бара. План ел дәверендә төрле темалар үзләштерүне күздә тота. Болар — «Безнең балалар бакчасы», «Көз», «Мин — дөньяның

бер кешесе», «Минем әйләнә-тирәм», «Кыш», «Яңа ел бәйрәме», «Әтиләр һәм әниләр, бабайлар һәм әбиләр», «Халык иҗаты», «Яз», «Җәй». Елга ике тапкыр диагностик методикалар ярдәмендә мониторинг үткәрелә, аның нәтиҗәләре балаларның персональ карточкаларына языла.

Туган телне өйрәнүгә юнәлдерелгән эшчәнлек конспектлары Н. Е. Веракса, Т. С. Комарова, М. А. Васильева редакциясендә чыккан «Туганнан алып мәктәпкә кадәр. Мәктәпкәчә мәгарифнең якынча төп белем бирү программасы» нигезендә төзелгән. Сезнең куллардагы методик әсбапта беренче кечкенәләр төркеменә (2 яшьтән 3 яшькә кадәр) йөрүче балалар эшчәнлеген оештыруның кыскача эчтәлеге (конспектлар) бирелгән һәм нәниләрне туган телгә өйрәтү, сөйләм үстерү эшчәнлеге үзенчәлекләре күрсәтелгән.

Беренче кече яшьтәге төркем балаларының сөйләм эшчәнлеген оештыру системасы мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сөйләм эшчәнлеген оештыру системасыннан аерыла. Балаларны туган телгә өйрәтү һәм сөйләм үстерү әйләнә-тирә белән таныштыру процессында бара. Шушы үзенчәлекләрне исәпкә алып, кече яшьтәге балаларның сөйләмен үстерү эшчәнлеген оештырганда, әйләнә-тирә предметларны һәм күренешләрне танып белүдә нәрсә чыганак булып торуы игътибар үзәгенә алына. Балаларның сөйләмен үстерү «Кроха» программасында (Г. Г. Григорьева, Н. П. Кочетова, Д. В. Сергеева һ.б.) күрсәтелгән түбәндәге эшчәнлек төрләренә нигезләнеп төзелде:

### I. Табигый шартларда табигать һәм социаль тирәлек белән турыдан-туры таныштыру

1. Табигатьне (күренешләрне һәм объектларны) күзәтү.
2. Предметлы дөнья белән таныштыру: предметлар һәм кораллар (исеме, сыйфаты, үзлекләре, эш-хәрәкәтләре).
3. Социаль күренешләр (үзе, якын кешеләр, өлкәннәр хезмәте турында күзаллаулар) белән таныштыру.

### II. Образлы уенчыклар аша тирә-юнь белән таныштыру

1. Уенчыклар карау.
2. «Тылсымлы» капчык», «Бу өйдә кем (нәрсә) яши?» дидактик уеннары, курчак белән дидактик уеннар.
3. Уеннар, күңел ачулар, уен-көлкеләр.
4. Йомыш кушулар (индивидуаль һәм кечерәк төркемнәргә бүлеп).

### III. Рәсем сәнгате аша әйләнә-тирә белән таныштыру

1. Өстәлгә куела торган кечкенә рәсемнәрне, китаптагы иллюстрацияләрне, стенадагы картиналарны карау.
2. «Җанлы» кечкенә картиналар белән эшчәнлек.

### IV. Нәфис сүз аша әйләнә-тирә белән таныштыру

1. Халык авыз иҗаты һәм матур әдәбият әсәрләре уку.
2. Тәрбияче белән бергә кыска экиятләрнең эчтәлеген сөйләү.

### V. Күрсәтмәлелектән башка, тирә-юнь белән таныштыру һәм сөйләм үстерү

1. Күрсәтмәлелектән башка һәм ситуациядән тыш, тәрбиячененң сөйләве.
2. Балалар белән әңгәмәләр һәм сөйләшүләр.

Өченче яшьтәге балалар белән оештырылган эшчәнлек уен характерын ала. Эшчәнлек төрләрендә сөйләм үсешенең *сүзлек эше, сөйләмнең грамматик төзелеше өстендә эш, аваз культурасы тәрбияләү, бәйләнешле сөйләм үстерү, матур әдәбият һәм халык иҗаты белән таныштыру* бурычлары хәл ителә. Туган телгә өйрәтү, сөйләм үстерү мәсьәләләрен чишкәндә, өйрәтүнең төрле методлары, алымнары, чаралары кулланыла. Шундый чараларның берсе — бармак уеннары. Хәрәкәтләнү активлыгы югарырак булган саен, балаларның сөйләме тизрәк һәм яхшырак үсеш ала. Бармак уеннары баш мие эшчәнлегенә, интеллект үсешенә уңай йогынты ясый. Чыннан да, физиологлар, психологлар үткәргән тикшеренүләр (Л. С. Выготский, И. П. Павлов, А. Р. Лурия, А. А. Леонтьев һ.б.) хәрәкәтләнү һәм сөйләм моторикасының үзара бәйле булуын исбатлыйлар.

Эшчәнлек барышында төрле предметлар тотып биюләр, уеннар киң кулланыла. Нәниләр уенчыкларны яшерәләр, эзлиләр, табалар. Мондый уеннар балаларда зур кызыксыну уята, тәрбияче күрсәткән хәрәкәтләрне балалар тырышып кабатлыйлар: «куян булып сикерәләр», «кошлар булып очалар», «җим чүплиләр», «аю кебек алпан-тилпән йөриләр», «әтәч булып кычкыралар» һ.б. Бу уеннарда музыка әсәрләрен куллану балаларның фонематик ишетү сәләтен, ритмикасын, эмоциональ сферасын да баета, үстерә.

Нәниләр белән эшләгәндә, «җанлы» картиналар куллану аеруча отышлы. «Җанлы» картиналар үзләренең тышкы сурәтләрен көтмәгәндә үзгәртәләр һәм шуның белән балаларның игътибарын җәлеп итәләр. Алар, эчтәлеккә карап, ике-өч төрле эшчәнлек өчен кулланыла ала. Мондый очракта эшчәнлекнең аерым эпизодларын үзгәртергә кирәк. Мәсәлән, катнашучыларның санын киметергә яки арттырырга, яңа элементлар кертергә мөмкин. «Җанлы» картиналарны темалар буенча сайлау мөһим: урам, йорт, кибет, кошлар, кыргый хайваннар һ.б. белән таныштыру.

Балаларның игътибарын туплау, эшчәнлеккә карата кызыксыну уяту, ял иттерү (релаксация) максатыннан, шигъри

әсәрләргә зур игътибар бирелә. Бу әсәрләрне укыганда, балалар, эчтәлеккә туры китереп, хәрәкәтләр ясыйлар: «яфраклар, кар бөртекләре кебек очалар», «кер юалар, чайкыйлар, сыгалар», «кояшны сәламлиләр», «кояш нурлары ясыйлар» һ.б.

Матур әдәбият, халык иҗаты, күрсәтмәлелек, предметлар белән уен хәрәкәтләре, кошларның, җәнлекләрнең образларын имитацияләү — болар барысы да нәниләрне туган телгә өйрәтүдә, аларның сөйләмен үстерүдә зур әһәмияткә ия. Балалар белән үткәрелә торган эшчәнлек конспектлары тулы, күләмле итеп язылды. Авторлар үстерелешле өйрәтү, өйрәтү барышында тәрбияләү, фәннилек, эзлеклелек һәм системалылык, аңлаешлылык, балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алу, гуманлылык, күрсәтмәлелек кебек төп педагогик принципларга таяндылар. Өйрәтү-тәрбия процессында балалар белән эшчәнлекне оештырганда, тәрбиячегә иҗади якын килү мөмкинлеге бирелде.

Эшчәнлек конспектларын төзегәндә, тәрбияче өчен күрсәтмәләр, балаларның якынча җаваплары (алар курсив белән бирелә), балаларны активлаштыру җәяләр эчендә күрсәтелде. Җәя эчендә бирелгән индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар, истә калдыру максатыннан, аваз, иҗек, сүз, фраза кебек сөйләм элементын кабатлауны күрсәтә. Кабатлауның төрле вариантлары бар: тәрбияче артыннан, балалар артыннан, тәрбияче белән бергә, күмәк һәм аерым-аерым (индивидуаль). Балаларны активлаштыру аларның җавапларын конкретлаштыру, аерым сүзләрне, фразаларны, хәрәкәтләрне кабатлату максатыннан эшләнә. Тәрбияче балаларга гомуми сораулар белән мөрәҗәгать итә. Ләкин барлык балаларга да бирелгән сорауны кечкенә бала үзенә дип кабул итми, шуңа күрә тәрбиячегә аны конкретлаштырырга кирәк (Балалар, алма нинди төстә? Әмир, алма нинди төстә? Гүзәл, алма нинди төстә? Балалар, минем янга килегез әле. Марат, син дә кил әле. Алсу, син дә кил һ.б.).

Без, авторлар коллективы, өйрәтү-методик комплектта тәкъдим ителгән материаллар балаларга туган телне өйрәтүдә һәм аларның сөйләмен үстерүдә тәрбиячеләргә зур ярдәм булыр дип ышанабыз. Әлеге методик әсбап милли балалар бакчасында эшләүче тәрбиячеләргә, әти-әниләргә, педагогик уку йортларында белем алучы студентларга адреслана. Алардан киңәшләр, тәкъдимнәр көтеп калабыз.

## ЭШЧӘНЛЕКНЕҢ ТЕМАТИК ПЛАНЫ

| Бүлек | Бурычлар | Дата | Йомгаклау чаралары вариантлары |
|---|---|---|---|
| Безнең балалар бакчасы | Балалар бакчасы шартларына ияләштерү. Баланың социаль мохите буларак, балалар бакчасы (бакча бинасы һәм төркем бүлмәсендәге җиһазлар: шкаф, караваt, уенчыклар һ.б.) белән таныштыру. Балаларны бер-берсе һәм тәрбияче белән таныштыру. Балалар бакчасына йөрү, яшьтәшләре белән аралашуның балаларда уңай эмоцияләр тудыруына ирешү. | 20.08 — 10.09 | |
| Көз | Көз турында күзаллау формалаштыру; табигатьтә, кешеләр киемендә, балалар бакчасы мәйданында сезонлы үзгәрешләр, уңыш җыю, кайбер яшелчәләр, җиләкләр, гөмбәләр турында беренчел күзаллау булдыру. Балаларның йорт хайваннары һәм кошлары турында белемнәрен киңәйтү. Көзен урман җәнлекләре һәм кошларының үз-үзләрен тоту үзенчәлекләре белән таныштыру. | 11.09 — 30.09 | Көз бәйрәме. Балалар иҗаты күргәзмәсе. Көзге яфраклар җыю һәм җыелган яфракларның иң матурларыннан плакат ясау. |
| Мин — дөньяның бер кешесе | Балада, кеше буларак, үзе турында күзаллау булдыру; кеше гәүдәсенең төп өлешләре һәм аларның ни өчен кирәклеге белән таныштыру. Үз исемен, гаилә әгъзаларының исемнәрен белүләренә ирешү. Нәрсәнең яхшы, нәрсәнең начар булуы, сәламәт тормыш образы турында башлангыч күзаллау булдыру. | 1.10 — 15.10 | Әти-әниләр белән бергә чәй эчү. Балаларның фотографияләре белән плакат ясау. «Бездә кем яхшы?» уены. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Минем әйләнә-тирәм | Балаларны туган шәһәрләре (авыллары): аның исеме, объектлары (урам, йорт, кибет, шифаханә) һәм транспорт, һөнәрләр (табиб, сатучы, полиция хезмәткәре) белән таныштыру. | 16.10—4.11 | «Минем яраткан уенчыкларым» исемле тематик күңел ачу чарасы. Балалар иҗаты күргәзмәсе. |
| Монито-ринг | | 5.11 — 14.11 | Балаларның персональ карточкаларын тутыру. |
| Яңа ел бәйрәме | Яңа елга һәм Яңа ел бәйрәменә кагылышлы эшчәнлекнең барлык төрен (уен, коммуникатив эшчәнлек, хезмәт, танып белү, тикшеренү, продуктив, музыкаль эшчәнлекләр, укулар) оештыру. | 15.11—31.12 | Яңа ел бәйрәме. |
| Кыш | Кыш турында күзаллау формалаштыру (табигатьтә сезон үзгәрешләре, кешеләрнең киеме, балалар бакчасы мәйданы). Балаларның йорт хайваннары һәм кошлары турында белемнәрен киңәйтү. Кыш көне урман җәнлекләре һәм кошларының үз-үзләрен тоту үзенчәлекләре белән таныштыру. | 1.01 — 31.01 | Кыш бәйрәме. Балалар иҗаты күргәзмәсе. |
| Әтиләр һәм әниләр, бабайлар һәм әбиләр | Гаиләгә, әнигә, әбигә мәхәббәт темасына кагылышлы эшчәнлекнең барлык төрләрен оештыру (уен, коммуникатив, хезмәт, танып белү, тикшеренү, продуктив, музыкаль эшчәнлекләр, укулар). | 1.02 — 8.03 | Әниләр бәйрәме. |
| Халык иҗаты | Балаларны халык иҗаты белән таныштыру. Халык авыз иҗаты (җырлар, бармак уеннары һ.б.) белән таныштыру. Балалар эшчәнлегенең барлык төрләрен оештырганда, фольклор элементларын куллану. | 9.03 — 20.03 | Уеннар. Халык иҗат иткән уенчыклар күргәзмәсе. |
| Мони-торинг | | 21.03 — 31.03 | Балаларның персональ карточкаларын тутыру. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Яз | Яз турында күзаллау формалаштыру (табигатьтә, кешеләр киемендә, балалар бакчасы мәйданында сезон үзгәрешләре). Йорт хайваннары һәм йорт кошлары турында белемнәрен киңәйтү. Яз көне урман җәнлекләре һәм кошларының үз-үзләрен тоту үзенчәлекләре белән таныштыру. | 1.04 — 30.04 | Яз бәйрәме. Балалар иҗаты күргәзмәсе. |
| Җәй | Җәй турында күзаллау формалаштыру (табигатьтә, кешеләр киемендә, балалар бакчасы мәйданында сезон үзгәрешләре). Йорт хайваннары һәм кошлары, яшелчәләр, җиләк-җимешләр турында белемнәрен киңәйтү. Җәен урман җәнлекләре һәм кошларының үз-үзләрен тоту үзенчәлекләре белән таныштыру. Җылы якларда яшәүче кайбер хайваннар белән таныштыру. | 1.05 — 31.05 | Җәй бәйрәме. |
| Җәйге чорда балалар бакчасы каникул режимында эшли. | | 1.06— 20.08 | |

## БЕЗНЕҢ БАЛАЛАР БАКЧАСЫ (20.08 — 10.09)

### А. ТАНЫП БЕЛҮ ЭШЧӘНЛЕГЕ

| Тема | Бурычлар |
|---|---|
| Чишенү бүлмәсен карау | 1) балаларны чишенү бүлмәсе, андагы җиһазлар белән таныштыру, бүлмәләрдә (төркемдәге) ориентлашу тәҗрибәсе туплау;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын, диалогта катнашу теләген үстерү;<br>3) җиһазларга сакчыл караш тәрбияләү. |
| Йомшаккай бездә кунакта | 1) балаларның уенчыклар турындагы белемнәрен киңәйтү, тәрбияче сорауларына җавап бирү осталыгын формалаштыру, уенчык исемнәре һәм аларның эш-хәрәкәтен белдерә торган сүзләр хисабына сүз байлыгын арттыру;<br>2) тыңлау һәм сорауларга җавап бирү теләген үстерү;<br>3) сөйләм этикетының гади формаларын (исәнләшү, саубуллашу) кулланырга гадәтләндерү, уенчыкларга сакчыл караш тәрбияләү. |
| Йомшаккай тагын бездә кунакта | 1) уенчыкларны карарга һәм аерым өлешләрен билгеләргә өйрәтү; уенчыкларның исемен, өлешләрен әйтү, төсен, хәрәкәтен белдерә торган сүзләрне актив сүзлеккә кертү;<br>2) тәрбияче соравына кычкырып җавап бирү осталыгын үстерү;<br>3) сөйләм этикетының гади формаларын (исәнләшү, саубуллашу) кулланырга гадәтләндерү, кызыклы уенчыклар белән уйнаудан тәм табу, шатлык хисләре тәрбияләү. |
| Тупны коткарабыз (рәсем буенча) | 1) рәсемнең эчтәлеген аңларга ярдәм итү, эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә өйрәтү;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын, тәрбияче артыннан аерым сүзләрне һәм фразаларны актив кабатлауларын үстерү;<br>3) башкаларга ярдәм итү теләге тәрбияләү. |

| | |
|---|---|
| Юыну бүлмәсен карау | 1) балаларны юыну бүлмәсендәге предметлар (сабын, сөлге, кран, су, теш щёткасы, теш пастасы) белән таныштыру, функциональ билгеләнешләре турындагы күзаллауларын ачыклау;<br>2) сүзләрне төрле грамматик формаларда (сабын, сабынны, сабын белән һ.б.) куллану осталыгына ирешү, балаларның сөйләм активлыгын, инициативасын үстерү;<br>3) балаларны сөйләм этикетының гади формаларын (исәнләшү, саубуллашу) кулланырга гадәтләндерү, пөхтәлек, чисталык, башкаларга ярдәм итү омтылышы тәрбияләү. |

**В.** СӨЙЛӘМ ҮСТЕРҮ ЭШЧӘНЛЕГЕ

| Тема | Бурычлар |
|---|---|
| Кем нәрсә эшли? | 1) балаларның сөйләмен үстерергә ярдәм итү, рәсемнәр карарга, анда сурәтләнгән предметларны һәм аларның сыйфатларын әйтергә, рәсемдә сурәтләнгән уенчыкны, предметны өстәлдә табып, исемен, гамәлен атый белергә өйрәтү;<br>2) игътибарны, кабул итү сәләтен үстерү;<br>3) уенчыкларга карата сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү. |
| Предметларның төсләрен тану һәм әйтү. «Паровоз» дидактик күнегүе | 1) төсләрне белдерә торган сыйфатлар (кызыл, яшел, сары) хисабына балаларның сөйләмен баету, [ү] авазының дөрес әйтелешенә күнектерү;<br>2) балаларның игътибарын, кабул итү сәләтен, төсләрне тану һәм атау осталыгын үстерү;<br>3) эшчәнлеккә карата кызыксыну, бергәләп уйнау, шөгыльләнү теләге тәрбияләү. |
| Уенчыклар бездә кунакта | 1) төсне, зурлыкны, эш-гамәлне белдерә торган сүзләр (*зур, кечкенә, яшел, кызыл, утырт, әчерт, керт*) хисабына балаларның сүз байлыгын арттыру, аралашу осталыгын формалаштыру;<br>2) исеме, төсе, размеры буенча балаларның предметны табу осталыгын, сенсор тою сәләтен, игътибарын, хәтерен үстерү;<br>3) уенчыкларга карата сакчыл караш тәрбияләү. |
| Пирамидалар | 1) балаларны предметларның зурлыгын, төсен билгеләргә өйрәтү, төсне (*кызыл, яшел, сары, зәңгәр*), зурлыкны (*зур — кечкенә, зуррак — кечкенәрәк, иң зурысы — иң кечкенәсе*) белдерә торган сүзләр ярдәмендә сүз байлыгын арттыру, аваз ияртемнәрен ачык әйтүдә күнектерү;<br>2) игътибарны, кабул итүне, сенсор тою сәләтен үстерү;<br>3) түземлелек, дидактик уеннар белән кызыксыну тәрбияләү. |

**С.** МАТУР ӘДӘБИЯТ БЕЛӘН ТАНЫШТЫРУ

| Тема | Бурычлар |
|---|---|
| «Үчтеки, үчтеки» такмагын уку | 1) балаларны фольклор әсәрләре белән кызыксындыру, шигъри әсәрнең эчтәлеген аңларга өйрәтү;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен, хәтерен, уңай эмоцияләрен үстерү;<br>3) нәфис сүзгә мәхәббәт тәрбияләү. |
| Ә. Бикчәнтәеваның «Туп-туп-тубыбыз» шигырен уку | 1) балаларга шигырьнең эчтәлеген аңларга ярдәм итү, таныш предметларны таный һәм атый белергә, шигырьнең авыр әйтелешле аерым сүзләрен дөрес әйтергә өйрәтү, төсләрне аеру күнекмәсен ныгыту;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен, хәтерен, уңай эмоцияләрен үстерү;<br>3) уенчыкларга сакчыл караш тәрбияләү. |
| С. Сөләйманованың «Ике» шигырен уку | 1) балаларны шигъри әсәр белән кызыксындыру, аның эчтәлеген аңларга өйрәтү, баланың үзе турында күзаллавын формалаштыруны дәвам итү; *кул, аяк, колак, күз* сүзләре хисабына сүз байлыгын арттыру һәм активлаштыру;<br>2) балаларның игътибарын, кабул итү сәләтен үстерү;<br>3) гигиена күнекмәләре тәрбияләү. |

**КӨЗ (1.09 — 30.09)**

**А.** ТАНЫП БЕЛҮ ЭШЧӘНЛЕГЕ

| Тема | Бурычлар |
|---|---|
| Көзге табигать | 1) балаларның көз (табигатьтәге үзгәрешләр, кешеләрнең киеме һ.б.) турында гади күзаллауларын формалаштыру;<br>2) балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын, тәрбиячене тыңлый белү осталыгын үстерү;<br>3) көзге табигатькә соклану хисләре тәрбияләү. |
| Җиләк-җимешләр | 1) тышкы билгеләре һәм тәме буенча җиләк-җимешләрне аерырга өйрәтү, җиләк-җимешләр һәм аларның уңышын җыеп алу турында күзаллауларын киңәйтү, җиләк-җимешләрнең исемнәре һәм аларның билгеләрен белдерә торган сүзләр хисабына балаларның сүз байлыгын үстерү;<br>2) балаларның игътибарын, үзләштерү, кабул итү һәм сенсор тою сәләтен, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;<br>3) балаларны сөйләм этикетының гади формаларын (исәнләшү, саубуллашу) куллана белергә гадәтләндерү, әйләнә-тирә табигать объектларына кызыксыну тәрбияләү. |

| | |
|---|---|
| «Безнең Алсу» сериясеннән рәсем карау | 1) рәсемдәге предметларны таный һәм исемен әйтә белергә, рәсем эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә өйрәтү, сүзлекне активлаштыру;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен үстерү, тәрбияче күрсәтмәләрен ишетә һәм үти белүләренә ирешү;<br>3) рәсемне кызыксынып карау теләге тәрбияләү. |
| Яшелчәләр: помидор, кыяр, кишер белән таныштыру | 1) балаларның помидор, кыяр, кишер турындагы белемнәрен ныгыту; помидор, кыяр, кишернең форма, төс, тәм үзенчәлекләре (кызыл, йомшак, шома, тәмле, сусыл, хуш исле, шар формасындагы помидор; яшел, каты, шома, кытыршы кыяр; шома, кызыл, тәмле, каты кишер) белән таныштыру;<br>2) балаларның сенсор тою сәләтен, тәрбиячене ишетү һәм сорауларга җавап бирү осталыкларын үстерү;<br>3) балаларны сөйләм этикетының гади формаларын (исәнләшү, саубуллашу) кулланырга гадәтләндерү, зурлар хезмәтенә хөрмәт тәрбияләү. |
| Рәсемдәге кошларны карау | 1) балаларда күгәрчен, саескан турында гомуми күзаллаулар булдыру, кошларга карата кызыксыну уяту;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын, күзәтүчәнлеген һәм сүз байлыгын үстерү;<br>3) кошларга карата мәрхәмәтлелек тәрбияләү. |
| Көз (йомгаклау чарасы) | 1) балаларның көз турындагы белемнәрен (яфраклар саргая, сары яфраклар, яфраклар коела, яңгырлар күп ява, кешеләр җылы киемнәрен кияләр) ныгыту, тәрбияче сорауларына дөрес җавап бирергә, рәсем ясаганда, буяуны кәгазь битенә дөрес һәм тигез төшерергә өйрәтү, төсләр турындагы күзаллауларын ныгыту;<br>2) балаларның актив сөйләмен, ишетеп кабул итү сәләтен, игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерү, рәсем ясарга кызыксындыру;<br>3) көзге табигатькә соклану хисләре тәрбияләү. |

## В. СӨЙЛӘМ ҮСТЕРҮ ЭШЧӘНЛЕГЕ

| Тема | Бурычлар |
|---|---|
| Яшелчәләр | 1) яшелчәләрне белдерә торган исемнәр (бәрәңге, помидор, суган, кишер) һәм аларның үзлекләрен белдерүче сүзләр хисабына балаларның сүзлеген баету, яшелчәләрне танырга өйрәтү, сөйләмнең грамматик төзелешен камилләштерү;<br>2) балаларның сенсор тою сәләтен үстерү;<br>3) яшелчәләр, аларның файдасы турында мәгълүмат бирү. |

| | |
|---|---|
| «Җил исә» уен күнегүе. «Кем нәрсә ашый?» дидактик күнегүе | 1) балаларның төсләр турындагы күзаллавын ныгыту, җәнлекләрнең нәрсә ашавы турындагы белемнәрен ачыклау; *ялап эчә, кимерә, чүпли, ашый* фигыльләрен сөйләмдә активлаштыру, авыз аша һаваны әкрен, салмак кына чыгарырга өйрәтү;<br>2) игътибарны, күзәтүчәнлекне үстерү;<br>3) җәнлекләргә, кошларга карата кызыксыну тәрбияләү. |
| Урманда | 1) балаларның олылар белән аралашу теләген хуплау, исем һәм сыйфатларны кулланырга өйрәтү: *йомшак йонлы койрык, озын колаклы куян, юан тәпиле аю, соры бүре;* кыргый хайваннарның тышкы билгеләрен һәм гадәтләрен белдерә торган сүзләр хисабына сүзлекне активлаштыру: *төлке бара, куян сикерә, аю алпан-тилпән йөри* һ.б.;<br>2) ишетү игътибарын, координацияләрне, ритм хисен үстерү;<br>3) кыргый хайваннарга карата кызыксыну тәрбияләү. |

## С. МАТУР ӘДӘБИЯТ БЕЛӘН ТАНЫШТЫРУ

| Тема | Бурычлар |
|---|---|
| Йорт хайваннарын чакыру эндәшләрен уку | 1) эндәшнең эчтәлеген аңлату; текстның эчтәлегеннән чыгып, аваз ияртемнәрен, ымлыкларны дөрес әйтүләренә, тәрбияченең сорауларына дөрес җавап бирүләренә ирешү;<br>2) балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерү;<br>3) хайваннарны ярату хисе тәрбияләү. |
| Д. Гарифуллинның «Йә, алар кемнәр икән?» шигырен уку | 1) шигъри әсәрне аңлап кабул итәргә өйрәтүне дәвам итү; *бак-бак, мә-мә, кар-кар* аваз ияртемнәрен кабатлау; балаларны шигырьдә бирелгән диалогка җәлеп итү, сүз байлыгын үстерү һәм активлаштыру;<br>2) балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген, кабул итү сәләтен үстерү;<br>3) кошларга, хайваннарга карата шәфкатьлелек тәрбияләү. |
| Б. Рәхмәтнең «Су» шигырен уку | 1) текстка туры китереп, хәрәкәтләр ясарга өйрәтү, [йу] аваз кушылмасын ачык итеп әйтергә күнектерү; сүз байлыгын үстерү һәм активлаштыру;<br>2) балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген, кабул итү сәләтен үстерү;<br>3) гигиена күнекмәләре тәрбияләү. |

## МИН—ДӨНЬЯНЫҢ БЕР КЕШЕСЕ (1.10 —15.10)

### **А.** ТАНЫП БЕЛҮ ЭШЧӘНЛЕГЕ

| Тема | Бурычлар |
|---|---|
| Минем исемем бар | 1) баланы үзенең һәм иптәшләренең исемен әйтергә өйрәтү, исемнәрне истә калдырырга, оялчанлыкны җиңәргә ярдәм итү;<br>2) тәрбияче әйткәнне ишетергә һәм аңларга, кайбер фразаларны (Минем исемем — Алсу) кабатларга күнектерү, хәтерне, игътибарны үстерү;<br>3) балаларда зурларга һәм яшьтәшләренә карата ягымлылык, дустанә мөнәсәбәт тәрбияләү. |
| Бу — мин | 1) организм һәм аның өлешләре турында балаларда күзаллау формалаштыру, үзләрен бербөтен итеп кабул итәргә өйрәтү, гәүдә өлешләре турында белемнәрне ачыклау һәм ныгыту;<br>2) гәүдә өлешләренең атамалары (баш, күзләр, колаклар, борын, авыз, тешләр, чәч, куллар, аяклар) хисабына балаларның сүзлеген активлаштыру;<br>3) үзеңне, гәүдә өлешләреңне ярату, игътибарлы булу, культура-гигиена күнекмәләрен үтәү теләге тудыру. |

### **В.** СӨЙЛӘМ ҮСТЕРҮ ЭШЧӘНЛЕГЕ

| Тема | Бурычлар |
|---|---|
| Алсу бүлмәсе | 1) балаларны өй җиһазларын таный һәм атый белергә өйрәтү; *өстәл, урындык, карават, шкаф, көзге* кебек исемнәр хисабына сүзлекне активлаштыру, сөйләмнең грамматик төзелешен камилләштерү;<br>2) балаларның уңай эмоцияләрен, кызыксынучанлыгын үстерү;<br>3) бергәләп шөгыльләнү теләге тәрбияләү. |
| «Бу өйдә кем яши?» дидактик уены | 1) төркемгә йөрүче балаларның исемнәрен истә калдырырга ярдәм итү, фигыльләрне хәзерге һәм киләчәк заманда куллана белергә өйрәтү, сорауны белдерә торган сүзләрне кулланырга күнектерү;<br>2) игътибарны, кабул итү сәләтен, диалогик сөйләмне үстерү;<br>3) бер-береңә карата игътибарлылык тәрбияләү. |

### С. МАТУР ӘДӘБИЯТ БЕЛӘН ТАНЫШТЫРУ

| Тема | Бурычлар |
|---|---|
| Г. Тукайның «Гали белән кәҗә» шигырен уку | 1) шигъри әсәрне аңлап кабул итүләренә ирешү, балаларда «Мин — дөньяның бер кешесе» дигән күзаллау булдыру; *кәҗә, чирәм, сакал* сүзләре хисабына сүзлек байлыгын киңәйтү, хәрәкәтләр өйрәтүне дәвам итү;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын, уңай эмоцияләрен үстерү;<br>3) балаларда бер-берсенә һәм хайваннарга карата кайгыртучанлык тәрбияләү. |
| З. Туфайлованың «Ул зу-у-у-р үскән» шигырен уку | 1) шигъри әсәрне аңлап кабул итүләренә ирешү һәм хезмәтнең нәтиҗәсен күрә белергә өйрәтү; *утырткан, сипкән, үскән* кебек эш-хәрәкәтне белдерә торган фигыльләр хисабына сүз байлыгын арттыру һәм активлаштыру, диалогик сөйләм күнекмәсе формалаштыру;<br>2) балаларның эмоциональлеген үстерү;<br>3) гөлләргә карата сакчыл караш, матурлыкка соклану тәрбияләү. |
| «Песи-нечкәбил» бишек җырын җырлау | 1) шигъри әсәрне аңлап кабул итүләренә ирешү, бишек җыры текстына туры китереп, хәрәкәтләр өйрәтү;<br>2) балаларның игътибарын үстерү;<br>3) фольклор әсәрләренә мәхәббәт тәрбияләү. |

## МИНЕМ ӘЙЛӘНӘ-ТИРӘМ (16.10. — 1.11)

### А. ТАНЫП БЕЛҮ ЭШЧӘНЛЕГЕ

| Тема | Бурычлар |
|---|---|
| Яраткан уен бүлмәбез | 1) балаларны балалар бакчасы шартларына ияләндерүне дәвам иттерү, уен (төркем) бүлмәсе, андагы махсус почмаклар белән таныштыру, «һәр әйбернең үз урыны» дигән төшенчәне аңлату һәм ныгыту;<br>2) сүзләрне һәм кыска фразаларны ачык әйтүләренә ирешү, сүз байлыгын үстерү;<br>3) җиһазларга сакчыл караш һәм яшьтәшләренә карата ягымлылык тәрбияләү. |
| КамАЗ машинасы | 1) балаларны КамАЗ машинасын һәм аның өлешләрен танырга, исемен әйтергә өйрәтү; уенның сүзләренә туры китереп, хәрәкәтләр ясау осталыгы булдыру;<br>2) балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын, хәтерен, сөйләмен, эмоциональлеген үстерү;<br>3) балаларда йөк транспортына, өлкәннәр хезмәтенә карата кызыксыну уяту. |

| | |
|---|---|
| «Безнең урам» | 1) балаларны урам, андагы объектлар, күренешләр белән таныштыру, аларга карата кызыксыну уяту;<br>2) балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын, сүз байлыгын үстерү;<br>3) урамга соклану хисе тәрбияләү. |

## B. СӨЙЛӘМ ҮСТЕРҮ ЭШЧӘНЛЕГЕ

| Тема | Бурычлар |
|---|---|
| Алсу бездә кунакта | 1) балаларга һөнәрләр (табиб, полиция хезмәткәре) турында мәгълүмат бирү, грамматик яктан җөмләләрне аңларга һәм аларны сөйләмдә дөрес кулланырга өйрәтүне дәвам итү;<br>2) игътибарны, хәтерне, күзәтүчәнлекне, кабул итү сәләтен үстерү;<br>3) һөнәрләргә карата кызыксыну тәрбияләү. |
| Әминәнең туган көненә килегез | 1) [к] һәм [к] авазларының сүзләрдә һәм сөйләмдә дөрес әйтелешен ныгыту, килеш кушымчаларын дөрес әйтергә өйрәтү, савыт-сабаларны белдерә торган сүзләр хисабына сүзлекне киңәйтү һәм активлаштыру, гомумиләштерүче сүзләрне аңлый һәм куллана белүләренә ирешү, җөмләләр белән җавап бирергә күнектерүне дәвам итү;<br>2) инициативалы сөйләмне, игътибарны, хәтерне үстерү, башкаларга мөрәҗәгать итәргә теләк тудыру;<br>3) үзара аралашуга омтылыш тәрбияләү. |
| Минем гаиләм | 1) сөйләмдә ягымлы сүзләрне (әти — әтием, әни — әнием, әби — әбием, сеңел — сеңлем) кулланырга өйрәтү, [ә] авазының әйтелешен ныгыту, аны ачык, тиешле дәрәҗәдә кычкырып әйтүгә ирешү, тәрбияче сорауларына җавап бирергә күнектерү;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен үстерү, зурлар һәм иптәшләре белән ирекле аралашуларына ирешү;<br>3) гаилә әгъзаларына ихтирам тәрбияләү. |

## C. МАТУР ӘДӘБИЯТ БЕЛӘН ТАНЫШТЫРУ

| Тема | Бурычлар |
|---|---|
| М. Җәлилнең «Маэмай» шигырен уку | 1) шигъри әсәрне аңлап кабул итүләренә ирешү, бармак театры элементларын өйрәтүне дәвам итү, сүз байлыгын арттыру;<br>2) балаларның кабул итү һәм истә калдыру сәләтен үстерү;<br>3) йорт хайваннарына карата шәфкатьлелек тәрбияләү. |

| | |
|---|---|
| М. Җәлилнең «Әтәч» шигырен уку | 1) күрсәтмәлелек кулланмыйча, әдәби әсәрне тыңлау һәм кабул итү күнекмәләре формалаштыру, йорт кошларын тавышлары буенча танырга һәм исемнәрен атарга өйрәтү, [к] һәм [к] авазларының әйтелешен ныгыту;<br>2) балаларның игътибарын, кабул итү һәм тыңлау сәләтен үстерү;<br>3) йорт кошларына карата шәфкатьлелек тәрбияләү. |
| Ж. Тәрҗемановның «Маэмай» шигырен уку | 1) шигъри әсәрне аңлап кабул итүләренә ирешү, аерым сүзләрне һәм зур булмаган фразаларны истә калдырырга өйрәтү;<br>2) балаларның игътибарын үстерү;<br>3) эткә карата миһербанлылык тәрбияләү. |

## ЯҢА ЕЛ БӘЙРӘМЕ (15.11. — 31.12)

### А. ТАНЫП БЕЛҮ ЭШЧӘНЛЕГЕ

| Тема | Бурычлар |
|---|---|
| Электр лампасы белән таныштыру | 1) электр турында балаларга гади төшенчә бирү (электр тогы электр чыбыкларында «яши»; утны яндыру өчен, өзгечкә (выключательгә) басарга кирәк, шуннан соң электр чыбыкларыннан ток килә); *электр, ток, чыбык, өзгеч* (*выключатель*) сүзләре хисабына сүзлекне үстерү һәм активлаштыру;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен, кабул итү сәләтен үстерү, ток белән бәйләнешле булган куркынычсызлык кагыйдәләрен балаларга җиткерү;<br>3) сакчыллык тәрбияләү. |
| Гирлянда | 1) балаларга гирлянда турында башлангыч белемнәр бирү, электр тогы турындагы күзаллауларын ныгыту, кызыл, яшел, сары төсләрне таный һәм аера белергә күнектерү;<br>2) балаларның игътибарын, кызыксынучанлыгын, шатлык хисләрен үстерү, сүз байлыгын киңәйтү;<br>3) күмәк эшчәнлектә катнашу теләге тәрбияләү. |
| Яшел чыршы | 1) балалар белән бергәләп чыршыны карау, Яңа ел бәйрәме турындагы күзаллауларын киңәйтү һәм баету;<br>2) балаларның «Яңа ел бәйрәме» темасы буенча сүз байлыгын активлаштыру, тәрбияче соравына җавап бирү осталыгын, игътибарын, күзәтүчәнлеген, сенсор тою сәләтен үстерү;<br>3) матурлыкны күрә һәм аңа соклана белү хисләре, чыршы уенчыкларына карата сакчыл караш тәрбияләү. |

| | |
|---|---|
| Чыршы бизибез | 1) балаларның Яңа ел бәйрәме турындагы күзаллауларын баетуны дәвам итү;<br>2) балаларның «Яңа ел бәйрәме» темасы буенча сүзлеген активлаштыру, тәрбияче соравына җавап бирү осталыгын, игътибарын, күзәтүчәнлеген, сенсор тою сәләтен үстерү;<br>3) чыршы уенчыкларына карата сакчыл караш тәрбияләү. |
| Без музыка залында | 1) чыршы бәйрәменә әзерләнү: балаларны музыка залының бизәлеше, чыршы уенчыклары, аларның материалы, төсе, формасы белән таныштыру; *чыршы уенчыклары, йомры, пыяла, шома, ялтырый* сүзләре хисабына сүзлекне активлаштыруны дәвам итү;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен, күзәтүчәнлеген, игътибарын, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;<br>3) балаларда эстетик хисләр тәрбияләү. |

**В.** СӨЙЛӘМ ҮСТЕРҮ ЭШЧӘНЛЕГЕ

| Тема | Бурычлар |
|---|---|
| Купшы чыршы | 1) сузык һәм тартык авазларны, аваз иярткемнәрен ачык әйтергә, сыйфатларны дөрес кулланырга күнектерү, *түбәндә* сүзен сөйләмдә кулланырга өйрәтү;<br>2) сорауларга җавап бирү осталыгын, игътибарны, күзәтүчәнлекне үстерү;<br>3) табигатькә соклану хисләре тәрбияләү. |
| Куян чыршы янында | 1) сөйләмдә бәйлек сүзләрне (*эчендә,артында, астында, өстә, өстендә*) кулланырга, *кайда? кая?* сорауларына җавап бирергә, тәрбияче һәм иптәшләре белән ирекле аралашырга өйрәтүне дәвам итү, тавыш көчен дөрес куллану осталыгын формалаштыру;<br>2) игътибарны үстерү, тәрбияче күрсәтмәләрен үтәүдә күнектерү;<br>3) нәфис сүзгә кызыксыну тәрбияләү. |
| Песи белән кәҗә чыршы янында | 1) балаларны тәрбияче сорауларына җавап бирергә өйрәтүне дәвам итү, сөйләмдә фигыльләр һәм сыйфатлар куллануны активлаштыру, [җ] авазын иҗекләрдә, сүзләрдә, җөмләләрдә дөрес һәм ачык әйтүләренә ирешү; аваз иярткемнәрен кабатлаганда, тавыш көчен җайлый белүдә күнектерү;<br>2) игътибарны, кабул итү сәләтен, тәрбияче күрсәтмәләрен үтәү осталыгын үстерү;<br>3) хайваннарга карата шәфкатьлелек тәрбияләү. |

| | |
|---|---|
| «Тылсымлы» таякчык | 1) балаларны сузык һәм тартык авазларны, аерым сүзләрне ачык итеп әйтергә өйрәтү, төсләр турындагы күзаллауларын ныгыту, төсне белдерә торган сүзләр хисабына сүзлекне баету;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын, ишетү осталыгын үстерү;<br>3) бергәләп шөгыльләнү теләге тәрбияләү. |

### С. МАТУР ӘДӘБИЯТ БЕЛӘН ТАНЫШТЫРУ

| Тема | Бурычлар |
|---|---|
| Ә. Бикчәнтәеваның «Беренче адым» шигырен уку | 1) балаларга шигырьнең эчтәлеген аңларга ярдәм итү, авыр әйтелешле кайбер сүзләрне дөрес әйтергә өйрәтү;<br>2) сорауларга җавап бирү күнекмәсен үстерү;<br>3) күмәк эшчәнлек күнекмәсе тәрбияләү. |
| «Карга әйтә» эндәшен уку | 1) шигъри әсәрне аңлап кабул итүләренә ирешү, балаларның кошлар турында белемнәрен арттыру һәм ныгыту, кошларның тышкы кыяфәтенә игътибар итү, сүз байлыгын арттыру, [к] авазының дөрес әйтелешенә ирешү;<br>2) балаларның игътибарын үстерү;<br>3) кошлар белән кызыксыну теләге уяту. |

## КЫШ (1.01. — 31.01)

### А. ТАНЫП БЕЛҮ ЭШЧӘНЛЕГЕ

| Тема | Бурычлар |
|---|---|
| Ап-ак кар ява | 1) балаларны кар һәм аның үзлекләре (ак төстә, эри, йомшак, салкын, җиңел) белән таныштыру, тәрбияче сорауларына җавап бирергә күнектерү;<br>2) балаларның сүз байлыгын, игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерү;<br>3) кышкы табигатькә соклану хисе, бергәләп уйнау теләге тәрбияләү. |
| Алсу урамга җыена | 1) балаларның кышкы киемнәр турындагы белемнәренә төгәллек кертү, урамга чыкканда киенү эзлеклелеген һәм киемнәрне истә калдырырга өйрәтү, тәрбияче сорауларына җавап бирергә күнектерү;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен, фикерләвен, сүз байлыгын үстерү;<br>3) башкаларга ярдәм итү теләге булдыру, киемнәргә сакчыл караш тәрбияләү. |

| | |
|---|---|
| Ләйлә суыктан курыкмый (рәсем буенча) | 1) рәсемне карарга, рәсемдәге предметларны танырга, исемнәрен дөрес әйтергә өйрәтү; предметларны, эш-хәрәкәтне, төсне белдерә торган сүзләр ярдәмендә сүзлекне активлаштыру, рәсем эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә күнектерү;<br>2) кабул итү сәләтен, игътибарны, хәтерне үстерү;<br>3) сюжетлы рәсемнәр карарга теләк уяту. |
| Күгәрченнәр, чыпчыклар — безнең нәни кошчыклар | 1) мәйданчыктагы җимлеккә килгән кошларны күзәтү, исемнәрен әйтү; *гөр-гөр, чырык-чырык, кар-кар* аваз ияртемнәрен ачык әйтергә күнектерү; *томшык, сикерә, гөрлиләр, җим, чүплиләр, чырылдый, җитез, өлгер* сүзләре хисабына сүзлекне баету;<br>2) балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;<br>3) кошлар турында кайгырту, аларга ярдәм итү теләге тәрбияләү. |

## **В.** СӨЙЛӘМ ҮСТЕРҮ ЭШЧӘНЛЕГЕ

| Тема | Бурычлар |
|---|---|
| Кошлар | 1) балаларны аваз ияртемнәрен дөрес һәм ачык итеп әйтергә, алардан фигыльләр (*гөр-гөр — гөрли, чырык-чырык — чыркылдый, кар-кар — каркылдый*) ясарга өйрәтү, гомумиләштерүче сүзләрне (*тавык, әтәч, каз — йорт кошлары*) куллануда күнектерү; кош исемнәрен, гәүдә өлешләрен, хәрәкәтне белдерүче сүзләр хисабына сүз байлыгын активлаштыру, балаларны кошлар белән таныштыруны дәвам итү;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен, сөйләмен үстерү;<br>3) кошларга карата кайгыртучанлык тәрбияләү. |
| Юлны чистартабыз | 1) балаларның кыш һәм кыш көне башкарыла торган хезмәт күнекмәләре турындагы белемнәрен формалаштыру, көрәк белән эшләргә өйрәтү, ишегалдын җыештыручы хезмәте белән таныштыру, балаларның сүзлеген активлаштыру, аерым сүзтезмәләрне (*зур көрәк, кечкенә көрәк, ак кар, күп кар, әз кар*) ачык итеп әйтүдә күнектерү;<br>2) хезмәт күнекмәләрен, кеше хәрәкәтләрен имитацияләү осталыгын үстерү;<br>3) зурларга ярдәм итү һәм гади хезмәт хәрәкәтләре үтәү теләге тәрбияләү. |

### С. МАТУР ӘДӘБИЯТ БЕЛӘН ТАНЫШТЫРУ

| Тема | Бурычлар |
|---|---|
| Ә. Ерикәйнең «Беренче кар» шигырен уку | 1) шигъри әсәрне аңлап кабул итүләренә ирешү, әсәр аша табигать дөньясына җәлеп итү, кышкы табигать турында мәгълүмат бирү; *йомшак, ап-ак* сыйфатлары хисабына сүз байлыгын арттыру һәм активлаштыру;<br>2) балаларның катлаулы сорауларга җавап бирү осталыгын, хәтерен, уңай эмоцияләрен үстерү;<br>3) табигатькә карата мәхәббәт уяту. |
| Ж. Тәрҗемановның «Йокы бабай» әкиятен сөйләү | 1) әкиятнең эчтәлеген аңлап кабул итүләренә ирешү;<br>2) балаларның игътибарын үстерү;<br>3) сорауларга дөрес җавап бирү омтылышы уяту. |
| С. Летованың «Кар бабай» хикәясен уку | 1) күләме буенча зур булмаган әдәби әсәрне (хикәяне) күрсәтмәлелек кулланмыйча тыңлау һәм кабул итү, сорауларга аңлаешлы итеп җавап бирергә өйрәтүне дәвам итү, балаларның әңгәмә вакытында җиңел һәм иркен аралашуларына ирешү, сүз байлыгын арттыру;<br>2) балаларның игътибарын, бергәләп тыңлау күнекмәсен үстерү;<br>3) сүз сәнгате белән кызыксыну тәрбияләү. |

## ӘТИЛӘР ҺӘМ ӘНИЛӘР, БАБАЙЛАР ҺӘМ ӘБИЛӘР (1.02—8.03)

### А. ТАНЫП БЕЛҮ ЭШЧӘНЛЕГЕ

| Тема | Бурычлар |
|---|---|
| Безнең әтиләр (сюжетлы рәсемнәр карау) | 1) балаларны әтиләр һөнәренә кагылышлы сюжетлы кечкенә рәсемнәр карарга, аларның эчтәлеген аңларга өйрәтү, эш-гамәлләрне белдерә торган сүзләр хисабына балаларның сүзлеген активлаштыру;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен, фикерләвен, куелган сорауларга кыска җөмлә белән җавап бирү осталыгын, сүз байлыгын үстерү;<br>3) төрле һөнәр кешеләренә һәм әтиләр хезмәтенә карата кызыксыну уяту. |
| Безнең апа (тәрбияче ярдәмчесенең хезмәтен күзәтү) | 1) тәрбияче ярдәмчесе хезмәте белән бәйле эшхәрәкәтләрне әйтергә өйрәтү (савыт-саба юа, ашарга алып килә, сөлгеләрне алмаштыра, бүлмәне җыештыра һ.б.), сүзлекне активлаштыру, яңа сүзләр белән баету, уенчыкларны күләмнәре (зур, кечкенә) буенча классификацияләргә өйрәтү;<br>2) балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерү, тәрбиячене ишетү һәм сорауларга җавап бирү, катлаулы булмаган биремнәрне үтәү осталыгына ирешү;<br>3) әйләнә-тирәдәге кешеләр хезмәтенә кызыксыну һәм тыңлаучанлык тәрбияләү. |

| | |
|---|---|
| «Алсу бәйрәмгә җыена» дидактик уены | 1) өс киемнәре, аларның төсе һәм материалы белән таныштыруны дәвам итү, сүзлекне активлаштыру: *ефәк, ак чәчәкле* кебек яңа сүзләр кертү;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен, фикерләвен, сорауларны ишетү, аларга бер сүз яки кыска җөмлә белән җавап бирү осталыкларын үстерү;<br>3) курчаклар белән уйнарга теләк уяту, уенчыкларга сакчыл караш тәрбияләү. |
| Безнең әниләр (сюжетлы рәсемнәр карау) | 1) балаларны әниләр һөнәренә кагылышлы сюжетлы кечкенә рәсемнәрнең эчтәлеген аңларга өйрәтү, эш-хәрәкәтне белдерә торган сүзләр хисабына балаларның сүз байлыгын киңәйтү;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен, куелган сорауларга кыска җөмлә белән җавап бирү осталыгын, игътибарын үстерү;<br>3) төрле һөнәр кешеләренә һәм әниләр хезмәтенә карата кызыксыну, хөрмәт тәрбияләү. |

**В.** СӨЙЛӘМ ҮСТЕРҮ ЭШЧӘНЛЕГЕ

| Тема | Бурычлар |
|---|---|
| «Шундый ук предметны тап» дидактик уены | 1) үз фикерләрен, грамматик яктан дөрес итеп, ике-өч сүздән торган гади җөмләләр белән белдерергә өйрәтү, гомумиләштерү күнекмәсе булдыру, предметларны чынбарлыкта һәм рәсемдә танырга өйрәтү, предметларның билгеләнешен ачыклау, предмет исемнәрен атау хисабына (*сабын, теш щёткасы, теш пастасы, сөлге*) һәм сөйләмдә кулланылган фигыльләр ярдәмендә сүзлекне активлаштыру һәм баету;<br>2) тәрбияче сорауларына гади җөмлә белән тулы җавап бирү осталыгына ирешү, игътибарны, сенсор тою сәләтен үстерү;<br>3) гигиена күнекмәләре тәрбияләү. |
| Машина һәм самолёт | 1) балаларны уенчыкларның өлешләрен, төсен, формасын аерырга һәм атарга өйрәтү; исемнәрне сыйфатлар белән яраклаштыру күнекмәләрен формалаштыруны дәвам итү, [у] сузык авазын әйтүдә күнектерү; *очучы, очып китү, очып төшү, йөк машинасы, самолёт* сүзләре хисабына сүзлекне активлаштыру, уенчыклар (машина, самолёт) белән таныштыруны дәвам итү;<br>2) балаларның *нинди? кайда? нәрсә ташый?* сорауларына гади җөмләләр белән җавап бирү осталыгына ирешү, игътибарын үстерү;<br>3) шофёр, очучы һөнәрләренә хөрмәт тәрбияләү. |

| | |
|---|---|
| Мәрьямне табыйк | 1) балаларны *кайда? кая?* сорауларына җавап бирергә, сөйләмдә *өстенә, артына, астына* сүзләрен кулланырга өйрәтү;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен үстерү;<br>3) уенга кызыксыну тәрбияләү. |
| Кына гөле | 1) балаларны бүлмә гөле — кына һәм аның өлешләре белән таныштыру; *сабак, яфрак, чәчәк* сүзләре хисабына сүзлекләрен активлаштыру;<br>2) балаларның зурлар белән аралашуын, аларны аңлауларын, күзәтүчәнлекләрен, игътибарларын үстерү;<br>3) бүлмә гөлләренә карата кызыксынучанлык, аларны карау теләге тәрбияләү. |

## С. МАТУР ӘДӘБИЯТ БЕЛӘН ТАНЫШТЫРУ

| Тема | Бурычлар |
|---|---|
| Ш. Маннурның «Яратам» шигырен уку | 1) шигырьнең эчтәлеген аңлап кабул итүләренә ирешү, [ә] авазын дөрес әйтергә күнектерү;<br>2) балаларның игътибарын, кабул итү сәләтен үстерү;<br>3) әти-әниләргә, туганнарга мәхәббәт тәрбияләү. |
| «Кәккүк-чыпчык» уены | 1) [ч], [к] һәм [қ] авазларын дөрес әйтергә өйрәтү, сүзлекне активлаштыру;<br>2) балаларның эмоциональлеген үстерү;<br>3) фольклор әсәрләре белән кызыксыну тәрбияләүне дәвам итү. |
| Г. Таһированың «Йокла, курчак» шигырен уку | 1) шигырьнең эчтәлеген аңлап кабул итүләренә ирешү; [ә], [ү] авазларын дөрес әйтергә күнектерү;<br>2) балаларның игътибарын үстерү;<br>3) курчакка карата кайгыртучанлык тәрбияләү. |

| | |
|---|---|
| Ә. Кариның «Тавык» шигырен уку | 1) шигъри әсәрне тыңларга өйрәтүне дәвам итү, фланелеграфта шигырь эчтәлегенә туры килгән рәсемнәр яки уенчыклар күрсәтү; кайбер фразаларны кабатлатып, балаларның сөйләмен активлаштыру;<br>2) балаларның игътибарын, кабул итү сәләтен, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;<br>3) әбиләргә карата ихтирам, ярату хисләре тәрбияләү. |
| Ә. Шәрифуллинаның «Иң матур әни» шигырен уку | 1) шигъри әсәрне тыңларга өйрәтүне дәвам итү; кайбер фразаларны кабатлатып, балаларның сөйләмен активлаштыру;<br>2) балаларның игътибарын, кабул итү сәләтен, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;<br>3) әниләргә карата ихтирам, ярату хисләре тәрбияләү. |

## ХАЛЫК ИҖАТЫ (9.03. — 20.03.)

### **А.** ТАНЫП БЕЛҮ ЭШЧӘНЛЕГЕ

| Тема | Бурычлар |
|---|---|
| Матрёшкалар | 1) балаларны халык иҗат иткән уенчыклар (матрёшкалар) белән таныштыруны дәвам итү, матрёшканы ачарга һәм дөрес итеп җыярга өйрәтү; сүз байлыгын киңәйтү һәм активлаштыру, балаларны үзләренә әйтелгән (мөрәҗәгать ителгән) сүзләрне тыңларга күнектерү;<br>2) игътибарны, хәтерне, сенсор тою сәләтен, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;<br>3) халык иҗатына кызыксыну, уенчыкларга (матрёшкага) карата сакчыллык тәрбияләү. |
| Матрёшкалар | 1) уенчыкның (матрёшканың) исемен дөрес әйтергә, төсендә һәм зурлыгында булган аермалыкларны күрә белергә күнектерү; *зур, кечкенә, сарафан, яулык* сүзләре хисабына сүзлекне активлаштыру;<br>2) балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;<br>3) балаларда халык уенчыкларына карата кызыксыну тәрбияләү. |

## **В.** СӨЙЛӘМ ҮСТЕРҮ ЭШЧӘНЛЕГЕ

| Тема | Бурычлар |
|---|---|
| Бармак уены белән таныштыру. «Йорт хайваннары» уен күнегүе | 1) халык авыз иҗаты белән таныштыруны дәвам итү, катлаулы булмаган фразаларны куллануда күнектерү, йорт хайваннарының исемнәрен ныгыту; *мөгри, кычкыра, мияулый, өрә* фигыльләре хисабына балаларның сүзлеген активлаштыру; [м], [у] авазларын дөрес әйтергә өйрәтү;<br>2) хәтерне, кабул итү сәләтен, авазларны әйтү күнекмәләрен үстерү;<br>3) халык авыз иҗатына, йорт хайваннарына карата кызыксыну тәрбияләү. |
| «Чуар тавык» әкиятен уку | 1) балаларны халык авыз иҗаты әсәрләре белән таныштыруны дәвам итү, әкиятне тыңлау теләге тудыру; *чуар, күкәй, алтын, гади, тычкан* кебек сүзләр хисабына балаларның сүзлеген баету;<br>2) тәрбияче башлаган җөмләне дәвам итү осталыгын, хәтерне, игътибарны, кабул итү сәләтен үстерү;<br>3) әкият персонажларына карата кызыксыну тәрбияләү. |

## **С.** МАТУР ӘДӘБИЯТ БЕЛӘН ТАНЫШТЫРУ

| Тема | Бурычлар |
|---|---|
| «Йомры икмәк» рус халык әкиятен уку | 1) балаларны «Йомры икмәк» әкияте белән таныштыру, әкиятнең эчтәлеген аңларга ярдәм итү, шар әвәләү күнекмәсен ныгыту, сорауларга җавап бирү осталыгына өйрәтүне дәвам итү;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын, активлыгын үстерү;<br>3) әкият белән кызыксындыру. |
| «Йомры икмәк» әкиятен кабатлау | 1) әкиятне тәрбияче белән бергә сөйләргә өйрәтү; аерым фразаларны кабатлатып, балаларның сүз байлыгын активлаштыру;<br>2) балаларның игътибарын, кабул итү сәләтен үстерү;<br>3) әкият геройлары белән кызыксындыру. |
| «Теремкәй» рус халык әкиятен уку | 1) балаларны яңа әсәр белән таныштыру, әкиятне аңлап тыңларга өйрәтү;<br>2) балаларның игътибарын үстерү;<br>3) халык иҗатына карата кызыксыну тәрбияләү. |
| «Теремкәй» әкиятен сәхнәләштерү | 1) әкият белән таныштыруны дәвам итү; балаларны сәхнәләштерү эшчәнлегенә җәлеп итү, уен барышында фразаларны дөрес әйтү осталыгына ирешү;<br>2) балаларның игътибарын, кабул итү сәләтен, активлыгын үстерү;<br>3) әкиятләр белән кызыксыну тәрбияләүне дәвам итү. |

## ЯЗ (1.04 — 30.04)

### **А.** ТАНЫП БЕЛҮ ЭШЧӘНЛЕГЕ

| Тема | Бурычлар |
|---|---|
| Яз, яз килә... | 1) балаларга язгы күренешләр турында башлангыч белемнәр (кар эри, тамчы тама, кояш җылыта, сулар җыела) бирү, сүз байлыгын киңәйтү һәм активлаштыру;<br>2) балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын үстерү;<br>3) табигатьтәге язгы күренешләр белән кызыксындыру. |
| Җәнлекләр урманда яшиләр | 1) җәнлекләр турында балаларның белемнәрен киңәйтү һәм ныгыту, җәнлекләрне таный һәм исемнәрен атый белергә өйрәтү;<br>2) балаларның диалогик сөйләмен активлаштыру, фикерләвен, мөстәкыйльлеген үстерү;<br>3) җәнлекләр белән кызыксындыру. |
| Сыерчыклар, карлыгачлар килде (рәсемнәр карау) | 1) балаларны үзләренә таныш кошларны рәсемнән танырга, исемнәрен әйтергә өйрәтү; балаларның сүз байлыгын арттыру, сүзлеккә *сыерчык, сыерчык оясы, карлыгач* сүзләрен кертү;<br>2) игътибарны, күзәтүчәнлекне, тәрбияче белән аралашу, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;<br>3) кошлар һәм табигать белән кызыксынуларына ирешү, кошларга карата мәрхәмәтлелек, кайгыртучанлык тәрбияләү. |
| Песиле тал бөреләрен карау | 1) балаларны песиле тал, аның өлешләре (ботаклар, бөреләр) белән таныштыру, табигатьтәге язгы күренешләр турында белемнәр формалаштыруны дәвам итү, сүз байлыгын киңәйтү һәм *песиле тал, ботак, бөре, йомшак, хуш исле* сүзләре исәбенә сүзлекне активлаштыру;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын, күзәтүчәнлеген, хәтерен, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;<br>3) табигать белән кызыксыну, табигать матурлыгына соклану хисләре тәрбияләү. |

### **В.** СӨЙЛӘМ ҮСТЕРҮ ЭШЧӘНЛЕГЕ

| Тема | Бурычлар |
|---|---|
| Бүлмә гөлләре (фикус, яран) | 1) балаларның гади сорауларга җавап бирү осталыгын камилләштерү, бүлмә гөлләренең өлешләрен өйрәтү, аларның сыйфат билгеләрен белдерә торган сүзләр хисабына сүзлекне баету;<br>2) гөлләр белән кызыксынуларын үстерү;<br>3) өлкәннәргә гөлләрне карарга ярдәм итү теләге тәрбияләү. |

| | |
|---|---|
| Йөк машинасы | 1) машина, аның өлешләре турында балаларның белемнәрен арттыру, ком һәм аның үзлекләре белән таныштыру; машинаның төрен, өлешләрен, комның үзлекләрен белдерә торган исемнәр, сыйфатлар хисабына сүзлекне активлаштыру; [в], [п] авазларының дөрес әйтелүдә күнектерү;<br>2) кызыксынучанлыкны, кабул итү сәләтен үстерү;<br>3) тәрбияче һәм яшьтәшләре белән аралашу теләге тәрбияләү. |
| Язгы урманда | 1) *кайда? нинди?* сорауларына җавап бирергә өйрәтү; *өстә, агач төбендә* сүзләрен куллану хисабына сөйләмнең грамматик төзелешен камилләштерү; аваз иярттемнәрен ачык, төгәл әйтүдә күнектерү, [ш] авазының әйтелешен ныгыту, ел фасылларына бәйле табигатьтәге үзгәрешләр турындагы белемнәрне формалаштыруны дәвам итү;<br>2) балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерү;<br>3) табигать объектларына сакчыл караш тәрбияләү. |
| Бозау, бәрән, колын, кәҗә бәтие, сез кайда? | 1) балаларның йорт хайваннары турындагы белемнәрен киңәйтү; *бозау, бәрән, колын, кәҗә бәтие* сүзләре хисабына сүзлекне баету һәм активлаштыру; тәрбияче күрсәтмәләрен үтәү осталыгы формалаштыру;<br>2) игътибарны, хәтерне үстерү;<br>3) башкаларга ярдәм итү теләге, тыңлаучанлык, хайваннарга карата кайгыртучанлык тәрбияләү. |

## С. МАТУР ӘДӘБИЯТ БЕЛӘН ТАНЫШТЫРУ

| Тема | Бурычлар |
|---|---|
| Ш. Галиевнең «Яз» шигырен уку | 1) балаларның шигъри әсәрне аңлап кабул итүләренә ирешү, язгы табигать турында мәгълүмат бирү; [т] авазын, *тып* аваз иярттемен дөрес әйтергә күнектерү, сүз байлыгын киңәйтү һәм активлаштыру;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын, кызыксынучанлыгын үстерү;<br>3) язгы табигать күренешләре белән соклану хисе тәрбияләү. |
| «Тор-тор, тургай» такмагын уку | 1) такмакның эчтәлеге белән таныштыру, [т] авазын дөрес әйтергә күнектерү, аваз иярттемнәре хисабына балаларның сүз байлыгын арттыру;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын, хәтерен үстерү;<br>3) фольклор әсәрләре белән кызыксындыруны дәвам итү. |

| | |
|---|---|
| «Тук, тук, тукран» эндәшен уку | 1) шигъри текстны тыңлау осталыгы формалаштыру, кошлар белән таныштыруны дәвам итү, аваз ияртемнәрен кабатлау, [т], [к] һәм [қ] авазлары кергән сүзләрне дөрес әйтергә өйрәтү;<br>2) балаларның игътибарын үстерү;<br>3) кошларга карата шәфкатьлелек тәрбияләү. |
| «Кояш, чык, чык» эндәшен уку | 1) балаларга эндәшнең эчтәлеген аңларга, сюжетны истә калдырырга ярдәм итү;<br>2) балаларның тыңлый белү осталыгын, уңай эмоцияләрен үстерү;<br>3) күмәк эшчәнлек белән кызыксындыру. |
| Р. Батулланың «Нурбәк» әкиятен уку | 1) әкиятне игътибар белән тыңларга өйрәтүне дәвам итү; [а], [у], [ә] сузык авазларын дөрес әйтергә күнектерү, уенчыкларда әкият персонажларын танырга һәм атарга өйрәтү;<br>2) балаларның игътибарын үстерү;<br>3) әкият геройлары белән кызыксыну тәрбияләү. |
| К.Д. Ушинскийның «Казлар» хикәясен уку | 1) казларны һәм үрдәкләрне аера белергә өйрәтү, хикәяне күрсәтмәлелек кулланмыйча аңлап кабул итүләренә ирешү, күплек һәм берлек саннардагы исемнәрне аерырга һәм дөрес кулланырга күнектерү;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын, хәтерен, тәрбиячөнең күрсәтмәләрен үти алу осталыгын үстерү;<br>3) йорт кошлары белән кызыксыну тәрбияләү. |

## ҖӘЙ (1.05 — 31.05.)

### А. ТАНЫП БЕЛҮ ЭШЧӘНЛЕГЕ

| Тема | Бурычлар |
|---|---|
| Тузганак чәчәген карау | 1) балаларны үсемлекләр белән таныштыруны дәвам итү, тузганак чәчәген күрсәтү, аны танырга, исемен әйтергә, төзелеше (чәчәге, сабагы, яфраклары) буенча аера белергә өйрәтү; сүз байлыгын киңәйтү; *тузганак, чәчәк, сабак* сүзләрен сөйләмдә активлаштыру;<br>2) балаларның сенсор тою һәм кабул итү сәләтен, игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерү;<br>3) табигать белән турыдан-туры аралашудан шатлык хисләре уяту, үсемлекләргә сакчыл караш тәрбияләү. |

| | |
|---|---|
| Йорт хайваннары | 1) балаларның йорт хайваннары (сыер, ат, песи, эт) турындагы белемнәрен (кайда яшиләр, нәрсә ашыйлар) киңәйтү, хайваннарның исемнәрен, хәрәкәтләрен әйтергә күнектерү;<br>2) сүзлекне баету, тәрбияченең сорауларына җавап бирү, мөстәкыйльлек һәм активлык күрсәтү теләген үстерү;<br>3) йорт хайваннарына карата кызыксыну тәрбияләү. |
| Балалар тавык һәм чебиләр ашата (рәсем буенча) | 1) балаларны рәсемне карарга, эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә, тәрбияче һәм иптәшләрен тыңларга өйрәтүне дәвам итү;<br>2) сөйләмне *томшык, тавык, чебиләр, табак* сүзләре хисабына баету, игътибарны, хәтерне, образлы фикерләүне үстерү;<br>3) йорт кошларына карата мәрхәмәтлелек тәрбияләү. |
| Ком һәм аның үзлекләре | 1) балаларны комны тикшерергә (комны учка алырга, йомарларга һәм сибәргә), төсе буенча аның дымлылыгын билгеләргә өйрәтү;<br>2) *коры, дымлы, юеш, сибелүчән, сибелә, әвәләү* сүзләре хисабына балаларның сүз байлыгын киңәйтү, игътибарын, сенсор тою сәләтен үстерү;<br>3) ком белән уйнарга кызыксындыру. |

## В. СӨЙЛӘМ ҮСТЕРҮ ЭШЧӘНЛЕГЕ

| Тема | Бурычлар |
|---|---|
| Балалар бакчасы ишегалдында | 1) исемнәр, фигыльләр, сыйфатлар хисабына сүз байлыгын үстерү; фигыльләрне һәм сыйфатларны исемнәр белән яраклаштыруда күнектерү, балаларны бакча ишегалдында үсә торган үсемлекләр исеме белән таныштыруны дәвам итү, табигатьтәге сезонлы үзгәрешләр турында белемнәрне киңәйтү;<br>2) төсләрне, матурлыкны белдерүче сыйфатлар ярдәмендә сөйләм теле компонентларын үстерү;<br>3) табигать объектларына карата кызыксыну, хезмәткә хөрмәт тәрбияләү. |
| Кызыксынучан тел | 1) балаларны [т], [д], [к], [к] авазлары кергән аваз ияртемнәрен әйтергә өйрәтү, аваз ияртемнәрен төрле югарылыктагы тавыш (калын, нечкә) белән әйтүдә күнектерү; [т], [д], [к], [к] авазларын сүзләрдә, фразаларда әйтүне ныгыту;<br>2) [т], [д], [к], [к] авазларын әйтү хисабына сөйләм үстерү, балаларның фантазиясен баету;<br>3) игътибарлылык тәрбияләү. |

| | |
|---|---|
| Зоопарк | 1) җылы якта яшәүче хайваннар белән таныштыру, сөйләмдә исемнәрне берлек һәм күплек саннарда кулланырга өйрәтүне дәвам итү;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын үстерү;<br>3) җылы як хайваннарына карата мәрхәмәтлелек тәрбияләү. |
| Рәхмәт, җәй! | 1) балаларны яшелчәләрне, җиләк-җимешләрне тәме буенча аерырга өйрәтүне дәвам итү; яшелчәләр, җиләк-җимешләр, агачлар турындагы белемнәрне киңәйтү;<br>2) балаларның игътибарын, кабул итү сәләтен үстерү;<br>3) табигатькә карата сакчыл караш тәрбияләү. |

## С. МАТУР ӘДӘБИЯТ БЕЛӘН ТАНЫШТЫРУ

| Тема | Бурычлар |
|---|---|
| Ә.Кариның «Чебиләр» шигырен уку | 1) күрсәтмәлелек кулланмыйча, шигъри әсәрне тыңларга өйрәтү, [ч] авазын дөрес әйтергә күнектерү;<br>2) балаларның уңай эмоцияләрен үстерү;<br>3) йорт кошларына карата кайгыртучанлык тәрбияләү. |
| С. Сөләйманованың «Кызыл әтәч» шигырен уку | 1) шигъри әсәрне тыңларга өйрәтү, гади сорауларга җавап бирү теләге уяту, аваз ияртемнәрен өйрәтүне дәвам итү;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын, хәтерен, тәрбияче күрсәтмәләрен үтәү осталыгын үстерү;<br>3) йорт кошларына карата шәфкатьлелек тәрбияләү. |
| Д. Гарифуллинның «Мыраубикә» шигырен уку | 1) шигырь ярдәмендә песи белән таныштыруны дәвам итү, песи турында мәгълүматларны ныгыту һәм киңәйтү; *мыр-мыр, гыр-гыр* аваз ияртемнәрен өйрәтү;<br>2) сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;<br>3) песиләргә карата кайгыртучанлык тәрбияләү. |

# ТАНЫП БЕЛҮ ЭШЧӘНЛЕГЕ

## *Беренче бүлек.* БЕЗНЕҢ БАЛАЛАР БАКЧАСЫ

### Тема. ЧИШЕНҮ БҮЛМӘСЕН КАРАУ

**Бурычлар:**

1) балаларны чишенү бүлмәсе, андагы җиһазлар белән таныштыру, төркемдәге (группадагы) бүлмәләрдә ориентлашу тәҗрибәсе туплау;

2) балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын, диалогта катнашу теләген үстерү;

3) җиһазларга сакчыл караш тәрбияләү.

**Җиһазлар:** уенчык куян.

**Эшчәнлек барышы.**

Чишенү бүлмәсенең ишеге ачык. Аннан балаларга таныш булмаган музыкаль уенчык тавышы ишетелә.

Тәрбияче. Балалар, нинди тавыш бу? Каян килә икән ул? Әйдәгез, эзләп карыйк әле! (Балалар тәрбияче белән бергә чишенү бүлмәсенә чыгалар, уенчыкны эзләп табалар.) Менә ул! (Куян уенчыгын күрсәтә.) Нәрсә бу? (*Куян.*) Әйе, бу — Куян-Озынколак. Әйдәгез, Куян-Озынколак белән исәнләшегез! (*Исәнме, Куян-Озынколак!*) Балалар, Куян-Озынколак менә бу урындыкка утырсын. Утыр, Куян-Озынколак! Балалар, әйдәгез, сез дә Куян-Озынколакка утыр дип әйтегез. (*Утыр, Куян-Озынколак!*) (Активлаштыру.) Бүгеннән башлап, ул сезне каршы алыр, озатып калыр. Балалар, сез бу бүлмәдә нәрсәләр күрәсез? (*Шкафлар, эскәмияләр.*) Әйе, нинди матур уңайлы шкафлар! Шкафлар ни өчен кирәк? (*Киемнәрне кую өчен.*) Шкафлар азмы, әллә күпме? (*Күп.*) Сез үз шкафыгызны таныйсызмы? Кайсы шкаф кемнеке икәнен ничек белергә? (*Шкафның ишегендә рәсем ясалган.*) (Балалар әйтә алмасалар, тәрбияче аларның игътибарын шкафтагы рәсемгә юнәлтә.) Хәзер һәрберегез үзегезнең шкаф янына басыгыз. Сезнең шкаф ишегенә нинди рәсем ясалган? Марат (Алсу, Энҗе, Ренат һ.б.), синең шкаф ишегенә нинди рәсем ясалган? (Активлаштыру).

Тәрбияче һәм балалар, шкафларны ачып карап, аның эчендә элгеч, өстә һәм аста киштәләр куелган булуын ачыклыйлар.

Тәрбияче. Балалар, киемнәрне шкафка матур һәм пөхтә итеп төреп куярга кирәк. Ни өчен матур итеп төрергә кирәк?(*Бөгәрләнмәсен өчен.*) (Күмәк һәм аерым кабатлаулар.) Балалар, шкафларны чиста итеп тотарга тырышыгыз. Ишекләрен каты итеп япмагыз, шкафлар ватылмасыннар.

Шкафларны сакларга кирәк, алар гел шулай матур булып торсыннар!

Балалар, Куян-Озынколак һәр көнне сезнең киемнәрегезне ничек төргәнне, шкаф ишекләрен ничек ачканны, япканны карап торыр. Бүген сез Куян-Озынколакка бик ошадыгыз. Ул сезне мактый. Әйдәгез, үзебезне мактап кул чабыйк әле. (Балалар кул чабалар.)

## Тема. ЙОМШАККАЙ БЕЗДӘ КУНАКТА

**Бурычлар:**

1) балаларның уенчыклар турындагы белемнәрен киңәйтү, тәрбияче сорауларына җавап бирү осталыгын формалаштыру, уенчык исемнәрен һәм аларның эш-хәрәкәтен белдерә торган сүзләр хисабына сүз байлыгын арттыру;

2) тыңлау һәм сорауларга җавап бирү теләген үстерү;

3) сөйләм этикетының гади формаларын (исәнләшү, саубуллашу) кулланырга гадәтләндерү, уенчыкларга сакчыл караш тәрбияләү.

**Җиһазлар:** Йомшаккай исемле уенчык песи.

### Эшчәнлек барышы.

Йомшаккай керә.

Йомшаккай. Исәнмесез, балалар! Мин — Йомшаккай. Сезгә кунакка килдем. Исәнме, Марат! (Алия, Динә, Зилә һ.б. Йомшаккай балалар янына килеп исәнләшә. Тәрбияче балаларны уенчыклар тезеп куелган келәм янына алып килә.)

Тәрбияче. Балалар, әйдәгез, келәм янына барыйк әле. Йомшаккай, әйдә син дә безнең белән. Балалар, келәмгә нәрсәләр тезеп куелган? (*Курчаклар, машиналар, туплар* һ.б.) Бик дөрес! Курчак, машина, туп — болар нәрсәләр? (*Уенчыклар.*) (Әйтә алмасалар, тәрбияче балаларга ярдәм итә, әйтеп җибәрә.) Балалар, бу нәрсә? (Курчакны алып күрсәтә.) Бу — курчак. (Активлаштыру.) Курчакның исеме — Алсу. (Активлаштыру.) Карагыз әле, Алсу нишли? (Тәрбияче кур-

чакны йөртеп карый. Балаларның җаваплары тыңлана.) Балалар, әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: «Курчак йөри». (Активлаштыру.) Балалар, Алсуны Йомшаккай янына утыртыйк. Алсу, утыр Йомшаккай янына. Әйдәгез, сез дә кабатлагыз: «Утыр, Алсу!» (Активлаштыру. Тәрбияче машина уенчыгын алып күрсәтә.) Бу нәрсә? (*Машина.*) (Активлаштыру. Тәрбияче машинаны йөртеп күрсәтә.) Машина нишли? (*Йөри.*) (Активлаштыру. Тәрбияче машинаның сигнал бирү тавышын чыгара.) Машина тагын нәрсә эшли? (*Кычкырта, сигнал бирә.*) (Активлаштыру.) Машина ничек итеп сигнал бирә? (*«Би-биип».*) Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз: «би-биип». (Активлаштыру.) (Тәрбияче тупны күрсәтә.) Ә менә бу нәрсә? (*Туп.*) Туп нинди төстә? (Активлаштыру). Туп нинди формада? (*Шар формасында.*) (Балалар әйтә алмаса, тәрбияче үзе әйтә. Тәрбияче тупны сикертеп карый.) Туп нишли?(*Сикерә.*) (Активлаштыру.) Балалар, әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: «Туп сикерә». (Тәрбияче тупны тәгәрәтеп карый.) Туп нишли? (*Туп тәгәри.*) (Активлаштыру.) Балалар, әйдәгез, кабатлыйк: «Туп тәгәри». Балалар, Йомшаккай сезгә туплар алып килгән. Әйдәгез, туплар белән уйнап алыйк. (Тәрбияче һәм балалар келәмгә утыралар. Тәрбияче, тупны алып, Маратка таба тәгәрәтә.) Марат, тот тупны тизрәк! (Марат тупны тотып ала, тәрбияче аны башка балага тәгәрәтеп җибәрергә куша.) Марат, ә хәзер туп кемгә кунакка бара? (Тәрбияче балага ярдәм итә.) Туп Гүзәлгә тәгәри. (Шулай итеп, туп һәрбер балада булып чыга.)

Балалар, сез Йомшаккайга бик ошадыгыз. Ул сезнең матур итеп сөйләшә, туп тәгәрәтә белүегезгә бик куанды. Булдырдыгыз! Әйдәгез, Йомшаккай белән саубуллашыгыз. (*Сау бул, Йомшаккай!*) (Активлаштыру.) Булдырдыгыз, балалар! Балалар, әйдәгез, үзебезне мактап кул чабып алыйк әле! Исән-сау гына булыгыз!

## Тема. ЙОМШАККАЙ ТАГЫН БЕЗДӘ КУНАКТА

**Бурычлар:**

1) уенчыкларны карарга һәм аларның аерым өлешләрен билгеләргә өйрәтү, уенчыкларның исемнәрен, өлешләрен әйтү; төсен, хәрәкәтен белдерә торган сүзләрне актив сүзлеккә кертү;

2) тәрбияче соравына кычкырып җавап бирү осталыгын үстерү;

3) сөйләм этикетының гади формаларын (исәнләшү, саубуллашу) кулланырга гадәтләндерү, кызыклы уенчыклар белән уйнаудан тәм табу, шатлык хисләре тәрбияләү.

**Җиһазлар:** Йомшаккай исемле уенчык песи, төрле кызыклы уенчыклар: әтәч, тавык, чеби һ.б., «Чебиләр зарядкасы» (Л. Хәйретдинова көе, М. Фәйзуллина сүзләре) җырының аудиоязмасы.

**Эшчәнлек барышы.**

Кулына «тылсымлы» тартма тотып, Йомшаккай керә.

Тәрбияче. Балалар, безгә кунак килгән. Нинди кунак? (*Йомшаккай.*) Әйе, Йомшаккай. Исәнме, Йомшаккай! Балалар, карагыз әле, Йомшаккай нәрсә алып килгән? (*Тартма.*) (Активлаштыру.) Әйе, «тылсымлы» тартма. Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: «тылсымлы» тартма». Йомшаккай, син утырып тор, ә без балалар белән тартманы карыйк. (Тәрбияче тартманы ала һәм әкрен генә селкетә.) Балалар, тартма эчендә нәрсә бар икән? Ачмыйча гына, тартма эчендә нәрсә бар икәнен әйтеп буламы? (*Юк.*) Дөрес, балалар, тартманы ачып карарга кирәк. Әгәр дә мин тартма эчендәге уенчык «кикрикүүк» дип кычкыра дисәм, сез аның нәрсә икәнен әйтә аласызмы? (Балалар әйтә алмасалар, өстәмә сорау бирелә.) Нәрсә «кикрикүүк» дип кычкыра? (*Әтәч.*) (Активлаштыру. Тәрбияче, тартманы ачып, әтәчне ала.) Бу нәрсә? (*Әтәч.*) Әйдәгез, әтәч белән исәнләшик әле: «Исәнме, әтәч!» (Исәнләшкәч, тәрбияче әтәчне балаларга якын китерә, алар аны тотып карый, сыйпый алалар. Борып әйләндерә торган уенчык булса, тагын да отышлы.) Әтәчнең башын күрсәтегез әле. Марат (Алия, Илһам, Айсылу һ.б.), син әтәчнең кайсы җирен күрсәттең? (Активлаштыру.) Әтәчнең башында нәрсәләре бар? (*Күзләре, томшыгы, кикриге.*) (Активлаштыру.) Әтәчнең тагын нәрсәләре бар? (*Канатлары, койрыгы, тәпиләре.*) (Тәрбияче балаларны әтәчнең өлешләрен күрсәтергә чакыра һәм бергәләп кабатларга тәкъдим итә. Тәрбияче уенчык әтәчне кычкырта.) Әтәч нишли? (*Кычкыра.*) Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк: «Әтәч кычкыра». (Активлаштыру.) Әтәч ничек кычкыра? («*Кикрикүүк*».) Балалар, әтәч менә шулай канатларын кага, җилпи. (Тәрбияче хәрәкәтләрне күрсәтә.) Әйдәгез, әтәчнең ничек итеп канат какканын күрсәтик әле. (Балалар күрсәтәләр.) Хәзер канатларын матур итеп җилпеп, кагынып кычкыра торган әтәч булып күрсәтегез әле. Менә шулай! (Активлаштыру. Тәрбияче әтәчне тагын бер тапкыр борып әйләндерә.) Менә нинди кызыклы әтәч! (Тәрбияче тартманы тагын бер тапкыр селкетә.) Тартма эчендә тагын нәрсәдер бар. Ул күкәй сала. Нәрсә икән ул? (*Тавык.*) (Активлаштыру.)

Әйдәгез, исәнләшик әле: «Исәнме, тавык!» (Исәнләшәләр. Тәрбияче тавыкны балаларга якын китерә, алар аны тотып карый, сыйпый алалар. Тәрбияче уенчыкны борып әйләндерә, тавык йөреп китә.) Тавык нишли? (*Йөри.*) Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк: «Тавык йөри». (Активлаштыру.) Тавык ничек кычкыра? (Кычкыра торган уенчык булса кычкыртып карый.) Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк: «кыт-кытыйк». (Активлаштыру.) Тавыкның башын күрсәтегез әле. Алсу, син тавыкның нәрсәсен күрсәттең? (Активлаштыру.) Ә тавыкның башында нәрсәләре бар? (*Башында күзләре, томшыгы, кикриге бар.*) (Активлаштыру.) Тавыкның тагын нәрсәләре бар? (*Канатлары, койрыгы, тәпиләре.*) (Активлаштыру. Тәрбияче балаларны берәм-берәм чакыра һәм тавыкның аерым өлешләрен күрсәттерә, кабатлата. Тәрбияче уенчыкны тагын бер тапкыр борып әйләндерә, тавык «күкәй сала».) Тавык нәрсә сала? (*Күкәй.*) (Активлаштыру.) Күкәй салганда, тавык «кыт-кытыйк» дип кычкыра. Әйдәгез, тавык тавышын бергәләп кабатлыйк: «кыт-кытыйк». (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар.) Әйе, ул: «Кыт-кытыйк, кыт-кытыйк, мин күкәй салдым, чыгып алыгыз», — ди. (Балалар тәрбияче белән бергәләп кабатлыйлар.) Балалар, тартма эчендә әле тагын нәрсәдер калган. (Тартманы селкетә һәм берәр баладан тартманың капкачын ачтыра. Бала, тартманы ачып, уенчык чебине ала.) Балалар, бу нәрсә? (*Чеби.*) Чеби зурлыгы буенча нинди: зурмы, кечкенәме? (*Кечкенә.*) (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар.) Чеби нинди төстә? (*Сары.*) Әйе, сары чеби. (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар.) Чеби нинди тавыш чыгара? (*«Чип-чип».*) (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар.) Ничек уйлыйсыз, чеби йомшакмы? Балалар, чебине тотып карагыз, яратып сыйпагыз әле. Әйе, ул йомшак. (Активлаштыру. Тәрбияче уенчык чебинең җим чүпләгәнен күрсәтә.) Чеби нишли? (*Җим чүпли, чирәм ашый.*) (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар.) Балалар, чебиләр зарядка ясарга яраталар. Әйдәгез, без дә чебиләр белән зарядка ясыйбыз:

Нәни чебиләр барсы да
Сары майка кигәннәр.
Зарядка ясарга диеп,
Бер урынга килгәннәр.
Корт, корт, корт, корт,
Бер урынга килгәннәр.

Балалар җыр тыңлыйлар һәм күнегүләр ясыйлар.

Тәрбияче. Йомшаккай, күрдеңме, безнең балалар нинди акыллы һәм игътибарлы. Сорауларга җавап бирәләр, зарядка ясыйлар, көләләр, шатлананалар. Булдыралар! Әйдәгез, үзебезне мактап кул чабыйк. (Балалар кул чабалар.)

## Тема. ТУПНЫ КОТКАРАБЫЗ
## (рәсем буенча)

**Бурычлар:**

1) рәсемнең эчтәлеген аңларга ярдәм итү, эчтәлек буенча сорауларга җавап бирергә өйрәтү;

2) балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын, тәрбияче артыннан аерым сүзләрне һәм фразаларны актив кабатлауларын үстерү;

3) башкаларга ярдәм итү теләге тәрбияләү.

**Җиһазлар:** «Тупны коткарабыз» рәсеме, Йомшаккай исемле уенчык песи, кызыл туп, «тылсымлы» капчык, «Туп» җырының (М. Әндерҗанова көе һәм сүзләре) аудиоязмасы, су салынган таз (туп өчен).

### Эшчәнлек барышы.

Балалар алдында рәсем эленгән мольберт тора. Рәсем каплап куелган.

Тәрбияче. Балалар, Йомшаккай безгә «тылсымлы» капчык алып килгән. Аның эчендә нәрсә бар икән? Карамыйча гына әйтеп буламы? (*Юк.*) Әмир, кил әле, «тылсымлы» капчыктагы әйберне алып кара әле, нәрсә икән ул? Әмир, син нәрсә алдың? (*Туп.*) Балалар, Әмир нәрсә алды? (*Туп.*) (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар.) Туп нәрсәгә охшаган? (*Шарга.*) Әйдәгез, кулларыгыз белән шар ясап күрсәтегез әле. (Кул бармакларын бер-берсенә якын китереп, шар ясап күрсәтәләр.) Менә нинди ул шар! Булдырдыгыз! Балалар, туп нинди төстә? (*Кызыл.*) Әйе, кызыл туп. Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз әле: «кызыл туп». (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар.) Балалар, тагын нинди төстәге туплар була? (Активлаштыру.)

Тәрбияче тупны сикертеп карый. Бу вакытта аудиоязмада «Туп» исемле җыр яңгырый.

Туп-туп, матур туп,
Сикер, сикер, матур туп!
Бер-ике, бер-ике!
Сикер, сикер, матур туп!

Тәрбияче. Балалар, туп сикерәме? (*Сикерә.*) Әйе, туп сикерә. Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз әле: «Туп сикерә». (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, Әминә исемле

бер кыз туп белән уйнарга бик яраткан. Әйдәгез әле, Әминә турында рәсем карыйк. (Тәрбияче мольберттагы рәсемне ача һәм балаларга карарга мөмкинлек бирә. Аннан рәсем буенча әңгәмә оештыра.) Йомшаккай да рәсемне карасын. (Тәрбияче аны утыртып куя.) Туп Йомшаккай янында торсын, аннан соң без аның белән уйнарбыз. Балалар, рәсемдә кемнәр бар? (*Бер малай, бер кыз.*) (Активлаштыру.) Әмир, кил әле, рәсемдәге малайны күрсәт әле. (Күрсәтә.) Булдырдың, Әмир! Гүзәл, кил әле, рәсемдәге кызны күрсәт әле. (Күрсәтә.) Булдырдың, Гүзәл! Рәсемдәге кызның исеме — Әминә. Әйдәгез, малайга да исем бирегез. (Активлаштыру.) Ярар, малайның исеме Камил булсын. Бу исемне Марат уйлап тапты. Булдырдың, Марат! Бик матур исем. Малайның исеме ничек? (*Камил.*) (Активлаштыру.) Балалар, Әминә туп белән уйнарга бик яраткан. Көтмәгәндә туп тәгәрәп киткән һәм җыелып торган суга төшкән. Балалар, туп суга төшкәч, Әминә кайгырганмы? (Балаларның җаваплары.) Әйе, балалар, Әминә бик кайгырган, елый башлаган. Балалар, Әминә нигә елый? (*Тубы суга төшкән.*) (Активлаштыру.) Әйе, балалар, туп тәгәрәп киткән дә җыелып торган суга төшкән. Әминә янында кем басып тора? (*Камил басып тора.*) (Активлаштыру.) Камил нишли? (*Тупны судан чыгара. Тупны таяк белән тарта.*) (Активлаштыру. Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар.) Әйе, балалар, Камил Әминәгә ярдәмгә килгән. Ул тупны судан таяк белән тартып чыгарырга тырыша. Камил — ярдәмчел малай. Камил Әминәне юата: «Чү, Әминә, елама, туп батмый ул елгада»,— ди. Әйдәгез, сез дә бергәләп кабатлагыз, Әминәне юатыгыз. (Кабатлыйлар.) Балалар, Камилнең тупны судан таяк белән тартып чыгаруын күрсәтегез әле. Ул бик тырыша. (Балалар хәрәкәтне күрсәтәләр.) Булдырдыгыз! Камил урынында булсагыз, сез дә Әминәгә булышыр идегез. Әйдәгез, балалар, Йомшаккай алып килгән тупны суга салып карыйк әле. Тупның суда батмавын тагын бер кат күрегез әле. (Тәрбияче тупны таздагы суга сала.) Балалар, туп суда батамы? (Активлаштыру.) Хәзер туп белән уйнап алабыз. Балалар, түгәрәк ясап басыгыз әле. Мин уртага басам һәм сезгә тупны ыргытып әйтәм:

Матур бит туп, күр әле,
Алсу (Гүзәл, Марат, Ренат һ.б.),
Мә, син тупны тот әле.
Балалар, тупны кем тотты,
Кабат миңа ыргытты?

Балалар тупны тоткан баланың исемен әйтәләр. Тәрбияче һәр балага туп ыргытып чыга. Бала, тупны тоткач, аны тәрбиячегә бирә.

Тәрбияче. Балалар, булдырдыгыз! Сез Йомшаккайга бик ошадыгыз.

## Тема. ЮЫНУ БҮЛМӘСЕН КАРАУ

**Бурычлар:**

1) балаларны юыну бүлмәсендәге предметлар (сабын, сөлге, кран, су, теш щёткасы, теш пастасы) белән таныштыру, функциональ билгеләнешләре турындагы күзаллауларын ачыклау;

2) сүзләрне төрле грамматик формаларда (сабын, сабынны, сабын белән һ.б.) куллану осталыгына ирешү, балаларның сөйләм активлыгын, инициативасын үстерү;

3) балаларны сөйләм этикетының гади формаларын (исәнләшү, саубуллашу) кулланырга гадәтләндерү, пөхтәлек, чисталык, башкаларга ярдәм итү омтылышы тәрбияләү.

**Җиһазлар:** Мәрьям исемле курчак, сабын, сөлге, теш щёткасы, теш пастасы.

### Эшчәнлек барышы.

Тәрбияче балаларны үз янына җыя. Ишек шакыган тавыш ишетелә.

Тәрбияче. Балалар, кем бар икән анда? (Ишеккә бара.) Безгә кунак килгән. (Курчакны алып керә.) Нинди кунак килгән? (*Курчак.*) (Активлаштыру.) Курчакның исеме — Мәрьям. Исәнмесез, балалар! Балалар, исәнләшегез әле Мәрьям белән. (*Исәнме, Мәрьям!*) Балалар, Мәрьям минем колагыма нәрсәдер пышылдый. Аның кулын юасы килә, ә ничек юарга кирәген белми. Балалар, Мәрьямгә булышабызмы? (Активлаштыру. Тәрбияче балаларны юыну бүлмәсенә алып керә.) Балалар, бу бүлмә ничек атала? (*Юыну бүлмәсе.*) (Активлаштыру.) Балалар, юыну бүлмәсендә сез нәрсә эшлисез? Гүзәл (Әдилә, Марат, Ренат һ.б.), ә син нәрсә эшлисең? (Активлаштыру.) Мәрьям, юыну бүлмәсендә безнең балалар кулларын, битләрен юалар, тешләрен чистарталар. Балалар, юыну бүлмәсендә нәрсәләр бар? (Тәрбияче балаларның игътибарын су краны, сөлге элгече һәм башка шундый предметларга юнәлтә. Активлаштыру.) Дөрес, балалар, юыну бүлмәсендә су краны, сөлге элгеч, сөлгеләр, сабын, теш щёткасы, теш пастасы бар. Айнур, бу нәрсә? (*Су краны.*) Әйдәгез, балалар, бергә кабатлыйк. (Активлаштыру.) Балалар, краннан нәрсә ага? (*Су.*) (Активлаштыру. Тәрбияче җылы су кранын ача.) Балалар, краннан аккан су салкынмы, җылымы? Килегез

әле, кулларыгызны куеп карагыз. Балалар, хәзер краннан нинди су ага: җылымы, салкынмы? Килегез әле, кулларыгызны куеп карагыз. (Тәрбияче салкын су кранын ача.) Су салкынмы? (*Салкын су.*) (Активлаштыру.) Су җылымы? (*Җылы су.*) (Активлаштыру.) Балалар су чиста, йомшак, ул бик күп һәм тиз ага.

Йомшак су, йөгерек су!
Син мине чиста ю!
Бер тап та калмасын,
Битләрем аллансын,
Кулларым агарсын,
Тешләрем тазарсын...

Кулларны һәм битне югач нишлиләр? (*Сөртәләр.*) Нәрсәгә сөртәләр? (*Сөлгегә сөртәләр.*) (Активлаштыру.) *Сөлге* сүзен икенче төрле тагын ничек әйтергә була? (*Тастымал.*) (Активлаштыру.) Илнур, без сөлгене кая элә без, күрсәт әле. (*Элгечкә.*) (Активлаштыру.) Дөрес, сөлгене элгечкә элә без. Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз әле. (*Элгеч.*) (Активлаштыру. Тәрбияче балаларга сабын күрсәтә.) Бу нәрсә? (*Сабын.*) (Активлаштыру.) Сабын нинди төстә? (*Ак.*) Әйе, ак сабын. Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз әле. (*Ак сабын.*) Иснәп карагыз әле, сабыннан нинди ис килә? (Тәрбияче балаларга сабынны иснәтә.) Сабын нинди исле? (*Тәмле исле.*) (Активлаштыру.) Сабынның тәмле исле булуын тагын нинди дип әйтергә була? (Җаваплар тыңлана.) Балалар, сабын хуш исле. Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз әле: «хуш исле». (*Хуш исле.*) Тагын нәрсә хуш исле була? (*Алма, чәчәк, ислемай* һ.б.) (Активлаштыру.) Балалар, Мәрьям сабынның ни өчен кирәк икәнен белми. Әйдәгез, аңа ярдәм итик. Балалар, сабын ни өчен кирәк? (Активлаштыру.) Дөрес, балалар, сабын белән кулларны, битне юалар. Балалар, Мәрьямгә кулны ничек итеп сабын белән юарга кирәклеген күрсәтегез әле. Җиңнәр озын булса, җиңнәрне сызганырга кирәк. Гүзәл, кабатла әле, башта нәрсә эшләргә кирәк? (Активлаштыру.) Аннары су кранын ачабыз, кулларны краннан аккан суда чылатабыз. Алсу, кабатла әле, нәрсә эшләргә кирәк? (Активлаштыру.) Сабын белән кулларны сабынлыйбыз. Ренат, кабатла әле, нәрсә эшләргә кирәк? (Активлаштыру.) Сабынны сабын савытына салабыз һәм кулны әйбәтләп ышкыйбыз. Әдилә, нәрсә эшләгәнеңне кабатла әле. (Активлаштыру.) Кулда бер генә микроб та калмасын. Аннан соң сабын күбеген су белән юып төшерәбез. Мәдинә, кабатла әле, нәрсә эшләргә кирәк? (Активлаштыру.) Су тамчылары кулда калмасын

өчен, кулларны раковина өстендә җиңелчә селкеп алырга да була. Менә шулай. (Тәрбияче барлык хәрәкәтләрне күрсәтә, соңыннан балалар кулларын үзләре юалар.) Балалар, хәзер һәрберегез сөлгегезне элгечтән алыгыз һәм кулларны корытып сөртегез. Менә шулай, булдырдыгыз! Балалар, сөлгене тотып карагыз әле. Сөлге нинди: катымы, әллә йомшакмы? (*Йомшак.*) (Активлаштыру.) Дөрес, балалар, сөлге йомшак. (Активлаштыру.) Сөлге чистамы? (*Чиста.*) (Активлаштыру.) Мәрьям, кара әле, һәр баланың үз сөлгесе бар. Әмир, Мәрьямгә үз сөлгеңне күрсәт әле. Синең сөлге элгеченә нәрсә рәсеме төшкән? (*Әтәч.*) (Активлаштыру.) Алсу, син дә үз сөлгеңне күрсәт әле. Синең элгечтә нәрсә рәсеме бар? (*Чеби.*) (Активлаштыру.) Балалар, карагыз әле, монда тагын нәрсә бар? (Теш щёткасын күрсәтә.) (*Теш щёткасы.*) (Активлаштыру.) Ә бу нәрсә? (*Теш пастасы.*) (Активлаштыру.) Теш щёткасы белән нәрсә эшлиләр? (*Тешләрне чистарталар.*) (Активлаштыру.) Тешләрне ничек итеп чистарталар? Мәрьям, карап тор әле. Теш щёткасына аз гына теш пастасы салабыз һәм тешләрне чистартабыз. Чистартып бетергәч, авызны су белән чайкыйбыз. Соңыннан щётканы су белән юабыз һәм урынына куябыз.

Мәрьям, сиңа безнең балалар ошадымы? Безнең балалар бик чиста һәм пөхтә. Су һәм сабын белән алар бик дус. Кулларын, битләрен гел юып кына торалар. Балалар, әйдәгез, Мәрьям белән саубуллашыгыз! (*Сау бул, Мәрьям!*) Мәрьям, безгә тагын кил! Балалар сине көтеп калалар.

## *Икенче бүлек.* КӨЗ

### Тема. КӨЗГЕ ТАБИГАТЬ

**Бурычлар:**

1) балаларның көз (табигатьтәге үзгәрешләр, кешеләрнең киеме һ.б.) турында гади күзаллауларын формалаштыру;

2) балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын, тәрбиячене тыңлый белү осталыгын үстерү;

3) көзге табигатькә соклану хисләре тәрбияләү.

**Җиһазлар:** эшчәнлек табигатьтә уза.

**Эшчәнлек барышы.**

Эшчәнлек балалар бакчасы мәйданчыгында үткәрелә.

Т ә р б и я ч е . Балалар, җәй үтте, көз җитте. Урамда җылымы, әллә салкынмы? (*Салкын.*) (Активлаштыру.) Урамда салкын булгач, кешеләр дә җылы киенәләр. Бер-берегезгә

карагыз әле, сезнең өстегездә җылы киемнәр. Әмир җылы свитер, чалбар, ботинкалар, куртка, башлык кигән. Әдилә дә бүген куртка, аның эченнән җылы кофта кигән, аның колготкилары да җылы, башлыгы да суыкны үткәрми. Балалар, кулларыгызны өскә күтәреп, күккә карагыз әле. Күктә нәрсәләр бар? (*Болытлар.*) (Активлаштыру.) Озакламый яңгыр явар. Балалар, тыңлап карагыз әле, җил исәме? (*Җил исә.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Җил искәндә нинди тавыш килә? (*«Ш-ш-ш».*) Дөрес, балалар, әйдәгез, бергәләп кабатлагыз әле. (Активлаштыру.) Җил исә, ул агачтагы яфракларны коя. Агач төбендәге яфракларга игътибар итегез әле. Яфраклар күпме? (*Күп.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, әйдәгез, коелган яфраклар өстеннән йөреп карыйк. (Йөриләр.) Менә яфраклар нинди матур тавыш чыгаралар! Нинди тавыш ишетәсез? (*«Кыштыр-кыштыр».*) Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз әле: «кыштыр-кыштыр». (Активлаштыру.) Балалар, ишетәсезме, яфраклар бер-берсе белән әкрен генә сөйләшәләр. Алар кыштыр-кыштыр киләләр, кыштырдыйлар. Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз әле: «кыштырдыйлар». Әйе, яфраклар кыштырдыйлар. Яфраклар нишлиләр? (*Кыштырдыйлар.*) (Активлаштыру.) Балалар, көз көне агач яфраклары кызыл, сары төскә керәләр. Аннан соң алар акрынлап коелалар.

Көз килде. Үләннәр
Саргайды, шиңде.
Сап-сары яфраклар
Җиргә сибелде.

Балалар, хәзер һәрберегез җирдән яфраклар алыгыз. Без сезнең белән яфраклар булыйк әле. Яфраклар агачта яшәгәннәр. Көз килгән. Көз яфракларны сары, кызыл төскә буяган. Яфраклар тагын да матурайганнар. Салкын җил искән, яфракларны ботакларыннан өзеп алган. Яфраклар һавада бөтерелә-бөтерелә оча башлаганнар.

Сап-сары яфраклар
Җил искәч очалар.
Бөтерелә-бөтерелә,
Җиргә үк төшәләр.

Балалар шигырь текстына туры китереп йөгерәләр, әйләнәләр, чүгәлиләр.

Тәрбияче. Балалар, сез бик матур яфраклар булдыгыз. Яфраклар булып, матур итеп «очтыгыз», биедегез. Булдырдыгыз, балалар! (Кул чабалар.)

## Тема. ҖИЛӘК-ҖИМЕШЛӘР

**Бурычлар:**

1) тышкы билгеләре һәм тәме буенча җиләк-җимешләрне аерырга өйрәтү, җиләк-җимешләр һәм аларның уңышын җыеп алу турында күзаллауларын киңәйтү, җиләк-җимешләрнең исемнәре һәм аларның билгеләрен белдерә торган сүзләр хисабына балаларның сүз байлыгын үстерү;

2) балаларның игътибарын, кабул итү һәм сенсор тою сәләтен, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;

3) балаларны сөйләм этикетының гади формаларын (исәнләшү, саубуллашу) куллана белергә гадәтләндерү, әйләнә-тирә табигать объектларына кызыксыну тәрбияләү.

**Җиһазлар:** Мәрьям исемле курчак, вазага (тәлинкәгә) салынган кызыл алма, яшел груша, сары сливалар.

### Эшчәнлек барышы.

Өстәлдә ваза яки тәлинкәгә салынган алма, груша, слива җимешләре. Аларның өсләре капланган. Тәрбияче төркем бүлмәсенә курчак алып керә.

Тәрбияче. Балалар, карагыз әле, безгә бүген кунак килгән. Нинди кунак килгән? (Активлаштыру.) Әйдәгез, балалар, курчакның исемен искә төшерик әле. (Активлаштыру.) Әйе, курчакның исеме — Мәрьям. Әйдәгез, балалар, бергәләп кабатлыйк әле: «Мәрьям». (Күмәк кабатлау.) Мәрьям белән исәнләшик. (*Исәнме, Мәрьям!*)

Мәрьям. Исәнмесез, балалар!

Тәрбияче. Балалар, Мәрьям безгә күчтәнәч алып килгән. Мәрьям нәрсә алып килгән? (*Күчтәнәч.*) (Активлаштыру. Тәрбияче вазадагы җиләк-җимешләрне күрсәтә.) Балалар, бу нәрсә? (*Алма, груша, слива.*) (Активлаштыру.) Алсу, кил әле, вазадан алма ал һәм балаларга күрсәт! Бу нәрсә? (*Алма.*) Алсу, син нәрсә алдың? (*Алма.*) Ренат, Алсу нәрсә күрсәтә? (*Алма.*) Булат, кабатла әле, бу нәрсә? (*Алма.*) Алма нинди төстә? (*Кызыл.*) Әйе, кызыл алма. Әйдәгез, балалар, бергәләп кабатлыйк әле: «кызыл алма». (Активлаштыру. Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Әдилә, вазадан груша ал әле. Әдилә, син нәрсә алдың? (*Груша.*) Рузилә, Әдилә безгә нәрсә күрсәтә? (*Груша.*) Камил, кабатла әле, бу нәрсә? (*Груша.*) Балалар, груша нинди төстә? (*Яшел.*) Әйе, яшел груша. Әйдәгез, балалар, бергәләп кабатлыйк әле: «яшел груша». (Активлаштыру. Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Данил, бу нәрсә? (*Слива.*) Динә, кабатла әле, бу нәрсә? (*Слива.*) Балалар, слива нинди төстә? (*Сары.*) Әйе, сары слива.

Әйдәгез, балалар, бергәләп кабатлыйк әле: «сары слива». (Активлаштыру. Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, алма, груша, слива — болар барысы да җиләк-җимешләр. Әйдәгез әле, кабатлагыз. (*Җиләк-җимешләр.*) (Активлаштыру. Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, Мәрьям-курчакның сезне тәмле җиләк-җимешләр белән сыйлыйсы килә. Балалар, мин сезгә җиләк-җимешләр өләшәм, ә сез, ашап карагач, аларның исемен әйтерсез. (Тәрбияче курчак белән балалар янына килә һәм киселгән җиләк-җимешләрне балаларга өләшә.) Әминә, син нәрсә ашыйсың? (*Алма.*) Камил, син нәрсә ашыйсың? (*Груша.*) Данил, ә син нәрсә ашыйсың? (*Слива.*) Балалар, җиләк-җимешләрегез тәмле булсын!

Рәхмәт, Мәрьям, бигрәк тәмле җиләк-җимешләр алып килгәнсең. Мәрьям сезгә нәрсәләр алып килгән әле? (Активлаштыру.) Мәрьям, безнең балалар бу җиләк-җимешләрне бик яраталар. Балалар, Мәрьямгә рәхмәт әйтегез! (*Рәхмәт, Мәрьям!*) (Рәхмәт әйтәләр һәм саубуллашалар.)

Балалар, җиләк-җимешләрне ашарга кирәк, аларда витаминнар күп. Витаминнар бик файдалы, алар сезгә нык һәм сәламәт булырга ярдәм итә.

## Тема. «БЕЗНЕҢ АЛСУ» СЕРИЯСЕННӘН РӘСЕМ КАРАУ

**Бурычлар:**

1) рәсемдәге предметларны таный һәм исемен әйтә белергә, рәсем эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә өйрәтү, сүзлекне активлаштыру;

2) балаларның игътибарын, хәтерен үстерү, тәрбияче күрсәтмәләрен ишетә һәм үти белүләренә ирешү;

3) рәсемне кызыксынып карау теләге тәрбияләү.

**Җиһазлар:** «Яфрак бәйрәме» җырының (Р. Еникеева көе, Л. Лерон сүзләре) аудиоязмасы, төрле төстәге көзге яфраклар (чын яфраклар яки аларның контурлы сурәтләре), «Безнең Алсу» рәсеме, сары һәм яшел яфрак беркетелгән ике урындык, шнурлардан ясалган ике юл.

### Эшчәнлек барышы.

Тәрбияче. Балалар, бүген безнең бүлмәдә бәйрәм. Нинди бәйрәм? (*Яфраклар бәйрәме.*) (Активлаштыру.)

Аудиоязмада «Яфрак бәйрәме» җыры яңгырый, тәрбияче һәм балалар җырлыйлар. Тәрбияче, җырлаганда, төрле төстәге яфракларны идәнгә сибә.

Тәрбияче. Балалар, идәнгә нәрсәләр сибелгән? (*Яфраклар.*) (Активлаштыру.) Әйе, идәнгә төрле төстәге яфраклар коелган. Карагыз әле, күпме яфраклар! Яфраклар күпме?

(*Күп.*) (Активлаштыру.) Балалар, әйдәгез, яфракларны җыегыз һәм өстәлдәге вазаларга куегыз. Бүлмәбез тагын да матурайсын! (Тәрбияче һәм балалар яфракларны җыялар һәм өстәлләрдәге вазаларга куялар.) Балалар, мин сезгә бер шигырь укыйм. (Тәрбияче шигырьне сөйләргә берәр баланы алдан әзерли ала.)

Көз килде. Үләннәр
Саргайды, шиңде.
Сап-сары яфраклар
Җиргә сибелде.

Балалар, хәзер мин сезгә Алсу исемле кызның көзге яфраклардан ничек итеп букет җыюы турында рәсем күрсәтәм.

Тәрбияче алдан әзерләп куелган рәсемне күрсәтә. Балаларга рәсемне карарга вакыт бирә һәм анда нәрсә сурәтләнүе турында сөйли.

Балалар, Алсу исемле кыз урамга чыккан. Менә ул Алсу. (Тәрбияче Алсуга күрсәтә.) Алмаз, кил әле, кызны күрсәт әле. Син кемне күрсәттең? (Активлаштыру.) Балалар, Алмаз кемне күрсәтте? (Активлаштыру.) Алмаз, кызның исеме ничек? (*Алсу.*) Балалар, кызның исеме ничек? (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Әминә, кил, син дә Алсуны күрсәт әле. Алсу нәрсәләр җыйган? (*Яфраклар.*) (Активлаштыру.) Балалар, Алсу көзге яфраклардан букет җыйган. Балалар, Алсу көзге яфраклардан нәрсә җыйган? (*Букет.*) Әйе, букет җыйган. (Активлаштыру.) Алсу җыйган яфраклар нинди төстә? (*Сары.*) Әйе, сары яфраклар. Нинди яфраклар? (*Сары яфраклар.*) Әйдәгез, балалар, барыгыз да кабатлагыз. (*Сары яфраклар.*) Әйе, көз көне яфраклар сары төскә керәләр — саргаялар. Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз әле: «саргаялар». (Активлаштыру). Көз көне сары яфраклар агачта озак тормыйлар — коелалар. Әйдәгез, барыгыз да бергә кабатлагыз. (*Коелалар.*) (Активлаштыру.) Карагыз әле, яфраклар эскәмиягә, юлга, чирәмгә коелганнар. Гүзәл, эскәмиягә коелган яфракларны күрсәт әле. (Күрсәтә.) Балалар, Гүзәл күрсәткән яфраклар кая коелганнар? (*Эскәмиягә.*) (Активлаштыру.) Азат, юлга коелган яфракларны күрсәт әле. Балалар, Азат күрсәткән яфраклар кая коелганнар? (*Юлга.*) (Активлаштыру.) Марат, ә менә бу яфраклар кая коелганнар? (*Чирәмгә.*) Кил әле, Марат, чирәмгә коелган яфракларны күрсәт әле. Балалар, Марат күрсәткән яфраклар кая коелганнар? (*Чирәмгә.*) Балалар, ә агачта яфраклар калганмы? (*Әйе.*) Әмир, агачта нәрсәләр бар, күрсәт әле. (*Сары яфраклар.*) Балалар, көз көне урамда җылымы, салкынмы? (*Салкын.*)

Әйе, шуңа күрә Алсу өстенә нәрсә кигән? (*Куртка.*) Балалар, әйдәгез, кабатлагыз: «Алсу өстенә куртка кигән». (*Куртка* сүзен ныгыту.) Камил, кил әле, Алсуны һәм аның курткасын күрсәт әле. Алсу өстенә нәрсә кигән? (*Куртка.*) Әйе, куртка җылы, Алсуга да җылы. Балалар, куртка җылымы? (Активлаштыру.) Алсу урамга үзе белән нәрсәләр алган? (*Курчак, машина.*) Дилә, күрсәт әле, Алсу урамга үзе белән нәрсәләр алган? (*Курчак, машина.*) (Балалар Дилә әйткәнне һәм күрсәткәнне кабатлыйлар.) Алсу янында нәрсә бар? (*Эт.*) Эт нишли? (*Йөгерә.*) (Активлаштыру. Бер-ике бала, чыгып, этне күрсәтә һәм сорауларга җавап бирә.) Әйдәгез, балалар, бармаклардан эт ясыйбыз. Кулның учын, үзегезгә каратып, кабыргасына куегыз. Баш бармак өскә караган, имән бармак бөгелгән, калган ике бармак бергә кушылган, ә чәнти бармак аска караган. Менә нинди матур эт килеп чыкты! Эт ничек өрә? (*«Һау-һау».*) Булдырдыгыз! Сезнең бармакларыгыз тыңлаучан, аларны яратырга кирәк. Бармакларыгызны менә шулай сыйпап яратыгыз әле! (Тәрбияче күрсәтә.)

Хәзер мин сезгә Алсу турында сөйлим. Көз җитте. Агачларда яфраклар саргайды. Салкын җил исте, һәм яфраклар коела башладылар. Алар эскәмиягә, чирәмгә, юлларга очып төштеләр. Көннәр салкынайтты. Алсу да, җылы киемнәрен киеп, урамга чыкты. Ул үзе белән курчагын һәм машинасын да алды. Алсу курчагын машинага утыртты. Аңа эте дә ияреп чыкты. Аның да Алсу белән уйныйсы килә. Алсу сары яфраклардан әнисенә букет җыйды. «Булдыргансың, кызым!» — диеп, әнисе шатланыр инде. Балалар, әйдәгез, уйнап алыйк.

«Яфрак бәйрәме» җырының аудиоязмасы куела. Тәрбияче алдан ук ике юл ясый. Юллар беткән урынга, берсенә сары, икенчесенә яшел яфраклар беркетеп, ике урындык куя.

Тәрбияче. Менә ике юл. Беренче юл — яшел, икенче юл сары яфракларныкы. Мин нинди яфракны күрсәтсәм, сез шул юлдан гына барырга тырышыгыз. Миңа карагыз, бик игътибарлы булыгыз! (Тәрбияче башта сары, аннан соң яшел яфракны күрсәтә. Балалар уен биремен үти алмасалар, тәрбияче ярдәм итә. Уен ике тапкыр кабатлана.)

Булдырдыгыз, балалар! Сез бүген барыгыз да бик тырыштыгыз! Урамга чыккач, көзге яфракларны җыярсыз. Ул яфраклардан букет ясап, әниләрегезгә бүләк итәрсез. Әниләрегез сөенсеннәр әле! (Рәсем, индивидуаль эш һәм иреккле карау өчен, группада калдырыла.)

## Тема. ЯШЕЛЧӘЛӘР: ПОМИДОР, КЫЯР, КИШЕР БЕЛӘН ТАНЫШТЫРУ

**Бурычлар:**

1) балаларның помидор, кыяр, кишер турындагы белемнәрен ныгыту; помидор, кыяр, кишернең форма, төс, тәм үзенчәлекләре (кызыл, йомшак, шома, тәмле, сусыл, шар формасындагы помидор; яшел, каты, шома, кытыршы кыяр; шома, кызыл, тәмле, каты кишер) белән таныштыру;

2) балаларның сенсор тою сәләтен, тәрбиячене ишетү һәм сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;

3) балаларны сөйләм этикетының гади формаларын (исәнләшү, саубуллашу) кулланырга гадәтләндерү, зурлар хезмәтенә хөрмәт тәрбияләү.

**Җиһазлар:** «Шалкан» әкиятеннән бабай (курчак); һәр бала санынча кәрзин белән кыяр, кишер, помидор; ваза, татарча бию көенең аудиоязмасы.

### Эшчәнлек барышы.

Тәрбияче. Балалар, кемдер ишек шакый. Кем икән ул? (Тәрбияче ишекне ача, һәм бабай керә.) Безгә кунак килде. Кем килде? (*Бабай.*) (Активлаштыру. Бабай балалар белән исәнләшә: «Исәнме, Алсу, исәнме Дамир (Дилә, Айнур һ.б.)». Бабай балалар янына килә, кул биреп күрешә, яратып, башларыннан, җилкәләреннән сыйпый.) Әйдәгез, балалар, без дә бабай белән исәнләшик. (*Исәнме, бабай!*) Балалар, бабай безгә «Шалкан» әкиятеннән килгән. Ул нәрсә алып килгән? (*Кәрзин.*) (Активлаштыру.) Бабай, син безгә нәрсәләр алып килдең?

Бабай. Мин сезгә бакчамда үстергән яшелчәләр алып килдем.

Тәрбияче. Ә-ә, син безгә күчтәнәчләр алып килдеңмени?

Бабай. Менә мин нәрсә алып килдем. (Кәрзиннән кишер алып күрсәтә.) Кем белә, бу нәрсә?(*Кишер.*) Әмир (Алсу, Гүзәл һ.б.), бу нәрсә? Әйе, бу — кишер. Әйдәгез, балалар, бергәләп әйтеп карагыз әле. (*Кишер.*)

Тәрбияче. Кишер яшелчә бакчасында үскән. Бабай, балалар кәрзиннән берәр кишер алса ярыймы?

Бабай. Алыгыз, балалар, алыгыз. (Һәр бала кәрзиннән берәр кишер ала.)

Тәрбияче. Алсу, син нәрсә алдың? (*Кишер.*) Каян алдың? (*Кәрзиннән.*) Марат, син нәрсә алдың? (Активлаштыру.) Кишер кайда үсә? (*Бакчада, түтәлдә, яшелчә бакчасында.*) (Активлаштыру.) Кишер нинди төстә? (*Кызыл.*) Әйе, кызыл

кишер. (Активлаштыру.) Балалар, кишерне кулыгыз белән тотып карагыз әле. Менә шулай. (Тәрбияче күрсәтә.) Ул шомамы? (*Шома.*) (Активлаштыру.) Ә хәзер бармакларыгыз белән басып карагыз. Ул йомшакмы, катымы? (*Каты.*) (Активлаштыру.) Дөрес, балалар, кишер шома һәм каты. Әйдәгез, бергәләп кабатлыйбыз: «шома һәм каты кишер». (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Бабакай, синең кәрзинеңдә тагын нәрсәдер бар бугай. Күрсәт әле. (Бабай помидор күрсәтә.) Кем әйтә ала, бу нәрсә? (*Помидор.*) Әйе, помидор. Балалар, барыгыз бергә бу сүзне кабатлагыз әле. (*Помидор.*) Помидор нинди төстә?(*Кызыл.*) Әйе, кызыл помидор. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Помидор нинди формада? (*Шар формасында.*) Әйдәгез, кулларыгыз белән шар ясап күрсәтегез әле. (Балалар күрсәтәләр. Балалар күрсәтә алмаса, тәрбияче кул бармаклары ярдәмендә шар формасын күрсәтергә ярдәм итә.) Балалар, помидор шарга охшаган. Бабай, балалар кәрзинеңнән берәр помидор алса ярыймы?

Бабай. Алыгыз, балалар, алыгыз. (Һәр бала кәрзиннән берәр помидор ала.)

Тәрбияче. Хәзер бармакларыгыз белән басып карагыз әле. Менә шулай. Помидор катымы, йомшакмы? (*Йомшак.*) (Активлаштыру.) Помидорны кулыгыз белән сыйпап карагыз әле. Помидор шомамы?(*Шома.*) (Активлаштыру.) Балалар, бабайга әйтегез әле: помидор нинди?(*Помидор кызыл, түгәрәк, йомшак, шома.*) (Активлаштыру.) Бабай, синең кәрзинеңдә тагын нәрсә бар? (Бабай кыяр алып күрсәтә.) Кем белә, бу нәрсә? (*Кыяр.*) Бабай, безнең балалар моның кыяр икәнен бик яхшы беләләр. Балалар, кыяр нинди төстә? (*Яшел.*) Әйе, яшел кыяр. (Активлаштыру.) Балалар, кыярга бармакларыгыз белән басып карагыз әле. Кыяр йомшакмы, катымы? (*Каты.*) (Активлаштыру.) Кыяр нинди: кытыршымы, шомамы? (*Шома.*) Кыярның кытыршысы да була. Менә бу кыяр кытыршы. (Күрсәтә.) Килегез әле, кытыршы кыярны тотып карагыз. (Тәрбияче кулындагы кыярны балалар тотып карыйлар.) Балалар, димәк, кыяр шома гына түгел, кытыршы да була. Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз әле: «кытыршы». (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, мин сезне бабай алып килгән яшелчәләр белән сыйларга телим. (Тәрбияче кыярны, турап, вазага куя.) Балалар, сез кыярны ашап карагыз һәм нәрсә ашаганыгызны әйтерсез. Күзләрегезне йомыгыз һәм кыярның нинди тәмле, хуш исле икәнен тоемлагыз. Кыяр хуш ислеме?(Х*уш исле.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Кыярны ашаганда нинди тавыш чыга? (*Ке-*

*тер-кетер.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Ә хәзер мин сезне кишер белән сыйлыйм. Ашап карагыз әле, кишернең тәме нинди? (*Баллы, тәмле.*) (Активлаштыру.) Кишер дә кыяр кебек кетер-кетер киләме? Әйе, ул да кетер-кетер килә. (Активлаштыру.) Ә хәзер помидор белән сыйланыгыз. Балалар, помидор нинди? (*Кызыл, шома, йомшак.*) (Активлаштыру.) Помидор хуш ислеме? (*Помидор хуш исле.*) Помидор тәмлеме? (*Тәмле.*) Булдырдыгыз, балалар! Сорауларга матур һәм дөрес итеп җавап бирдегез. Сез бабайга да бик ошадыгыз. Әйдәгез, балалар, күчтәнәчләре өчен бабайга рәхмәт әйтик. (Активлаштыру.) Бабай яшелчәләрне бик тырышып үстергән: су сипкән, чүпләрен утаган. Шуңа күрә яшелчәләр бик тәмле булып өлгергәннәр. Яшелчәләрне яратып ашарга кирәк, аларда витаминнар күп.

Бабай. Балалар, витаминлы яшелчәләр ашагач, сез тагын да акыллы һәм сәламәт булып үсәрсез, авырмассыз.

Тәрбияче. Балалар, яшелчәләрне һәрвакыт юып ашарга кирәк. Әйдәгез, бабай белән бергә күңелле көйгә биеп алыгыз. (Барысы бергә бииләр, шатланалар.)

## Тема. РӘСЕМДӘГЕ КОШЛАРНЫ КАРАУ

**Бурычлар:**

1) балаларда күгәрчен, саескан турында гомуми күзаллаулар булдыру, кошларга карата кызыксыну уяту;

2) балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын, күзәтүчәнлеген һәм сүз байлыгын үстерү;

3) кошларга карата мәрхәмәтлелек тәрбияләү.

**Җиһазлар:** мольберт, күгәрчен, саескан рәсемнәре, күгәрчен битлекләре.

### Эшчәнлек барышы.

Тәрбияче мольбертка күгәрчен рәсемен куя һәм Н. Арслановның шигырен укый.

Тәрбияче. Бер кошка кызыгамын:
Тәпие кызыл аның.
Атлаган саен, баш ия —
Гадәте кызык аның.
Гөлдер-гү, гөлдер-гү,
Бигрәк чибәр, кемдер бу?

Балалар, рәсемдә нәрсә ясалган? (*Күгәрчен.*) (Активлаштыру.) Күгәрченне игътибар белән карыйк әле, нәрсәләре бар? (*Башы, гәүдәсе, канатлары, тәпиләре.*) (Балалар әйтә алмаса, тәрбияче, ишарәләр белән күрсәтеп, игътибарларын

күгәрченнең өлешләренә юнәлтә.) Күгәрченнең башында нәрсәләре бар? (Күзләренә күрсәтә.) (*Күзләре.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Күгәрчен күзләре белән сезгә карап тора, аңа күзләр күрү өчен кирәк. Күгәрченнең башында тагын нәрсә бар? (Томшыгына күрсәтә.) (*Томшык.*) (Активлаштыру. Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, күгәрчен томшыгы белән җим чүпли. Күгәрчен нишли? (*Җим чүпли.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, күгәрчен нәрсә ярата? (*Көнбагыш.*) Күгәрчен гөрләгәндә нинди тавыш чыгара? (*«Гөр-гөр»*). Әйдәгез, балалар, «гөр-гөр» итеп, күгәрченнәрнең ничек көнбагыш чүпләгәнен күрсәтик. (Балалар, «гөр-гөр» тавышы чыгарып, җим чүпләү хәрәкәте ясыйлар.) Балалар, күгәрченнең гәүдәсе бар. Менә ул. (Күрсәтә.) Марат, кил әле, күгәрченнең гәүдәсен күрсәт әле. (Күрсәтә.) Син күгәрченнең нәрсәсен күрсәттең? (*Гәүдәсен.*) Әйе, менә бу — күгәрченнең гәүдәсе. (Күрсәтә. Тагын икеөч баладан кабатлата.) Күгәрченнең гәүдәсендә канатлары бар. Менә алар. (Күрсәтә.) Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз әле: «канатлар». (Активлаштыру.) Балалар, күгәрчен ничек оча? Әйдәгез, бергәләп күрсәтик әле. (Күрсәтәләр.) Балалар, күгәрченнең койрыгы бар. (Күрсәтә.) Бу нәрсә? (Койрыкка күрсәтә.) (*Койрык.*) Койрыгы аңа очарга ярдәм итә. Балалар, күгәрчен сикерәме, әллә йөриме? (*Йөри.*) Аңа йөрергә нәрсәләре ярдәм итә? (*Тәпиләре.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Менә тәпиләре. (Күрсәтә.) Тәпиләр нинди төстә? (*Кызыл тәпиләр.*) Әйе, күгәрченнең кызыл тәпиләре бар. (Активлаштыру.) Балалар, күгәрченнәр «гөр-гөр» итеп гөрлиләр. (*Гөрлиләр* сүзен активлаштыру.) Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: «гөрлиләр». (*Гөрлиләр.*) Күгәрченнәр йөриләр. Күгәрченнәр нишлиләр? (*Йөриләр.*) Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: «йөриләр». (*Йөриләр*). Күгәрченнәр очалар. Күгәрченнәр нишлиләр? (*Очалар.*) Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: «очалар». (*Очалар.*) Балалар, ә хәзер без сезнең белән күгәрченнәр булабыз. (Тәрбияче балаларга күгәрчен битлекләре тарата.) Әйдәгез, күгәрченнәр кебек, бүлмә буйлап очабыз, җим чүплибез, гөр-гөр киләбез. Менә шулай, булдырдыгыз!

Тәрбияче мольбертка саескан сурәте төшкән кечкенә рәсем куя һәм саескан турында шигырь укый.

Саескан, саескан.
Агач башына кунган.
Җиргә төшкән, сикергән —
Безгә кунакка килгән.

Балалар, бу кечкенә рәсемгә игътибар белән карагыз әле. (Тәрбияче балаларның игътибарын саескан ясалган кечкенә рәсемгә юнәлтә.) Рәсемдә нинди кош ясалган? (*Саескан.*) (Активлаштыру.) Әйе, бу — саескан. Саесканның башы, гәүдәсе, канатлары, тәпиләре бар. (Тәрбияче саесканның гәүдә өлешләрен күрсәтә һәм исемнәрен әйтә.) Балалар, бу нәрсә? (Саесканның башына күрсәтә.) (*Башы.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, саесканның башында нәрсәләр бар? (*Күзләре.*) (Активлаштыру.) Башында тагын нәрсә бар? (*Томшык.*) (Балалар әйтә алмаса, тәрбияче саесканның томшыгына күрсәтә.) Балалар, бергәләп кабатлагыз әле: «томшык». (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Бик яхшы! Ләйсән, саесканның гәүдәсен күрсәт әле. Балалар, Ләйсән саесканның нәрсәсен күрсәтте? (*Гәүдәсен.*) (Активлаштыру.) Балалар, саесканның гәүдәсендә нәрсәләр бар? Бу нәрсә? (Канатларына күрсәтә.) (*Канатлар.*) (Активлаштыру.) Канатлар саесканга очар өчен кирәк. Әйдәгез, саескан кебек очып күрсәтик. (Балалар кулларын як-якка җәеп, саескан кебек «очып» йөриләр.) Булдырдыгыз! Балалар, саесканның койрыгы бар. (Күрсәтә.) Бу нәрсә? (*Койрык.*) Койрык саесканга очарга ярдәм итә. Балалар, бу нәрсә? (Тәпиләренә күрсәтә.) (*Тәпиләр.*) (Активлаштыру.) Саескан йөриме, сикерәме? (*Сикерә.*) (Активлаштыру.) Саесканның тәпиләре көчле. Саескан җимне бик ярата. Саесканның җимне ничек чүпләвен күрсәтегез әле. (Балалар тәрбияче белән бергә хәрәкәтне күрсәтәләр.)

Балалар, без бүген ике рәсем карадык. Аның берсендә — (рәсемдәге күгәрченгә күрсәтә) күгәрчен, ә икенчесендә (саесканга күрсәтә) саескан рәсеме ясалган. Балалар, күгәрчен һәм саескан — кошлар. (Активлаштыру.) Балалар, кошларны куркытырга, аларга таш ыргытырга, зыян салырга ярамый. Кошларны яратырга кирәк. Кошлар — безнең дусларыбыз. Булдырдыгыз! (Кул чабалар.) Мин сездән бик канәгать!

## Тема. КӨЗ (йомгаклау чарасы)

**Бурычлар:**

1) балаларның көз турындагы белемнәрен (яфраклар саргая, яфраклар коела, яңгырлар күп ява, кешеләр җылы киемнәрен кияләр) ныгыту, тәрбияче сорауларына дөрес җавап бирергә, рәсем ясаганда буяуны кәгазь битенә дөрес һәм тигез төшерергә өйрәтү, төсләрне ныгыту;

2) балаларның актив сөйләмен, ишетеп кабул итү сәләтен, игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерү, рәсем ясарга кызыксындыру;

3) көзге табигатькә соклану хисләре тәрбияләү.

**Җиһазлар:** сары гуашь, мольберт, «Яфрак бәйрәме» җырының (Р. Еникеева көе, Л. Лерон сүзләре) аудиоязмасы, болытлар төшерелгән кәгазь битләре (һәр балага җитәрлек санда).

### Эшчәнлек барышы.

Кулына көзге уңыш тутырылган кәрзин тотып, музыкага («Яфрак бәйрәме» җырының аудиоязмасы яңгырый) салмак кына биеп, Көз кызы керә.

Көз кызы. Исәнмесез, балалар! (Исәнләшәләр.) Хәзер елның кайсы вакыты? (*Көз.*) Мин — Көз кызы. Сезгә кунакка килдем. Балалар, әйтегез әле: көзен көннәр җылымы, салкынмы? (*Салкын.*) (Активлаштыру.) Көз көне табигатьтә нинди үзгәрешләр була? (*Яфраклар саргая. Яфраклар коела. Яңгырлар күп ява. Кешеләр җылы киемнәр кияләр*). (Активлаштыру.) Әйдәгез, балалар, яңгыр булып уйнап алыйк. Яңгыр тамчылары, тып-тып итеп, түбәгә тамалар. (Әкрен темпта әйтелә. Балалар тәрбияче артыннан кабатлыйлар, бармаклары белән тезләренә кагалар.) Балалар, яңгыр башланганда, тамчылар менә шулай әкрен генә тамалар: тып-тып, тып-тып... (Балалар кабатлыйлар. Активлаштыру.) Яңгыр тиз-тиз ява башлады, менә шулай. (Тәрбияче, «тып-тып, тып-тып» дип, тиз әйтә. Балалар кабатлыйлар.) Хәзер мине игътибар белән тыңлагыз һәм әйтегез: яңгыр әкрен явамы, әллә тизме? (*Тиз.*) (Балалар кабатлыйлар.) Ә хәзер яңгыр тиз явамы, әллә әкренме? (*Әкрен.*) (Активлаштыру.) (Тәрбияче *тып-тып* сүзен төрле темпта әйтә, балалар яңгырның тиз яки әкрен явуын билгелиләр. Уен ике-өч тапкыр кабатлана.)

Яңгыр, яңгыр, көн буе
Явасың да явасың!
Тәрәзәгә кагасың,
«Тып-тып» диеп әйтәсең.

Яңгыр тәрәзәгә кагылганда нинди тавыш чыгара? (*«Тып-тып».*) (Бармаклары белән өстәлгә шакыйлар.) Балалар, шигырьне бергәләп сөйлик әле. (Тәрбияче шигырь сөйли, балалар кабатлыйлар.) Балалар, көз көне яңгыр ... (*ява*). (Кабатлыйлар. Тәрбияче төрле төстәге яфракларны идәнгә сибә). Җил агач яфракларын җиргә ... (*коя*). (Кабатлыйлар.) Карагыз әле, яфраклар ничек күп. Балалар, яфраклар нинди төстә? (Активлаштыру.) Әйе, сары, яшел, кызыл яфраклар. Балалар, урыннарыгызга утырыгыз әле, хәзер без яфраклар ясарбыз. (Балаларга болытлар төшерелгән кәгазь битләре тарата, гуашька бармакны манчып, яфрак ясарга өйрәтә.)

Балалар, яфраклар нинди төстә? (*Сары.*) Әйе, сары яфраклар. (Кабатлыйлар.) Күрегез әле, сары яфраклар коела! Сары яфраклар күп. Булдырдыгыз, балалар.

Музыка яңгырый. Музыкага Көз кызы вальс әйләнә.

Көз кызы. Балалар, мин сезгә күчтәнәчләр алып килдем. Карагыз әле, минем кәрзинемдә нәрсәләр бар? (Күрсәтә.) Бу нәрсә? (*Кыяр, помидор, кишер.*) Балалар, кыяр, помидор, кишерне бер сүз белән ничек әйтергә була? (*Яшелчәләр.*) (Активлаштыру.) Дөрес, булдырдыгыз! Кәрзиндә тагын нәрсәләр бар? (*Алма, груша, слива.*) (Активлаштыру.) Алма, груша, слива башкача ничек әйтелә? (*Җиләк-җимешләр.*) (Активлаштыру.) Дөрес, бик яхшы. Балалар, мин сезне көзге яшелчәләр, җиләк-җимешләр белән сыйлыйм.

Тәрбияче һәм Көз кызы балаларга алма һәм кишер өләшә.

Тәрбияче. Балалар, Көз кызына күчтәнәчләре өчен рәхмәт әйтегез һәм саубуллашыгыз. Ул башка балалар янына ашыга. (Көз кызын озаталар.) Балалар, кишерләрегез, алмаларыгыз тәмле булсын! Алманы ашагач, чүбен идәнгә ташламагыз, чүп савытына салыгыз! Көз кызы чиста, пөхтә балаларны ярата. (Балалар кул чабалар.)

## *Өченче бүлек.* МИН — ДӨНЬЯНЫҢ БЕР КЕШЕСЕ

### Тема. МИНЕМ ИСЕМЕМ БАР

**Бурычлар:**

1) баланы үзенең һәм иптәшләренең исемен әйтергә өйрәтү, исемнәрне истә калдырырга, оялчанлыкны җиңәргә ярдәм итү;

2) тәрбияче әйткәнне ишетергә һәм аңларга, кайбер фразаларны (Минем исемем — Алсу) кабатларга күнектерү; балаларның хәтерен, игътибарын үстерү;

3) балаларда зурларга һәм яшьтәшләренә карата ягымлылык, дустанә мөнәсәбәт тәрбияләү.

**Җиһазлар:** Йомшаккай исемле уенчык песи, күңелле бию көенең аудиоязмасы.

**Эшчәнлек барышы.**

Тәрбияче балаларны урындыкларга утырта. Ишек шакыйлар. Йомшаккай керә, балалар белән исәнләшә.

Тәрбияче. Балалар, безгә кунак килгән. Аның исемен сорыйк әле: «Синең исемең ничек?» (Активлаштыру.)

Йомшаккай. Минем исемем — Йомшаккай. (Активлаштыру.)

Т э р б и я ч е . Балалар, Йомшаккайның исемнэрегезне беләсе килә. Аңа исемегезне әйтегез әле.

Йомшаккай балалар янына килә, һәр баланың исемен сорый.

Й о м ш а к к а й . Бигрәк матур икән исемнәрегез! Ә тәрбияче апаның исемен беләсезме? (Йомшаккай тәрбияче ярдәмчесенең һәм әти-әниләренең исемнәрен сорый. Балалар җавап бирә.) Балалар, сез уйнарга яратасызмы? (*Яратабыз.*) Әйдәгез, миңа берәр кызыклы уен уйнап күрсәтегез әле. (Балалар тәрбияче белән бергә «Кем безнең бик яхшы?» уенын уйныйлар.)

Т э р б и я ч е . Йомшаккай, әйдә, син дә безнең белән уйна!

Кем безнең бик яхшы,
Кем безнең ягымлы?

(Тәрбияче Алсуны чакырып ала һәм кочаклый.)

Б а л а л а р . Безнең Алсу бик яхшы,
Безнең Алсу ягымлы.

Тәрбияче Йомшаккай белән бергә баланың уңай сыйфатларын атый. Мәсәлән: матур, чәчләре тасма белән үрелгән, күзләре кара, еламый, тыңлаучан, җырларга ярата һ.б. Тәрбияче, биш-алты баланы чакырганнан соң, балаларга, пар табып, җитәкләшергә куша.

Аннары балалар күңелле музыкага парлап бииләр.

Т э р б и я ч е . Йомшаккай, күрдеңме минем нәни дусларымны! Һәрберсенең бик матур исеме бар. (Тәрбияче һәр баланың исемен кабатлап чыга.) Балалар үзләре дә бик матурлар, акыллылар, ягымлылар. Мин сезнең барыгызны да яратам.

Балалар Йомшаккай белән саубуллашалар.

## Тема. БУ—МИН

**Бурычлар:**

1) организм һәм аның өлешләре турында балаларда күзаллау формалаштыру, үзләрен бербөтен итеп кабул итәргә өйрәтү, гәүдә өлешләре турында белемнәрен ачыклау һәм ныгыту;

2) гәүдә өлешләренең атамалары (баш, күзләр, колаклар, борын, авыз, тешләр, чәч, куллар, аяклар) хисабына балаларның сүзлеген активлаштыру;

3) үзеңне, гәүдә өлешләреңне ярату, игътибарлы булу, культура-гигиена күнекмәләрен үтәү теләге тудыру.

**Җиһазлар:** шәрә курчакның тәмамланмаган рәсеме, һәр балада кече форматтагы шундый ук рәсем, мольберт, «тылсымлы» тартма.

### Эшчәнлек барышы.

Тәрбияче балаларга «тылсымлы» тартманы күрсәтә.

Т ә р б и я ч е . Балалар, карагыз әле, Йомшаккай безгә «тылсымлы» тартма алып килгән. Карыйк әле, нәрсә бар икән тартма эчендә? (Тәрбияче тартмадан курчак ала.) Бу нәрсә? (*Курчак.*) (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар.) Балалар, бүген бездә кунакта Алсу исемле курчак. Курчакны карыйк әле. Бу нәрсә? (Курчакның башына күрсәтә.) (*Баш.*) (Активлаштыру.) Курчакның башында нәрсәләр бар? (*Чәче, күзләре, борыны, авызы, колаклары.*) (Активлаштыру. Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Ә бу нәрсә? (*Курчакның гәүдәсе.*) (Активлаштыру.) Гәүдәдә нәрсә бар? (*Эч.*) (Активлаштыру.) Курчакның тагын нәрсәләре бар? (Кулларына күрсәтә.) (*Куллары.*) (Активлаштыру.) Курчакның тагын нәрсәләре бар? (Курчакның аякларына күрсәтә.) Бу нәрсәләр? (*Аяклар.*) (Активлаштыру.)

Балалар, минем күршемдә Азат исемле малай яши. Ул балалар бакчасына йөрми, шуңа күрә күп нәрсәне белми. Ул бер рәсем ясый башлаган, ләкин ясап бетерә алмаган. Азат рәсемне сезгә күрсәтергә кушты. Сез Азатка рәсемне ясап бетерергә ярдәм итәрсезме? Әйдәгез, Азатка ярдәм итик, булышыйк әле. Булышасызмы? (Рәсем мольбертка эленгән. Тәрбияче баш өлешен, борын, күзләр, авыз, колакларын ясый һәм балалардан: «Мин нәрсәләр ясадым?» — дип сорый.) (*Борын.*) (Активлаштыру.) Үзегезнең борыныгызны күрсәтегез әле. Булдырдыгыз! Бу нәрсә? (Курчакның күзләренә күрсәтә.) (*Күзләр.*) (Активлаштыру.) Күзләрегезне күрсәтегез әле. Алар безгә ни өчен кирәк? (*Күрер өчен.*) Мин нәрсә ясыйм? (Тәрбияче курчакның авызына күрсәтә.) Дөрес, балалар, мин курчакның авызын ясадым. (Активлаштыру.) Сез дә авызыгызны күрсәтегез әле. Булдырдыгыз! Мин нәрсә ясыйм? (Тәрбияче курчакның колакларына күрсәтә.) Дөрес, балалар, мин курчакның колакларын ясадым. (Активлаштыру.) Сез дә колакларыгызны күрсәтегез әле. Булдырдыгыз! Бу курчакның нәрсәсе? (*Гәүдәсе.*) (Активлаштыру.) Гәүдәдә нәрсә бар? (*Эч.*) (Активлаштыру.) Күрсәтегез әле үзегезнең эчегезне. Эч нинди, тотып карагыз әле. (*Йомшак.*) Әйдәгез, эчегезне кулларыгыз белән сыйпагыз әле, менә шулай. Ул сезнең яратканны тойсын. Курчакның тагын нәрсәләре бар? (Кулларына күрсәтә.) (*Куллары.*) (Активлаштыру.) Сез дә кулларыгызны күрсәтегез әле. (Күрсәтәләр.) Куллар безгә ни өчен кирәк? (*Әйбер тотар өчен, ашар өчен, уйнар өчен, бер-беребезне юату өчен.*) Курчакның тагын нәрсәләре бар? (Курчакның аякларына күрсәтә.) Бу нәрсәләр? (*Аяклар.*) (Активлаштыру.) Аякларыгызны күрсәтегез әле. (Күрсәтәләр.) Аяклар безгә

ни өчен кирәк?(*Йөрү өчен, йөгерү өчен, сикерү өчен.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Әйдәгез, сикереп күрсәтегез әле! (Балалар сикерәләр.) Менә курчакның бөтен өлешләрен дә ясап бетердек. Мин бу рәсемне Азатка бирермен. Азат шатлансын әле. Балалар, әйдәгез, тагын бер кат әйтеп чыгыйк һәм күрсәтик әле. (Тәрбияче тән өлешләрен атый һәм күрсәтә, балалар кабатлыйлар.) Балалар, үзебездә күрсәтик һәм кычкырып кабатлыйк әле: «Бу — минем башым. Бу — минем чәчем. Бу — минем колакларым. Бу — минем күзләрем. Бу — минем борыным. Бу — минем авызым. Бу — минем гәүдәм. Бу — минем кулларым. Бу — минем аякларым. Бу — мин! Мин үземне яратам». (Тәрбияче үз-үзен куллары белән кочаклый, балалар шуны ук кабатлыйлар.) Мин үземне бик яратам һәм саклыйм. Мин һәрвакыт сәламәт. Шуңа күрә мин көн саен битемне, күзләремне, колакларымны юам, тешләремне чистартам. Балалар, бергәләп «Бу — мин» җырын җырлыйк әле.

Менә борыным,
Бу — минем кашым,
Күзем, колагым,
Ә менә башым.
Авызны ачсам,
Телем күренә.

Тезелгән тешем
Өч бөртек кенә.
Кулны күрсәтсәм —
Аяк тыпырдый:
Үзеннән-үзе
Биергә сорый.

Балалар, сез булдырдыгыз. (Балалар кул чабалар.)

## *Дүртенче бүлек.* МИНЕМ ӘЙЛӘНӘ-ТИРӘМ

### Тема. ЯРАТКАН УЕН БҮЛМӘБЕЗ

**Бурычлар:**

1) балаларны балалар бакчасы шартларына ияләндерүне дәвам итү, төркемдәге уен бүлмәсе, андагы махсус почмаклар белән таныштыру, «һәр әйбернең үз урыны» дигән төшенчәне аңлату һәм ныгыту;

2) сүзләрне һәм кыска фразаларны ачык әйтүләренә ирешү, сүз байлыгын үстерү;

3) җиһазларга сакчыл караш һәм яшьтәшләренә карата ягымлылык тәрбияләү.

**Җиһазлар:** кәрзин (кәрзингә һәр балага җитәрлек уенчыклар салынган).

**Эшчәнлек барышы.**

Тәрбияче балаларны уен бүлмәсенә алып керә.

Тәрбияче. Балалар, менә без сезнең белән уен бүлмәсенә кердек. Бу — иң зур бүлмә. Балалар, бу бүлмә нинди: кечкенәме, зурмы? (*Зур.*) (Активлаштыру.) Карагыз әле, бу бүлмәдә нәрсәләр бар? (Активлаштыру.) Бу бүлмәдә һәрбер әйбернең үз урыны бар. Менә бу — уен почмагы. (Балаларны уен почмагына алып килә.) Уен почмагында нәрсәләр бар? (Активлаштыру.) Балалар, курчак, машина, туп, шакмаклар — боларны бер сүз белән ничек әйтергә була? (*Уенчыклар.*) (Активлаштыру.) Дөрес, уенчыклар. Уен бүлмәсендә уенчыклар күпме? (*Күп.*) Нәрсәләр күп? (*Уенчыклар.*) (Активлаштыру.) Балалар, уенчыклар белән уйнагач, аларны үз урынына куярга кирәк. Уенчыклар уен почмагында торалар. Уенчыклар кайда торалар? (*Уен почмагында.*) (Активлаштыру. Тәрбияче Айсылуга курчак бирә.) Айсылу, бу курчакны үз урынына куй әле! (Айсылу курчакны башка курчаклар янына куя). Булдырдың, Айсылу, курчак курчаклар почмагында яши. Айсылу, син курчакны кая куйдың? (*Курчаклар янына.*) Әйе, Айсылу курчакны курчаклар почмагына куйды. Балалар, курчак кайда яши? (*Курчаклар почмагында.*) (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар). Әмир, машинаны үз урынына илтеп куй әле. Булдырдың, Әмир. Әмир, син машинаны кая куйдың? (*Машиналар янына.*) Әйе, Әмир, машина да уен почмагында тора. Машинаның да үз урыны бар. Машина кайда тора? (*Уен почмагында, машиналар янында.*) (Активлаштыру. Тәрбияче балаларны китап почмагына алып килә.) Балалар, монда нәрсәләр бар? (*Китаплар.*) Бу нәрсә почмагы? (*Китап почмагы.*) (Активлаштыру.) Карагыз әле, китап почмагында нәрсәләр бар? (*Китаплар.*) (Активлаштыру.) Әйе, китап почмагында китаплар бар. Китаплар күпме? (*Күп.*) (Активлаштыру.) Бүген мин сезгә яңа китап алып килдем. (Тәрбияче балаларга китапны күрсәтә һәм берәр әсәр укый.) Динә, бу китапны үз урынына куй әле. Динә, син китапны кая куйдың? (*Китап почмагына.*) Балалар, Динә китапны кая куйды? (Активлаштыру. Тәрбияче балаларны өстәл янына чакыра. Өстәлдә бер гөл тора.) Балалар, бу нәрсә? (Активлаштыру.) Гөлнең үз урыны кайда икән? Әйдәгез, аны үз урынына илтеп куябыз. (Тәрбияче гөлне табигать почмагына илтеп куя.) Бу — табигать почмагы. Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз! (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Табигать почмагында тагын нәрсәләр бар? (Активлаштыру. Тәрбияче балаларга кәрзиннән уенчыклар алып бирә.) Балалар, бу уенчыкларны үз урыннарына матур итеп куегыз. Булдырдыгыз!

Балалар, уен бүлмәсендә тәртип булсын өчен, уенчыклар һәрвакытта үз урыннарында торырга тиеш. Алар белән уйнагач, урыннарына куярга онытмагыз!

## Тема. КамАЗ МАШИНАСЫ

**Бурычлар:**

1) балаларны КамАЗ машинасын һәм аның өлешләрен танырга, исемен әйтергә өйрәтү; уенның сүзләренә туры китереп, хәрәкәтләр ясау осталыгы булдыру;

2) балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын, хәтерен, сөйләмен, уңай эмоцияләрен үстерү;

3) балаларда йөк транспортына, өлкәннәр хезмәтенә карата кызыксыну уяту.

**Җиһазлар:** уенчык КамАЗ машинасы.

### Эшчәнлек барышы.

Тәрбияче. Балалар, тыңлагыз әле: нинди тавыш ишетелә? (Ишек артында «би-биип» дигән тавыш ишетелә.) Ишекне ачып карыйм әле, нәрсә бар икән анда? (Тәрбияче уенчык машина алып керә һәм өстәлгә куя.) Бу нәрсә? (*Машина.*) (Активлаштыру.) Бу нинди машина? (*КамАЗ машинасы.*) (Әгәр дә балалар әйтә алмаса, тәрбияче үзе әйтә. Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: «КамАЗ машинасы». (Активлаштыру.) Балалар, машинаның нәрсәләре бар? Бу нәрсә? (Кабинасына күрсәтә.) (*Кабина.*) (Активлаштыру.) Ә бу нәрсә? (*Кузов.*) (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар.) Машинаның тагын нәрсәләре бар?(*Тәгәрмәчләре.*) (Активлаштыру.) Әмир, бу машина ничек атала?(Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Әмир, машинаның тәгәрмәчләрен күрсәт әле. Әмир, син нәрсәләрне күрсәттең? (*Тәгәрмәчләрне.*) Балалар, Әмир машинаның нәрсәләрен күрсәтте? (*Тәгәрмәчләрен.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Азат, син машинаның кабинасын күрсәт. Син нәрсә күрсәттең? (*Кабинасын.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, КамАЗ машинасы нәрсә өчен кирәк? (*Ул йөк ташый.*) Балалар, КамАЗ машинасын заводта ясыйлар. КамАЗ машинасын кайда ясыйлар? (*Заводта.*) (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар.) Ленарның, Алсуның, Маратның, Диләнең әтиләре «КамАЗ» заводында эшлиләр. Алар бик тырышлар.

Балалар, юлда кешеләр, хайваннар булса, машина нәрсә эшли? (*Кычкырта, сигнал бирә.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Машина сигнал биргәндә нинди тавыш чыга?

(*«Бип-биип».*) Әйдәгез, без дә сезнең белән сигнал биреп карыйк әле: «би-биип». Бик яхшы. Балалар, беркайчан да машина юлында йөрергә ярамый. Балалар, машинаны кем йөртә? (*Шофёр.*) Хәзер, балалар, без дә шофёрлар булып уйнап алыйк. (Балалар тәрбияченең сүзләрен һәм хәрәкәтләрен кабатлыйлар.)

Тәгәрмәчкә тын өрәм
(Балалар тәгәрмәчкә тын өрү хәрәкәте ясыйлар.)

Һәм моторны кабызам.
(Куллары белән ачкыч борган хәрәкәт ясыйлар.)

Машинама утырам,
(Руль тоткан хәрәкәтне күрсәтәләр.)

Бик еракларга китәм.
Би-биип!
(Сигнал тавышын кабатлыйлар.)

Булдырдыгыз, балалар! Әйдәгез, КамАЗ машинасын үз урынына куегыз әле. Машинаны кая куярсыз? (*Машиналар почмагына.*) Бик дөрес. Ул безнең бүлмәне тагын да матурлап торсын!

## Тема. «БЕЗНЕҢ УРАМ»

**Бурычлар:**

1) балаларны урам, андагы объектлар, күренешләр белән таныштыру, аларга карата кызыксыну тудыру;

2) балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын, сүз байлыгын үстерү;

3) урамга соклану хисе тәрбияләү.

**Җиһазлар:** урам макеты: уенчыклар кибете, светофор, полиция хезмәткәре, трамвай, автобус, КамАЗ машинасы, балалар бакчасы, йортлар, Йосыф исемле курчак.

### Эшчәнлек барышы.

Тәрбияче балаларга урам макетын күрсәтә. Макетны игътибар белән карарга мөмкинлек бирә.

Тәрбияче. Балалар, монда сезгә таныш әйберләр бармы, сез нәрсәләр күрәсез? (*Өйләр, машиналар, агачлар, автобуслар* һ.б.) Балалар, бу — урам. (Активлаштыру.) Урамда нәрсәләр бар? (*Йортлар, автобус, КамАЗ машинасы, балалар бакчасы, кибетләр.*) (Активлаштыру.) Балалар, урам нинди: кечкенәме, әллә зурмы? (*Зур.*) Тагын нинди? Матурмы? (*Матур.*) (Балалар сорауларга җавап бирә алмаса, тәрбияче

үзе әйтә.) Әйе, балалар, урам зур һәм матур. (Активлаштыру.) Балалар, без хәзер Йосыф исемле малай белән танышырбыз. Менә ул. (Тәрбияче малайның контурлы сурәтен күрсәтә яки курчак куллана.) Йосыф урамга чыкты. Урамда бик рәхәт. Йосыф кояшны, иртәне сәламләде: «Исәнме, кояш! Исәнме, иртә!» Балалар, әйдәгез, без дә кабатлыйк: «Исәнме, кояш! Исәнме иртә!» Йосыф саф һава сулый. Әйдәгез, сез дә, тирән итеп, борыныгыз белән сулагыз һәм һаваны авызыгыз аша чыгарыгыз. Менә шулай. (Тәрбияче күрсәтә, балалар аның артыннан кабатлыйлар.) Булдырдыгыз! Йосыф урамны күзәтә: юлларга карап тора. Илнур, кил әле, рәсемдәге юлларны күрсәт әле. (Күрсәтә.) Илнур, син нәрсә күрсәттең? (*Юл.*) (Активлаштыру.) Балалар, бу юлдан нәрсәләр йөри? (Машиналар йөри торган зур юлга күрсәтә.) (*Машиналар.*) (Активлаштыру.) Юлда тагын нәрсәләр йөри? (*Автобус, трамвай, КамАЗ машинасы* һ.б.) Алсу, кил әле, автобусны күрсәт әле. (Күрсәтә.) Алсу, син нәрсә күрсәттең? (*Автобус.*) Балалар, Алсу нәрсә күрсәтте? (Активлаштыру.) (Шул рәвешле, тәрбияче трамвайны, КамАЗ машинасын күрсәтергә куша, балаларны активлаштыра.) Балалар, машиналарны кем йөртә? (*Шофёр.*) (Активлаштыру.) Әйдәгез, шофёрлар булып уйнап алыйк әле.

Балалар шофёрлар булып уйныйлар (узган эшчәнлектәге уен уйнала). Тәрбияче балаларны мактый.

Тәрбияче. Балалар, рәсемгә карагыз әле, бу юлдан кемнәр йөри? (Җәяүле кешеләр йөри торган юлга (тротуарга) күрсәтә.) (*Кешеләр.*) Дөрес, балалар, бу юлдан җәяүле кешеләр генә йөри, аннан машиналарга йөрергә ярамый. Йосыф та шул юлдан бара. Менә ул тукталып калды. Ул ни өчен туктаган? Бу нәрсә? (Светофорга күрсәтә.) (*Светофор.*) (Активлаштыру.) Светофорның нәрсәләре бар? (Утларына күрсәтә.) Светофорның утлары нинди төстә? (Активлаштыру.) Әйе, балалар светофорның яшел, кызыл, сары утлары бар. Кешеләр, светофорның утларына карап, юл аша чыгалар. Йосыф та, яшел ут янгач, юл аша чыкты. Менә шулай. Йосыф кибеткә керде. Йосыф кая керде? (*Кибеткә.*) (Активлаштыру.) Балалар, бу нинди кибет икән, анда нәрсәләр саталар? (*Уенчыклар кибете.*) (Балалар әйтә алмаса, тәрбияче әйтә.) Уенчыклар кибетендә нәрсә саталар? (*Уенчыклар.*) Сезнең нинди уенчыкларыгыз бар? (*Туп, машина, курчак* һ.б.) (Активлаштыру.) Йосыф уенчыклар кибетеннән күп итеп уенчыклар сатып алды. Йосыф сезне уенчыклар белән

уйнарга чакыра. (Тәрбияче балалар санынча төрле уенчыклар салынган тартма алып килә. Балаларга уенчыкларны алырга куша. Һәр бала берәр уенчык ала, һәм бергәләшеп уйныйлар.)

Балалар, Йосыф сезнең дус һәм тату уйнаганны карап торды. Ул сезне бик яратты һәм тагын килергә вәгъдә итте. Мин сездән бик канәгать, балалар!

Уен тәмамлангач, балалар уенчыкларны җыеп куялар һәм кул чабалар.

## *Бишенче бүлек.* ЯҢА ЕЛ БӘЙРӘМЕ

### Тема. ЭЛЕКТР ЛАМПАСЫ БЕЛӘН ТАНЫШТЫРУ

**Бурычлар:**

1) электр турында балаларга гади төшенчә бирү (электр тогы электр чыбыкларында «яши»; утны яндыру өчен, өзгечкә (выключательгә) басарга кирәк, шуннан соң электр чыбыкларыннан ток йөри башлый); *электр, ток, чыбык, өзгеч* (*выключатель*) сүзләре хисабына сүзлекне үстерү һәм активлаштыру;

2) балаларның игътибарын, хәтерен, кабул итү сәләтен үстерү; ток белән бәйләнешле булган куркынычсызлык кагыйдәләрен балаларга җиткерү;

3) сакчыллык тәрбияләү.

**Җиһазлар:** төнге күк йөзе сурәтләнгән рәсем, ике мольберт, ике картина-панорама (50х70 см), сары һәм ак гуашь, пумалалар.

### Эшчәнлекне оештыру.

Тәрбияче (балаларны тәрәзә янына чакырып). Балалар, урамга карагыз әле. Хәзер урамда караңгымы, әллә яктымы? (*Якты.*) (Активлаштыру.) Бүген күктә кояш күренәме? Күрсәтегез әле кояшны. (Күрсәтәләр.) Дөрес, балалар, хәзер көн, күк аяз, кояш яктырта. Кояш нинди төстә? (*Сары.*) Кояш нинди формада? (*Шар формасында.*) (Активлаштыру.) Балалар, кояш, арыгач, йокларга ята. (Тәрбияче мольбертка төнге күк йөзе сурәтләнгән рәсемне куя.) Балалар, кояш йокларга яткач, урамда караңгы була, һәм күк йөзендә ай калка. Балалар, айны без кайчан күрәбез? (*Кич белән.*) Урамда караңгы, өйдә дә караңгы. Өйдә якты булсын өчен нәрсә эшлиләр? (*Ут яндыралар.*) Әйе, сез дөрес әйтәсез, ут яндыралар. Балалар, утны ничек итеп яндыралар? (Активлаштыру.) Әйе, утны яндыру өчен, кнопкага басалар. Нәрсәгә басалар? (*Кнопкага.*) Бу кнопка өзгеч (выключатель) дип атала.

Бергәләп кабатлагыз әле: «өзгеч». (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар.) Әйдәгез, бүлмәдә утны яндырыйк. Илһам, утны яндыр әле. Илһам, син нәрсә эшләдең? Балалар, Илһам утны ничек яндырды? (*Кнопкага басты.*) Балалар, менә ут янды. Кнопкага тагын бер бассаң, нәрсә булыр икән? (*Ут сүнә.*) Ут тагын янсын өчен нәрсә эшләргә кирәк? (*Кнопкага басарга кирәк.*) Менә ут янды. Ут кайда «яши»? (*Өзгечләрдә «яши».*) Балалар, күрсәтегез әле, безнең бүлмәбездә тагын өзгечләр (выключательләр) бармы? (Күрсәтәләр.)

Балалар, хәзер бармаклар белән уен уйнап алабыз. (Ике кулның баш һәм имән бармагын тоташтыралар — «ут» яна. Бармакларны аералар — «ут» сүнә. Уен ике-өч тапкыр кабатлана. «Ут» янганда, тәрбияче өзгечтә утны яндыра, «ут» сүнгәндә сүндерә.) Әйдәгез, хәзер рәсемнәрдәге утларны яндырыйк. (Тәрбияче балаларга ике йорт рәсеме күрсәтә. Йортларның тәрәзәләре кара белән буялган.) Балалар, бу нәрсә? (*Йорт. Өй.*) Ни өчен өйнең тәрәзәләре кара төстә? (*Утлары сүнгән.*) Хәзер сезнең белән бу өйләрдә ут яндырабыз. Тәрәзәләр якты булып торсын. Карагыз әле, мин ничек итеп ут яндырам. (Тәрбияче тәрәзәне сары төскә буйый.) Алсу, кил әле, син дә утны яндыр, өйдә якты булсын! (Тәрбияче, һәр баланы чакырып, тәрәзәне гуашь белән сары төскә буята.) Менә өйләр ничек яктырып китте!

Балалар, утны яндырып яисә сүндереп уйнарга ярамый, янгын чыгуы бар. Ут пешерә. Балалар, яктылыкны электр лампасы гына түгел, кояш та бирә. Кояш чыккач, көн яктыра. Әйдәгез, кояш нурлары ясыйк әле. Кулларыгызны алга сузыгыз, бер-берегез белән кулга-кул тотынышыгыз. Үзегезне җылы кояш нуры кебек тоемлап, тыныч кына басып торыгыз. Менә безнең бүлмәбезне нинди матур кояш яктырта. Аның җылысы нурлар аша бөтен бүлмәгә тарала. Бүлмәбез тагын да якты, җылы була!

## Тема. ГИРЛЯНДА

**Бурычлар:**

1) балаларга гирлянда турында башлангыч белемнәр бирү, электр тогы турындагы күзаллауларын ныгыту; кызыл, яшел, сары төсләрне таный һәм аера белергә күнектерү;

2) балаларның игътибарын, кызыксынучанлыгын, шатлык хисләрен үстерү, сүз байлыгын киңәйтү;

3) күмәк эшчәнлектә катнашу теләге тәрбияләү.

**Җиһазлар:** тартма, гирлянда, кәрзин; яшел, сары, кызыл төстәге фонарьлар, Йомшаккай исемле уенчык песи.

**Эшчәнлекне оештыру.**

Тәрбияче «тылсымлы» тартманы күрсәтә.

Тәрбияче. Балалар, Йомшаккай безгә «тылсымлы» тартма алып килгән. Нәрсә бар икән тартманың эчендә, карыйк әле. (Тәрбияче тартманы ача һәм гирлянда ала.) Бу нәрсә? (*Гирлянда.*) Бергәләп кабатлагыз әле: «гирлянда». (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар.) Гирляндада нәрсәләр бар?(Тәрбияче лампочкаларга күрсәтә.) Кабатлагыз әле: «лампочкалар». (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар.) Гирлянданың лампочкалары янамы?(*Юк.*) Балалар, лампочкаларны өзгечнең кнопкасына басып яндырабыз. Лампочкалар янсын өчен нәрсә эшләргә кирәк? (*Өзгечнең кнопкасына басарга кирәк.*) Балалар, мин кнопкага бастым. Нәрсә булды? (*Утлар янды.*) (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар.) Ут янгач, рәхәт булып китте. Тагын кнопкага бастым, хәзер нәрсә булды? (*Утлар сүнде.*) (Активлаштыру.) Балалар, өзгечләрдә ток «яши». Өзгечләрдә нәрсә «яши»? (*Ток.*) (Активлаштыру. Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар.) Ток чыбыклар буенча (гирлянданың чыбыкларын күрсәтә) лампочкаларга килә, һәм ут кабына. Карагыз әле, кәрзиндә нинди матур фонарьлар бар. Кәрзиндә нәрсәләр бар? (*Фонарьлар.*) (Активлаштыру.) Фонарьлар күпме? (*Күп.*) Минем янга килеп, берәр фонарь алыгыз. (Алсу, Гүзәл, Әмир һ.б. берәр фонарь алалар.) Хәзер, балалар, кызыл фонарьларны яндырабыз. (Тәрбияче кәрзиннән кызыл фонарь ала һәм балаларга күрсәтә.) Кызыл фонарьны өскә күтәрегез. Менә шулай. Булдырдыгыз! Хәзер яшел фонарьны өскә күтәрегез. Мин дә яшел фонарьны өскә күтәрәм. Булдырдыгыз! Хәзер сары төстәге фонарьны яндырабыз. Сары төстәге фонарьны өскә күтәрегез. Булдырдыгыз! Хәзер кызыл, яшел, сары фонарьлар — барысы да яналар. Балалар, нинди төстәге фонарьлар яна? (*Кызыл, яшел, сары фонарьлар.*)

Балалар, сезнең фонарьларыгыз бик якты булып янды. Йомшаккайга да ошады. Без Яңа ел бәйрәмендә кызыл, яшел, сары фонарьлар белән чыршыны бизәрбез. Булдырдыгыз! (Балалар кул чабалар.)

## Тема. ЯШЕЛ ЧЫРШЫ

**Бурычлар:**

1) балалар белән чыршыны бергәләп карау, Яңа ел бәйрәме турындагы күзаллауларын киңәйтү һәм баету;

2) балаларның «Яңа ел бәйрәме» темасы буенча сүз байлыгын активлаштыру, тәрбияче соравына җавап бирү осталыгын, игътибарын, күзәтүчәнлеген, сенсор тою сәләтен үстерү;

3) матурлыкны күрә һәм соклана белү хисләре, чыршы уенчыкларына карата сакчыл караш тәрбияләү.

**Җиһазлар:** ясалма чыршы (биеклеге 90 см), тартмага салынган чыршы уенчыклары.

## Эшчәнлек барышы.

Тәрбияче балаларга чыршы күрсәтә.

Тәрбияче. Бу нәрсә? (*Чыршы.*) (Активлаштыру.) Чыршы нинди: зурмы, әллә кечкенәме? (*Кечкенә.*) (Активлаштыру.) Чыршы нинди төстә? (*Яшел чыршы.*) (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар.) Әйе, балалар, яшел чыршы. Балалар, чыршының ботаклары бармы?(*Бар.*) Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: «ботаклар». Менә ул чыршы ботаклары. (Тәрбияче күрсәтә.) Чыршы ботакларын күрсәтегез әле. (Күрсәтәләр.) Чыршының яфраклары бармы? (*Юк.*) Яфраклар урынына чыршының нәрсәләре бар? (*Энәләре.*) (Активлаштыру.) Әйе, чыршының энәләре бар. Әдилә, чыршының энәләрен күрсәт әле. (Күрсәтә.) Балалар, чыршының энәләрен тотып карагыз әле. (Балалар тотып, кадап карыйлар.) Энәләр кадыйлармы? (*Кадыйлар.*) (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар.) Дөрес, балалар, чыршының энәләре бар, алар очлы һәм кадыйлар. Балалар, әйдәгез, үзебез чыршы булып карыйк әле. Кул бармакларын менә шулай аерып куегыз, алар чыршының энәләре булсыннар. Хәзер әйләнәбез һәм кул бармакларын башка, билгә, аякларга куябыз. Менә сез нинди матур энәле чыршылар булдыгыз. Булдырдыгыз!

Балалар, тиздән нинди бәйрәм була? (*Яңа ел.*) (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар.) Балалар, бик дөрес, тиздән Яңа ел җитә. Бәйрәмгә балалар да, өлкәннәр дә әзерләнә. Балалар, без бергәләп чыршы бәйрәмендә җырлар җырларбыз, биербез, шигырьләр сөйләрбез, уйнарбыз. Шуңа күрә чыршы бәйрәменә әзерләнәбез: шигырьләр, җырлар, биюләр, уеннар өйрәнәбез. Бәйрәмгә Кыш бабай, Кар кызы, әниләр, әтиләр, әби-бабайлар да килер. Кыш бабай үзенең зур капчыгында бүләкләр алып килер. Балалар, тиздән без чыршыны бизәрбез. Чыршыны нәрсәләр белән бизәрбез икән? (*Уенчыклар белән.*) (Тәрбияче чыршы уенчыклары күрсәтә.) Әйе, чыршы уенчыклары белән бизәрбез. Бизәгәч, чыршы нинди булыр икән? Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк: «матур,

купшы». (Активлаштыру.) Иртәгә без (тартмадагы уенчыкларны күрсәтә) чыршыны бизәрбез.

Балалар, без бүген чыршы белән таныштык. Әйдәгез, чыршы турында Ә. Бикчәнтәеваның шигырен укыйк.

Яшел чыршы, тезелешеп
Әйләнәбез тирәңдә,
Куанабыз, Яңа елга
Син кунакка килгәнгә.

Балалар тәрбияче артыннан кабатлыйлар. Берәр баланы алдан әзерләргә дә була.

## Тема. ЧЫРШЫ БИЗИБЕЗ

**Бурычлар:**

1) балаларның Яңа ел бәйрәме турындагы күзаллауларын баетуны дәвам итү;

2) балаларның «Яңа ел бәйрәме» темасы буенча сүзлеген активлаштыру, тәрбияче соравына җавап бирү осталыгын, игътибарын, күзәтүчәнлеген, сенсор тою сәләтен үстерү;

3) чыршы уенчыкларына карата сакчыл караш тәрбияләү.

**Җиһазлар:** ясалма чыршы (биеклеге 90 см), тартмага салынган чыршы уенчыклары.

### Эшчәнлек барышы.

Тәрбияче. Балалар, безнең чыршы бизәлмәгән, аны уенчыклар белән бизәргә кирәк. Без бу тартмадагы уенчыклар белән чыршыны бизәрбез. (Тәрбияче тартмадан шар ала.) Балалар, бу нәрсә? (*Шар.*) Шар нинди төстә? (*Кызыл шар.*) (Активлаштыру.) Балалар, әйе, кызыл шар. Шар нинди матур, ялтырап тора. Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк: «Шар матур, ул ялтырый». (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, шар пыяладан ясалган. Балалар, шар нәрсәдән ясалган? (*Пыяладан.*) Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк: «пыяладан». (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Әгәр дә шарны идәнгә төшерсәң, ул ватыла. Балалар, менә бу шар нинди төстә? (*Сары шар.*) (Шарны чыршыга эләләр.) Ә менә бу шар нинди төстә? (*Зәңгәр шар.*) (Шарны чыршыга эләләр.) Ә менә бу шар нинди төстә? (*Яшел шар.*) (Шарны чыршыга эләләр.) Хәзер без чыршыны төрле төстәге уенчыклар белән бизәрбез. (Тәрбияче тартмадан уенчыклар ала, һәм балалар белән бергәләп чыршыны бизиләр. Тәрбияче тартмадан гирлянда ала.) Бу нәрсә? (*Гирлянда.*) Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк: «гирлянда». (Тәрбияче гирлянданың лампочка-

ларына күрсәтә.) Бу нәрсә? (*Лампочкалар.*) Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк: «лампочкалар». (Тәрбияче гирлянданың чыбыкларына күрсәтә.) Бу нәрсә? (*Чыбыклар.*) Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк: «чыбыклар». Балалар, гирлянда янамы? (*Юк.*) Әйе, гирлянда янмый. Гирляндаларны ничек яндырабыз? (*Кабызырга кирәк.*) (Тәрбияче гирлянданы чыршыга элә һәм утын яндыра.) Балалар, карагыз әле, нинди матур безнең чыршыбыз! Без чыршыны шарлар, төрле уенчыклар, гирляндалар белән бизәдек. Шарлар, гирляндалар — чыршы уенчыклары. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, чыршы уенчыклары бик тиз ватыла, шуңа күрә аларны сак кына тотарга кирәк, бәрергә, идәнгә төшерергә ярамый. Бу уенчыкларны чыршы бизәү өчен генә кулланалар.

В. Вәлиева көе һәм сүзләренә язылган «Чыршыкай-матуркай» җыры яңгырый. Балалар шатланалар, кул чабалар.

## Тема. БЕЗ МУЗЫКА ЗАЛЫНДА

**Бурычлар:**

1) чыршы бәйрәменә әзерләнү: балаларны музыка залының бизәлеше, чыршы уенчыклары (аларның материалы, төсе, формасы) белән таныштыру; *чыршы уенчыклары, йомры, пыяла, шома, ялтырый* сүзләре хисабына балаларның сүзлеген активлаштыруны дәвам итү;

2) балаларның кабул итү сәләтен, күзәтүчәнлеген, игътибарын, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;

3) балаларда эстетик хисләр тәрбияләү.

**Җиһазлар:** Яңа ел уңаеннан бизәлгән музыка залы.

### Эшчәнлек барышы.

Тәрбияче. Балалар, тиздән Яңа ел җитә. Без хәзер музыка залына барабыз. Анда нинди үзгәрешләр бар икән? (Музыка залында балаларны музыка җитәкчесе каршылый. Исәнләшәләр.) Балалар, карагыз әле, бу нәрсә? (Чыршыга күрсәтә.) (*Чыршы.*) (Активлаштыру.) Чыршы сезгә ошыймы? (Җаваплар тыңлана.) Балалар, чыршыга нәрсәләр эленгән? (*Уенчыклар.*) Сез чыршыда нинди уенчыклар күрәсез? (Тәрбияче әле бер, әле икенче уенчыкны күрсәтә. Балалар уенчыкларны карыйлар, тәрбияче ярдәм итә. Уенчыкларның төсен ныгыталар.) Балалар, бу нәрсә икән? (Тәрбияче балаларның игътибарын чыршыга эленгән шарга юнәлтә.) (*Шар.*) Дөрес, бу — шар. (Активлаштыру.) Чыршыга нинди төстәге шарлар эленгән? (*Кызыл, сары, яшел, ак* һ.б.) (Балалар әйтә ал-

маса, тәрбияче шарларны үзе күрсәтә һәм «Менә бу шар нинди төстә?», «Ә менә монысы нинди төстә?» дигән сораулар бирә.) Балалар, шарлар нәрсәдән ясалган? (*Пыяладан.*) (Активлаштыру.) Әйе, пыяладан. Шуңа күрә шарлар ватылырга мөмкин, алар белән сак эш итәргә кирәк. Балалар, шарлар ялтырыйлар. Әйдәгез, бергәләп «ялтырыйлар» дип кабатлагыз әле. (Активлаштыру.) Ә хәзер кулларыгыз белән шар ясап күрсәтегез. (Тәрбияче куллары белән шар ясап күрсәтә, балалар кабатлыйлар.) Бу нәрсә? (Чыршыга эленгән куянга күрсәтә.) (*Куян.*) Әйе, бу — куян. Балалар, ә бу нәрсә? (*Төлке.*) (Активлаштыру.) Әйе, бу — төлке. (Активлаштыру.) Алсу, кил әле, төлкене чыршы ботагына эл әле. Балалар, Алсу нишли? Дөрес, Алсу төлкене чыршыга элә. Карагыз әле, безнең чыршы нинди матур! Чыршыдагы уенчыклар ялтырыйлар. Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз әле: «ялтырыйлар». (*Ялтырыйлар.*) (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар.)

Тәрбияче һәм балалар, чыршы тирәли әйләнеп, В. Вәлиева көе һәм сүзләренә язылган «Чыршыкай-матуркай» җырын башкаралар.

Күрәсеңме, чыршыкай,
Безне, нәниләреңне.
Без бик-бик яратабыз
Синең тәтиләреңне.
Әл-лә-ли, әл-лә-ли,
Син, чыршыкай, бик тәти.

Син, чыршыкай-матуркай,
Тәтиләреңне кабыз.
Без сине бик яратып,
Шатланып кул чабарбыз.
Чәбәк-чәбәк-чәбәки,
Тәтиләрең бик тәти.

Тәрбияче. Балалар, тиздән безнең бакчада чыршы бәйрәме була. Күрәсезме, чыршыбыз Яңа ел бәйрәменә әзер. Чыршыга бик күп матур уенчыклар эленгән. Бигрәк тә төрле төстәге шарлар нык ялтырыйлар. Шарлар чыршыны тагын да купшы итәләр. Әйдәгез, чыршы тирәли түгәрәк ясап басыйк әле.

Балалар, җитәкләшеп, чыршы тирәли әйләнәләр, шатланалар.

## *Алтынчы бүлек.* КЫШ

### Тема. АП-АК КАР ЯВА

**Бурычлар:**

1) балаларны кар һәм аның үзлекләре (ак төстә, эри, йомшак, салкын, җиңел) белән таныштыру, тәрбияче сорауларына җавап бирергә күнектерү;

2) балаларның сүз байлыгын, игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерү;
3) кышкы табигатькә соклану хисе, бергәләп уйнау теләге тәрбияләү.

**Җиһазлар:** трафаретлар (шар, гөмбә, йолдыз, куян һ.б.).

### Эшчәнләк барышы.

Эшчәнлек саф һавада мәйданчыкта уза. Тәрбияче, балаларны үз янына җыеп, шигырь укый.

Тәрбияче. Йомшак кына кар яуды,
Бөтен җирне каплады.
Ап-ак булды урамнар,
Ап-ак булды түбәләр.

Балалар, карагыз әле, күпме кар яуган! Кар нинди төстә? (*Ак кар.*) (Активлаштыру.) (Тәрбияче карны, кулына алып, балаларга күрсәтә.) Балалар, бияләйләрне салмыйча, карны кулыгызга алыгыз әле. Кар җиңелме, әллә авырмы? Кар бик җиңел. Аз гына җил иссә дә очып китәргә тора. Менә ул ничек оча. (Учындагы карны өреп, очырып күрсәтә.) Кар нишли? (*Оча.*) Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз: «Кар оча». (Активлаштыру.) Балалар, карагыз әле, кар бөртекләре, очып, җиргә төшә. Бөтен җир кар белән тула. Хәзер кар белән уйнап алыйк.

Динамик пауза. Балалар иеләләр, куллары белән карны үзләренә таба «көриләр». Кулларны ике якка сузып, карны уңнан һәм сулдан уртага «көриләр». Тураялар, куллары белән шар ясыйлар. Сул аякны алга чыгарып, гәүдә белән җиңелчә алга иелеп, уң кул белән кар ату хәрәкәте ясыйлар.

Тәрбияче: Ап-ак йомшак карны
Кулыма алам.
Аннан шар ясыйм
Һәм алга атам.

(Кулына кар ала, балаларга аның ничек эрегәнен күрсәтә.) Балалар, мин кулыма кар алдым, карагыз әле, ул нишли? (*Кар эри.*) Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле. (Активлаштыру.) Балалар, безнең учлар җылы. Җылыда кар эри һәм суга әйләнә. Кар җылымы, әллә салкынмы? (*Салкын.*) (Активлаштыру. Тәрбияче балаларга төрле фигуралы трафаретлар тарата.) Балалар, без хәзер трафаретлар белән карда рәсемнәр ясыйбыз. Карагыз әле, минем трафарет гөмбә ясый. Гүзәл (Марат, Әдилә, Әдип һ.б.), сезнең трафаретлар нәрсә ясый? (Активлаштыру.) Балалар, сезнең рәсемнәрегез бик ма-

тур. Булдырдыгыз! Сезнең рәсемнәр белән безнең мәйданчык тагын да матурланды. Карагыз әле, бөтен җир ап-ак кар белән капланган. Кар чиста, һаваны сафландыра. Борын белән, тирән итеп, саф һава сулагыз. Менә шулай. (Күрсәтә.) Хәзер һаваны авыз аша чыгарыгыз. Саф һава сәламәтлек бирә. Сәламәт булыгыз!

## Тема. АЛСУ УРАМГА ҖЫЕНА

**Бурычлар:**

1) балаларның кышкы киемнәр турындагы белемнәренә төгәллек кертү; урамга чыкканда киенү эзлеклелеген һәм киемнәрне истә калдыру, тәрбияче сорауларына җавап бирергә күнектерү;

2) балаларның игътибарын, хәтерен, фикерләвен, сүз байлыгын үстерү;

3) башкаларга ярдәм итү теләге булдыру, киемнәргә сак караш тәрбияләү.

**Җиһазлар:** «тылсымлы» тартма, Алсу исемле курчак, кышкы киемнәр.

### Эшчәнлек барышы.

Тәрбияче. Балалар, безгә бүген Алсу исемле курчак кунакка килгән. (Курчакны күрсәтә.) Ул бик матур итеп киенгән. Күлмәк, носки, туфли кигән. Алсу урамга чыгарга җыена. Ул күлмәкчән генә урамга чыга аламы? (*Юк.*) Ни өчен? (*Урамда кар ява. Салкын. Алсуга җылы киемнәр кирәк.*) Балалар, Алсуга нинди киемнәр кирәк булыр икән? (Активлаштыру.) Балалар, бу нәрсә? (Тартма күрсәтә.) (*Тартма.*) Әйе, бу — «тылсымлы» тартма. Балалар, тартма эчендә нәрсә бар? Әйдәгез, карыйк әле. Камил, кил әле, тартманы ачып кара. Анда нәрсә бар? (*Киемнәр.*) Карагыз әле, Камил дөрес әйтәме? (Активлаштыру.) (Тәрбияче тартмадан куртка ала). Балалар, бу нәрсә? (*Куртка.*) Курткaның нәрсәләре бар? (Активлаштыру.) Бу нәрсә? (Яка һәм капюшонга күрсәтә.) Әйе, бу — яка, капюшон. (Активлаштыру.) Ә менә бу нәрсә? (*Җиң.*) Бу нәрсә? (Икенче җиңгә күрсәтә.) (*Җиң.*) Әдип, кил әле, курткaның җиңнәрен күрсәт әле. Син нәрсәне күрсәттең? (*Җиңнәрне.*) Курткaның тагын нәрсәләре бар? (Сәдәпләренә, замогына күрсәтә. Берәр баланы сәдәпләрен, замогын күрсәтергә чакыра.) Куртка нинди төстә? (*Кызыл куртка.*) Урамнан кергәч, курткaны кая эләләр? (*Элгечкә.*) Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: «элгечкә эләләр». (Тәрбияче курткaны элгечкә элеп куя. Икенче балага тартмадан башлык алырга кушалар.) Балалар, Гүзәл тартмадан нәрсә алды? (*Башлык.*) Мә, Алсу, башлыгыңны ки! (Башлыкны

курчакка бирә.) Башлыкны башка кияләрме? (*Башка.*) (Активлаштыру.) Балалар, Алсуның башлыгы матурмы? (*Матур.*) Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз әле: «Нинди матур башлык!» Ә бу нәрсә? (*Чалбар.*) (Активлаштыру.) Бу нәрсә? (*Итекләр.*) (Активлаштыру.) Итекләрне аякка кияләрме? (*Аякка.*) (Активлаштыру.) Бу нәрсә?(*Шарф.*) (Активлаштыру.) Шарфны муенга бәйлиләрме? (*Муенга.*) (Активлаштыру.) Бу нәрсә? (*Бияләй.*) (Активлаштыру.) Аны кулларга кияләрме? (*Кулларга.*) (Активлаштыру.) Балалар, Алсу урамга чыгарга җыена. Ул курткасын киде. Балалар, Алсу дөрес киенәме? Ул хәзер кофтасын кия алырмы? Әйдәгез, балалар, Алсуга киенергә ярдәм итик әле. Урамда салкын. Алсу җылы киенсен. Балалар, Алсу нәрсәләр кияр?(Активлаштыру. Тәрбияче балалар белән бергә курчакны киендерә.) Алсу кыш көне колготки, җылы чалбар, кофта, итек, аннан курткасын кия. Башына башлык кия, муенына шарф бәйли, кулларына бияләйләр кия. (Тәрбияче курчакны чишенү бүлмәсенә алып чыга, алар бергәләп балаларның ничек киенүен күзәтәләр. Дөрес киенмәүче балаларга ярдәм итәләр.)

Балалар, шкафтан киемнәрнең кирәклесен генә алырга кирәк. Киемнәрне идәнгә ташларга ярамый. Булдырдыгыз, балалар! (Балалар кул чабалар.) Балалар, Алсуны да үзебез белән урамга алып чыгабыз. Ул да саф һава суласын.

## Тема. ЛӘЙЛӘ СУЫКТАН КУРЫКМЫЙ (рәсем буенча)

**Бурычлар:**

1) рәсемне карарга, рәсемдә ясалган предметларны танырга, исемнәрен дөрес әйтергә өйрәтү; предметларны, эш-хәрәкәтне, төсне белдерә торган сүзләр ярдәмендә сүзлекне активлаштыру, рәсем эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә күнектерү;

2) кабул итү сәләтен, игътибарны, хәтерне үстерү;

3) сюжетлы рәсемнәр карарга теләк уяту.

**Җиһазлар:** «Ләйлә суыктан курыкмый» рәсеме.

### Эшчәнлек барышы.

Мольбертка рәсем куелган. Тәрбияче Һ.Такташ шигырен укый.

Тәрбияче: Урамнар бүген сөенгән,
Ап-ак кардан киенгән.
Ләйлә чанасын өстерәп
Чыгып китте өеннән.

Ләйлә суыктан курыкмаган, чанасын алып, урамга чыккан. Үзе белән уенчык аюын да алган. (Тәрбияче балаларга рәсемне карарга мөмкинлек бирә, пауза ясый. Балалар рәсемне карыйлар, үз фикерләрен белдерәләр.) Дилә, кил, рәсемдәге кызны күрсәт әле. Кызның исеме ничек? (*Ләйлә.*) (Активлаштыру. Берничә бала Ләйләне күрсәтә, аның исемен атый.) Ләйлә үзе белән урамга нинди уенчык алган?(*Аю.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Аюны күрсәтегез әле. (Активлаштыру.) Бу нәрсә? (*Аю.*) Аю нишли? (*Чанада утыра.*) Әйе, аю чанада утыра. (Тәрбиячегә ияреп кабатлыйлар: «Аю чанада утыра».) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Булдырдыгыз, балалар! Аюга күңелле, урамда бик рәхәт. Ләйлә нәрсә эшли? (*Йөри.*) Ләйлә йөриме, әллә йөгерәме? Ләйлә нәрсә тартып йөри? (*Чана.*) Әйе, балалар, Ләйлә аюны чанада йөртә. (Әлеге фразаны ике-өч бала кабатлый.) Бөтен җирдә ап-ак кар. Агачлар, эскәмия нәрсә белән капланган? (*Кар белән.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Урамда җылымы, салкынмы? (*Салкын.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Ләйләгә салкын түгел. Ни өчен салкын түгел икән? (Активлаштыру.) Ләйлә җылы куртка, аякларына җылы итекләр кигән. Аңа салкын түгел. (Активлаштыру. Ләйләнең башлыгын, шарфын, итеген, бияләйләрен карыйлар.)

Балалар, әйдәгез, сез дә Ләйлә кебек җылы итеп киенегез! Урамга чыгабыз, чана шуабыз. (Балалар шатланып кул чабалар.)

## Тема. КҮГӘРЧЕННӘР, ЧЫПЧЫКЛАР — БЕЗНЕҢ НӘНИ КОШЧЫКЛАР

**Бурычлар:**

1) мәйданчыктагы җимлеккә килгән кошларны күзәтү, исемнәрен әйтү; *гөр-гөр, чырык-чырык, кар-кар* аваз ияртемнәрен ачык итеп әйтергә күнектерү; *томшык, сикерә, гөрлиләр, җим, чүплиләр, чырылдый, җитез, өлгер* сүзләре хисабына сүзлекне баету;

2) балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;

3) кошлар турында кайгырту, аларга ярдәм итү теләге тәрбияләү.

**Җиһазлар:** кошларга сибү өчен көнбагыш төше, төрле ярмалар.

### Эшчәнлек барышы.

Эшчәнлекне урамда оештыру мөмкин булмаса, тәрбияче, кошлар сурәтләнгән рәсемнәр файдаланып, аны бүлмәдә үткәрә.

Т ә р б и я ч е. Балалар, без хәзер киенербез һәм урамга чыгарбыз. Безнең мәйданчыкка нинди кошлар килгән икән, аларны күзәтербез һәм сыйларбыз. (Тәрбияче балаларны мәйданчыкка алып чыга, ярымтүгәрәк ясап бастыра. Тәрбияче кошларга җим сибә, балалар аларны күзәтәләр.) Балалар, карагыз әле, безгә нинди кошлар очып килгән? (*Чыпчыклар һәм күгәрченнәр.*) (Активлаштыру.) Балалар, күгәрченнәр зур, ә чыпчыклар кечкенә. Балалар, нәрсә зуррак: күгәрченнәрме, әллә чыпчыклармы? (*Күгәрченнәр.*) Ә нәрсәләр кечерәк? (*Чыпчыклар.*) Бик дөрес. (Балалар индивидуаль һәм күмәк җавап бирәләр. Тәрбияче кошларга җим сибә. Кошларны куркытмас өчен, балаларга тынычрак булырга, тавышланмаска куша. Активлаштыру.) Кыш көне кошларга азык табуы бик читен. Үләннәр дә, бөҗәкләр дә юк. Әйдәгез, кошларны ашатыйк. Бу — җимлек. Бу нәрсә? (*Җимлек.*) (Активлаштыру.) Җимлекне агачка эләбез һәм аңа ярма бөртекләре сибәбез. (Күрсәтә.) Җимлеккә нәрсә сибәбез? (*Ярма бөртекләре*). (Активлаштыру.) Җимлеккә нәрсәләр килә? (*Кошлар.*) (Активлаштыру.) Балалар, кошлар күпме? (*Күп.*) (Активлаштыру.) Балалар, карагыз әле, кошлар ничек итеп җим чүплиләр? Алар туңганнар, ашыйсылары килгән.

Ә хәзер мин сезгә табышмак әйтәм:

Гөлдер-гөлдер-гөлдер бу,
Кызыл тәпи, кемдер бу?

Балалар, табышмакның җавабын әйтегез әле. (*Күгәрчен.*) (Балалар әйтә алмаса, тәрбияче аларның игътибарын кайсы кошның кызыл тәпиле булуына юнәлтә.) Балалар, күгәрченнәрне чакырыгыз әле. (Балалар «гөр, гөр, гөр» дип кабатлыйлар. Тәрбияче балаларга җим бирә, алар аны кошларга сибәләр.) Балалар, күгәрченнәрне карагыз әле, алар җим чүплиләр. Камил, күгәрченнәр нишлиләр? (*Көнбагыш чүплиләр.*) Көнбагышны нәрсә белән чүплиләр?(*Томшыклары белән.*) (Активлаштыру.) Балалар, күгәрченнәр ничек итеп җим чүплиләр, күрсәтегез әле. (Күрсәтәләр.) Күгәрченнәр бер-берсе белән бик дус, матур итеп сөйләшәләр: гөр-гөр киләләр — гөрлиләр. Балалар, күгәрченнәр ничек сөйләшәләр? Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз әле: «Күгәрченнәр гөрлиләр». (Активлаштыру.) Балалар, күгәрченнәр тагын нәрсә эшли беләләр? (Балалар әйтә алмаса, тәрбияче: «Тәпиләре ни өчен кирәк?» — дип сорый.) Әйе, күгәрченнәр йөриләр. Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз әле: «Күгәрченнәр йөриләр». Күгәрченнәр безнең балалар бакчасына ничек килеп җит-

кәннәр соң? (Тәрбияче балаларның игътибарын күгәрченнәрнең канатына юнәлтә.) Очып килгәннәрме? Әйе, алар очып килгәннәр. Күгәрченнәр очалар. Бергәләп кабатлагыз әле: «Күгәрченнәр очалар». Балалар, күгәрченнәр янында тагын нинди кошлар бар? (*Чыпчыклар.*) Балалар, чыпчыклар кечкенә. Чыпчыклар нинди: зурмы, кечкенәме? (*Кечкенә.*) Әйе, чыпчыклар кечкенә, ләкин алар бик җитез һәм өлгер. Чыпчыклар нинди? (*Җитез, өлгер.*) (Балалар бергәләп һәм аерым-аерым *җитез, өлгер* сүзләрен кабатлыйлар.) Җитез булгач, көнбагышларны бик тиз эләктереп алалар. Җимне тиз генә эләктермәсәләр, зуррак кошлар — күгәрченнәр чүпләп бетерә. Чыпчыклар җим чүплиләр. Алар нинди тавыш чыгаралар? (*«Чырык-чырык».*) Әйдәгез, чыпчыклар булып чыркылдап алыгыз әле. (*«Чырык-чырык».*) Чыпчыклар чыркылдый. Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз әле: «Чыпчыклар чыркылдый». (Тәрбияче кошларга кабат җим сибә.) Балалар, тагын бер кош очып килде, ләкин нигәдер ул җим чүпләми. Безнең киткәнне көтеп тора. Нинди кош икән ул? (*Ала карга.*) Ала карга ничек кычкыра? (*«Кар-кар».*) (Активлаштыру.) Балалар, кошларның нәрсәләре бар? (*Башы, күзләре, томшыгы, гәүдәсе, койрыгы, канатлары, тәпиләре.*) (Активлаштыру.)

Балалар, әйдәгез, бер уен уйнап алабыз. Сез күгәрченнәр, чыпчыклар булырсыз, ә мин ала карга булам. Сез җим чүпләгез, чыпчыклар сыман сикерегез, очыгыз. Мин «кар-кар» дип әйткәч, агач төбенә качыгыз. (Уен ике-өч тапкыр кабатлана.)

Балалар, булдырдыгыз! Без сезнең белән кошлар турында сөйләштек. Кошлар төрле-төрле һәм бик матурлар. Кошларны яратырга, кыш көне аларны ашатырга кирәк. Чөнки урамда кар һәм салкын, аларга азык табуы бик кыен. «Гөргөр», «чырык-чырык», «кар-кар» дип, алар безгә рәхмәт әйтәләр.

## *Җиденче бүлек.* ӘТИЛӘР ҺӘМ ӘНИЛӘР, БАБАЙЛАР ҺӘМ ӘБИЛӘР

### Тема. БЕЗНЕҢ ӘТИЛӘР (сюжетлы рәсемнәр карау)

**Бурычлар:**

1) балаларны әтиләр һөнәренә кагылышлы сюжетлы кечкенә рәсемнәрне карарга, аларның эчтәлеген аңларга өйрәтү; эш-гамәлләрне белдерә торган сүзләр хисабына балаларның сүз байлыгын үстерү;

2) балаларның игътибарын, хәтерен, фикерләвен, куелган сорауларга кыска җөмлә белән җавап бирү осталыгын, сүз байлыгын үстерү;

3) төрле һөнәр кешеләренә һәм этиләр хезмәтенә карата кызыксыну уяту.

**Җиһазлар:** шофёр, төзүче сурәтләнгән сюжетлы кечкенә рәсемнәр.

## Эшчәнлек барышы.

Т ә р б и я ч е. Балалар, хәзер без бергәләп бармак уены уйныйбыз.

Бу бармак — бабай,
Бу бармак — әби,
Бу бармак — әти,
Бу бармак — әни,
Бу бармак — нәни бәби,
Аның исеме — Чәнти.

Балалар, бу бармак — әти. (Тәрбияче урта бармакны күрсәтә.) Сез дә күрсәтегез әле. (Балалар урта бармакны күрсәтәләр.) Бүген без этиләр, алар эшли торган эшләр турында сөйләшербез. (Тәрбияче балаларның игътибарын мольбертта эленеп торган рәсемгә юнәлтә һәм карарга мөмкинлек бирә.) Балалар, бу кем? (*Шофёр.*) (Әгәр балалар җавап бирә алмаса, тәрбияче үзе әйтә һәм аларны активлаштыра.) Шофёр кайда утыра? (*Машинада.*) (Активлаштыру.) Балалар, шофёр машина кабинасында утыра. Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: «кабинада». (Активлаштыру.) Алмаз, кил әле, машинаның кабинасын күрсәт әле. Булдырдың! Балалар, Алмаз машинаның нәрсәсен күрсәтте? (*Кабинасын.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Бу нәрсә? (Тәрбияче машинаның кузовына күрсәтә.) (*Кузов.*) Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: «кузов». (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Гадел, кил әле, машинаның тәгәрмәчләрен күрсәт. Балалар, Гадел машинаның нәрсәләрен күрсәтте? (*Тәгәрмәчләрен.*) Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: «тәгәрмәчләр». (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, бу җиңел машинамы, әллә йөк машинасымы? (*Йөк машинасы.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, бу машина йөк ташый. (Активлаштыру.) Машинаны кем йөртә? (*Шофёр.*) (Активлаштыру.) Балалар, шофёр машина йөртә һәм машинада йөк ташый. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, машинаның кузгалып киткәнен карыйк әле. Машина кузгалып киткәндә, шофёр ниш-

ли? (*Сигнал бирә.*) Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: «сигнал бирә». Шофёр ничек итеп сигнал бирә? (*«Би-биип».*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.)

Балалар, безнең төркемгә йөрүче Айгиз, Алмаз, Ләйсән, Лилиянең этиләре шофёр булып эшлиләр, зур машиналарда йөк ташыйлар. Аларның этиләре бик тырышлар. Көн саен, иртүк торып, кибетләргә, төзелешләргә, бакчаларга кирәкле йөкне илтәләр. Аларга хәерле юл телик. Хәзер шофёр булып уйнап алабыз.

Тәгәрмәчкә тын өрәм
(Балалар насос белән тын өрү хәрәкәте ясыйлар.)

Һәм моторны кабызам.
(Ачкычны борып, машинаны кабызалар.)

Машинама утырам,
(Рульне уңга-сулга борып йөгерәләр.)

Бик еракларга китәм.
Би-биип!
(Сигнал тавышын кабатлыйлар.)

(Тәрбияче мольбертка төзүче рәсемен куя һәм балаларга карарга мөмкинлек бирә.) Балалар, бу — төзүче. Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: «төзүче». Төзүче йортлар төзи. Йорт салу өчен, кирпеч, измә кирәк. Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: «кирпеч, измә». (Тәрбияче рәсемне күрсәтә.) Балалар, күрәсезме, төзүчеләр нинди зур йорт төзегәннәр. Йорт матур һәм биек. Илназның да этисе төзүче булып эшли. Хәзер ул этисе турында шигырь сөйләр. (Илназ шигырь сөйли.)

Минем әти кирпеч сала,
Шәп итеп, тыгыз итеп.
Матурлап, сырлап, шомартып,
Турылап, тигез итеп.

Тәрбияче. Булдырдың, Илназ, этиең турында бик матур шигырь сөйләдең. Балалар, Алсу, Данил һәм Камилнең этиләре дә — төзүчеләр. Аларның этиләре дә матур йортлар салалар, бик уңганнар.

Балалар, безнең этиләр арасында төзүчеләр дә, шофёрлар да, табиблар да, укытучылар да, юристлар да бар. Алар бик тырышып эшлиләр, үз хезмәтләрен яраталар. Сез дә, алар кебек, хезмәтне яратыгыз, этиләрегезгә охшарга тырышыгыз. Хәзер, әйдәгез, без дә төзүчеләр булып уйныйбыз, төзү материалларыннан биек йортлар салабыз. (Тәрбияче балаларга Lego конструкторлары тәкъдим итә.)

## Тема. БЕЗНЕҢ АПА
## (тәрбияче ярдәмчесенең хезмәтен күзәтү)

**Бурычлар:**

1) тәрбияче ярдәмчесе хезмәте белән бәйле эш-хәрәкәтләрне әйтергә өйрәтү (савыт-саба юа, ашарга алып килә, сөлгеләрне алмаштыра, бүлмәне җыештыра һ.б.); сүзлекне активлаштыру, яңа сүзләр белән баету; уенчыкларны күләмнәре (зур, кечкенә) буенча классификацияләргә өйрәтү;

2) балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерү, тәрбиячене ишетү һәм сорауларга җавап бирү, катлаулы булмаган биремнәрне үтәү осталыгын үстерү;

3) әйләнә-тирәдәге кешеләр хезмәтенә кызыксыну һәм тыңлаучанлык тәрбияләү.

**Җиһазлар:** кызыл һәм зәңгәр төстәге ике тартма, зур һәм кечкенә шакмаклар.

### Эшчәнлек барышы.

Тәрбияче. Балалар, безнең бакчада сезне ашатучы, савыт-сабаларны юучы, урамга чыкканда киенергә булышучы апабыз бар. Ул — Галия апа. Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: «Галия апа». Сез аны яратасызмы? (*Әйе.*)

Безнең Галия апабыз  
Әниебез шикелле:  
Тәмле ашлар ашата,  
Савыт-сабаны юа,  
Бүлмәне җыештыра,  
Әкият сөйләп йоклата,  
Киенергә булыша,  
Киемнәрне элешә —  
Менә нинди уңган ул!  
Бар эшкә дә булган ул!

Балалар, Галия апа бик уңган, ул савыт-сабаларны: тәлинкәләрне, чынаякларны, кашыкларны юа. (Активлаштыру.) Галия апагыз нәрсәләрне юа? (Тәрбияче балаларга чынаяклар, тәлинкәләр, кашыклар күрсәтә. Балалар җавап бирәләр.) (*Тәлинкәләрне, чынаякларны, кашыкларны юа.*) Балалар, сез Галия апагызга булышасызмы? (*Әйе.*) Ашагач, тәлинкәне, чынаякны юарга илтәсез. (Активлаштыру.) Әйе, балалар, сез Галия апагызга булышасыз. Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: «Без Галия апага булышабыз». Нәрсә эшлисез? (*Булышабыз.*) (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар.) Балалар, карагыз әле, безнең бүлмәбез чистамы? (*Чиста.*) (Активлаштыру.) Дөрес әйтәсез, бүлмәбез чиста, чөнки Галия апа тузанны сөртә, идәнне юа, бүлмәләрне җыештыра. Сез урамга

чыкканда киенергә кем булыша? (*Галия апа.*) Дөрес, балалар, безгә киенергә Галия апабыз булыша. Балалар, карагыз әле, кемдер идәндә шакмаклар калдырып киткән. Әйдәгез, Галия апага булышабыз: шакмакларны тартмага җыеп куябыз. Шакмаклар күпме? (*Күп.*) (Активлаштыру.) Аларның зурлары да, кечкенәләре дә бар. Балалар, зур шакмакларны кызыл, ә кечкенә шакмакларны зәңгәр тартмага салыгыз. Әмир, синдә нинди шакмак: кечкенәме, әллә зурмы? (*Зур.*) (Активлаштыру.) Әдилә, ә синең шакмагың зурмы, әллә кечкенәме? (*Кечкенә.*) (Активлаштыру.) Балалар, булдырдыгыз! Шакмакларны бик тырышып җыйдыгыз. Менә нинди тәртип ясадыгыз. Галия апагыз бик сөенде. Ул сезгә рәхмәт әйтә.

## Тема. «АЛСУ БӘЙРӘМГӘ ҖЫЕНА» ДИДАКТИК УЕНЫ

**Бурычлар:**

1) өс киемнәре, аларның төсе һәм материалы белән таныштыруны дәвам итү, сүзлекне активлаштыру: *ефәк, ак, чәчәкле* кебек яңа сүзләр кертү;

2) балаларның игътибарын, хәтерен, фикерләвен, сорауларны ишетә һәм аларга бер сүз яки кыска җөмлә белән җавап бирү осталыгын үстерү;

3) курчаклар белән уйнарга теләк уяту, уенчыкларга сакчыл караш тәрбияләү.

**Җиһазлар:** яшел күлмәк, ак майка, трусик, оекбаш һәм туфли кигән Алсу исемле курчак; кызыл җирлеккә ак борчаклар төшкән челтәрле кызыл күлмәк, ак носки, кызыл туфли; мольберт, көлеп торган кояш рәсеме.

### Эшчәнлек барышы.

Тәрбияче. Балалар, Алсу исемле курчак бәйрәмгә җыена. Аңа матур күлмәк кияргә кирәк. Курчакка игътибар белән карагыз әле, ул ничек киенгән? Курчакның күлмәге нинди төстә? (*Яшел.*) Әйдәгез, аның яшел күлмәген салдырыйк әле. Әминә, Алсуның күлмәген салдыр әле. (Тәрбияче булыша.) Әминә, син нәрсә эшләдең? (*Алсуның күлмәген салдырдым.*) Булдырдың, Әминә. Курчак тагын нәрсә кигән? (*Майка.*) Майка нинди төстә? (*Ак.*) Ә тагын нәрсә кигән? (*Трусик.*) Алия, курчак аягына нәрсәләр кигән? (*Носки һәм туфли.*) (Активлаштыру.) Шамил, кил әле, Алсуның оекбашын һәм туфлиен салдыр әле. Шамил, син курчакның нәрсәләрен салдырдың? (*Носкиен, туфлиен.*) (Активлаштыру.) Алсу, хәзер без сине матур итеп киендерәбез. Балалар, карагыз әле, нинди матур күлмәк! Күлмәк ефәктән тегелгән. Кызыл

төстә. Ак борчаклар төшкән. Күлмәкнең ак челтәрләре бар. Кулъяулык салу өчен, кесәсе дә бар. Күлмәк нинди төстә? (*Кызыл.*) Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: «кызыл». Күлмәк нәрсә белән бизәлгән? («Ак борчаклар белән» дип, тәрбияче артыннан кабатлыйлар.) Күлмәкнең тагын нәрсәсе бар? (*Кесәсе бар.*) Бу нәрсә? (*Кесә.*) (Активлаштыру.) Балалар, сезнең киемегездә кесә бармы, күрсәтегез әле. (Күрсәтәләр.) Әдилә, кил әле, күлмәкне тотып кара әле. Ул матур, йомшак, җиңел, ефәктән тегелгән. Күлмәк нинди? (*Ефәк. Йомшак. Җиңел*). (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар.) Балалар, курчакның матур бант бәйлисе килә. Әйтегез әле: Алсуга нинди төстәге бант килешер икән? (Әйтә алмасалар, «акмы, кызылмы» дип, тәрбияче ярдәм итә. Балалар сайлыйлар.) Ә хәзер Алсуга ак оекбаш һәм кызыл туфли кидерергә кирәк. Рания, булыш әле миңа. Без нәрсә эшлибез? (*Ак оекбаш һәм кызыл туфли кидерәбез.*) Балалар, без Рания белән нәрсә эшләдек? (Активлаштыру.) Дөрес, балалар, ак оекбаш, кызыл туфли кидердек. (Активлаштыру.) Күрегез әле, балалар, Алсу ничек матур киенде! Хәзер ул әниләр бәйрәменә бара. Алсу ак борчаклы кызыл ефәк күлмәк кигән. Күлмәкнең ак челтәрләре һәм кесәсе бар. Кесәсенә кулъяулык салган. Аякларына ак оекбаш һәм кызыл туфли кигән. Башында ак бант. Алсу бик матур! Балалар, әйдәгез, «Алсу бик матур!» дип, бергә кабатлыйбыз. (Кабатлыйлар.) Балалар, Алсу нинди бәйрәмгә бара? (*Әниләр бәйрәменә.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, булдырдыгыз! Алсу да шатлана. Мин сездән бик канәгать. Балалар, сезне сәламләп, кояш елмая (кояш рәсемен мольбертка куя). Әйдәгез, балалар, хәзер Алсу белән бергәләп биеп алыйк.

Тыпыр-тыпыр басамын,
(Аяклар белән тыпырдыйлар.)

Аннары әйләнәмен.
(Әйләнәләр.)

Башны уңга борамын,
Башны сулга борамын,
(Башны, ике кул белән тотып, уңга-сулга боралар.)

Ә аннары сикерәмен.
(Сикерәләр.)

Булдырдыгыз, балалар. Алсуны матур итеп киендердек, бергәләп биедек. Алсу да сезгә рәхмәт әйтә. Тиздән без дә, матур киенеп, әниләр бәйрәменә барырбыз.

## Тема. БЕЗНЕҢ ӘНИЛӘР
## (сюжетлы рәсемнәр карау)

**Бурычлар:**

1) балаларны әниләр һөнәренә кагылышлы сюжетлы кечкенә рәсемнәрнең эчтәлеген аңларга өйрәтү; эш-хәрәкәтне белдерә торган сүзләр хисабына балаларның сүз байлыгын үстерү;

2) балаларның кабул итү сәләтен, куелган сорауларга кыска җөмлә белән җавап бирү осталыгын, игътибарын үстерү;

3) төрле һөнәр кешеләренә һәм әниләр хезмәтенә карата кызыксыну, хөрмәт тәрбияләү.

**Җиһазлар:** Йомшаккай исемле уенчык песи, мольберт, әни-пешекче, әни-табибә, әни-сатучы төшерелгән сюжетлы кечкенә рәсемнәр.

### Эшчәнлек барышы.

Тәрбияче. Балалар, безгә кунак килгән. Сез аны таныйсызмы? (*Йомшаккай.*) Әйе, Йомшаккай. Исәнләшик әле Йомшаккай белән. (Исәнләшәләр.) Балалар, карагыз әле, Йомшаккай безгә матур рәсемнәр алып килгән. (Тәрбияче мольбертка табибә төшерелгән сюжетлы кечкенә рәсем куя һәм балаларга карарга мөмкинлек бирә.) Камил, бу рәсемдә кем сурәтләнгән? (*Врач.*) Балалар *врач* сүзе татарча табиб була. Монда врач — апа кеше. Шуңа күрә ул табибә була. Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз әле: «табибә». (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар.) Табибә өстенә нәрсә кигән? (*Халат.*) Башына нәрсә кигән? (*Калпак.*) Халат һәм калпак нинди төстә? (*Ак.*) Табибә авыру кешеләрне дәвалый. Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: «Табибә дәвалый». (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар.) Табибә балаларны, әтиләрне, әниләрне, әби-бабайларны дәвалый. Ул аларның сәламәтлеге турында кайгырта. Лилиянең әнисе дә — табибә. Ул да авыруларны дәвалый. Лилиянең әнисе бик ягымлы.

Тәрбияче мольбертка әни-пешекче сурәтләнгән сюжетлы кечкенә рәсемне куя һәм балаларга карарга мөмкинлек бирә.

Тәрбияче. Балалар, рәсемдә пешекче сурәтләнгән. Пешекче — аш-су әзерләүче кеше ул. Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: «пешекче». (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар.) Пешекче алъяпкыч япкан. Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: «алъяпкыч». (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар.) Пешекче башына нәрсә кигән? (*Калпак.*) (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар.) Балалар, пешекче ашлар, боткалар, тәмле кабартмалар пешерә. Балалар, ул пешергән ризыклары тәмле булсын дип тырыша. Тәмле ризыкларны ашагач, сез зур һәм акыллы булып үсәрсез. Азатның да әнисе — пешекче. Ул

ашханәдә тәмле-тәмле ризыклар пешерә. (Тәрбияче мольбертка сатучы төшерелгән сюжетлы кечкенә рәсем куя һәм балаларга карарга мөмкинлек бирә.)

Балалар, бу рәсемдә сатучы сурәтләнгән. Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: «сатучы». (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Сатучы кибеттә эшли. Сатучы кайда эшли? (*Кибеттә.*) Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: «кибеттә». (Активлаштыру.) Сатучы сөт, ипи, күмәч сата. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.)

Тәрбияче шигырь укый.

Ә менә минем апа
Конфет-перәнник сата.
Ул эшләгән кибеттә
Бар ак күмәч, бар сөт тә.

Әйбер ала күп кеше —
Олысы һәм кечесе.
Һәммәсе мактап китә,
Апамны хөрмәт итә.

Балалар, Мәрьямнең дә энисе — сатучы. Ул кибеттә аяк киемнәре — итекләр, туфлиләр, ботинкалар сата. Гөлназның да энисе — сатучы. Ул матур күлмәкләр сата. Балалар, сезнең эниләрегез төрле урыннарда эшлиләр. Алар арасында табибәләр, сатучылар, пешекчеләр, укытучылар, тәрбиячеләр бар. Алар үз эшләрен яратып башкаралар. Эниләр эштән арып кайталар, шуңа күрә аларны борчырга ярамый. Аларны һәрвакыт тыңларга, булышырга кирәк. Эниләр — безнең иң кадерле кешеләребез. Әйдәгез, эниләргә багышлап, җыр җырлыйк әле.

Энием, кадерлем,
Шатлан, көл син.
Җыр булсын бүләгем —
Гөлләргә тиң.

Булдырдыгыз, балалар! Мин сезнең өчен бик шат. (Тәрбияче мольбертка кояш рәсеме куя.) Балалар, әйдәгез, кояш нурлары ясыйк әле. Кулларыгызны алга сузыгыз, бер-берегез белән кулга-кул тотынышыгыз. Үзегезне җылы кояш нурлары кебек хис итеп, тыныч кына басып торыгыз. Менә безнең бүлмәбезне нинди зур кояш яктырта. Бүлмәбез тагын да якты, җылы була!

## *Сигезенче бүлек.* ХАЛЫК ИҖАТЫ

### Тема. МАТРЁШКАЛАР

**Бурычлар:**

1) балаларны халык иҗат иткән уенчыклар (матрёшкалар) белән таныштыруны дәвам итү; матрёшканы ачарга һәм дөрес итеп

җыярга өйрәтү, сүз байлыгын киңәйтү һәм активлаштыру, балаларны үзләренә әйтелгән (мөрәҗәгать ителгән) сүзләрне тыңларга күнектерү;

2) игътибарны, хәтерне, сенсор тою сәләтен, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;

3) уенчыкларга сакчыллык, халык иҗатына кызыксыну тәрбияләү.

**Җиһазлар:** «тылсымлы» тартма, матрёшкалар (тәрбиячегә һәм һәр балага җитәрлек санда.)

## Эшчәнлек барышы.

Тәрбияче. Балалар, «тылсымлы» тартма янына килегез әле. Бу нинди тартма икән? Бу — «тылсымлы» тартма, аның эчендә нәрсә бар икән? (Тәрбияче тартманы селкетеп карый.) Тартманың эчендә әйбер бармы?(*Бар*.) Тартма эчендәге әйбернең исемен әйткәч, тартма ачылачак. Мин хәзер аны тасвирлап күрсәтәм, ә сез аның нәрсә икәнен әйтергә тырышыгыз. Ул — уенчык, бик матур, кызыл сарафан кигән, кызыл яулык бәйләгән, аның белән балалар бик яратып уйныйлар. Аның зурысы да, кечкенәсе дә була. Балалар, бу нәрсә? (*Матрёшка*.) Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: «матрёшка». (Тәрбияче тартмадан матрёшканы ала һәм өстәлгә куя.) Карагыз әле, нинди матур уенчык! Аның исеме — матрёшка. Яулыгы, күлмәге бик матур. (Тәрбияче матрёшканы тотып карарга, сыйпарга мөмкинлек бирә.) Балалар, безнең матрёшка җиңелме, әллә авырмы? Әйе, авыр. Аның эчендә берәр әйбер бармы, селкетеп кара әле, Камил. Аның эчендә нәрсәдер шакылдый. Тагын игътибар белән тыңлагыз әле (селкетеп карый). Нәрсә эшли?(*Шакылдый.*) (Активлаштыру.) Әйдәгез, карыйк әле, нәрсә шакылдый икән анда? (Тәрбияче матрёшканы ача.) Матрёшка, матрёшка, ачыл әле син безгә! (Ачу процессы балаларда кызыксыну тудырсын өчен, тәрбияче аны акрынлап ача.) Әйдәгез, бергәләп әйтик: «Матрёшка, матрёшка, ачыл әле син безгә!» (Матрёшканы ачып, аның эченнән икенчесен ала.) Балалар, монда тагын бер матрёшка бар. Әйдәгез, аларны янәшә куйыйк әле. Менә монысы зур, ә монысы кечкенәрәк. (Тәрбияче кечерәк матрёшканы алып, тагын селкетеп карый.) Нәрсәдер шакылдый! Әйдәгез, матрёшкага эндәшик: «Матрёшка, матрёшка, ачыл әле син безгә!» (Аның эченнән матрёшканы ала, янәшә куя, шул рәвешле, соңгы матрёшкага хәтле ачалар һәм зурдан алып кечкенәгә хәтле бер рәткә тезәләр.) Балалар, сокланып карагыз әле матрёшкаларга. Алар да сезгә яратып карап торалар. Матрёшкалар бер-берсенә бик охшаган, игезәкләр шикелле.

Бу — иң зур матрёшка. Ул — әни. Ә монысы кечерәк. Ул — олы кыз. Ә менә бу кыз тагын да кечерәк. Ә менә бу кыз иң кечкенәсе. Ул — бу кызларның сеңлесе. (Балалар бергә матрёшкалар биюен бииләр.)

Без — матрёшкалар, матур курчаклар.
Менә шундый, менә шундый
Чип-чиста куллар.
Без — матрёшкалар, матур курчаклар.
Менә шундый, менә шундый
Кызыл иреннәр.
Без — матрёшкалар, матур курчаклар.
Тып-тып итеп биибез без,
Шат күңеллеләр!

Балалар бармакларын алмаш-тилмәш битләренә, иреннәренә тидерәләр. Кулларын билләренә куеп, аякларын тыпырдаталар.

Тәрбияче. Ә хәзер һәрберегез матрёшка алыгыз. (Тәрбияче матрёшкаларны тикшереп карарга мөмкинлек бирә.) Матрёшканы ачыгыз һәм ябыгыз. Хәзер матрёшкаларны урыннарына (киштәгә) куегыз. Алар сезгә карап торсыннар һәм рәхәтләнеп ял итсеннәр. Матрёшканы ватарга, бәрергә, ташларга ярамый. Аларны сакларга кирәк! Булдырдыгыз! (Балалар кул чабалар.)

## Тема. МАТРЁШКАЛАР

**Бурычлар:**

1) уенчыкның исемен (матрёшка) дөрес әйтергә, төсендә һәм зурлыгында булган аерманы күрә белергә күнектерү; *зур, кечкенә, сарафан, яулык* сүзләре исәбенә сүзлекне активлаштыру;

2) балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;

3) балаларда халык уенчыкларына кызыксыну тәрбияләү.

**Җиһазлар:** төрле зурлыктагы, төрле төстәге киемле ике матрёшка.

### Эшчәнлек барышы.

Тәрбияче. Балалар, карагыз әле, безгә кунаклар — матрёшкалар килгән. Кемнәр килгән? (*Матрёшкалар.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, зурлыклары буенча алар төрле-төрле. (Тәрбияче матрёшкаларга күрсәтә.) Бу матрёшка зурмы, әллә кечкенәме? (*Кечкенә.*) Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: «кечкенә». (Активлаштыру.) Бу матрёшка кечкенәме, әллә зурмы? (*Зур.*) Әйдәгез, бергәләп

кабатлыйк әле: «зур». (Активлаштыру.) Әмир, зур матрёшканы күрсәт әле. Син нинди матрёшканы күрсәттең? (*Зурны.*) (Активлаштыру.) Зилә, кил әле, кечкенә матрёшканы күрсәт. Син нинди матрёшканы күрсәттең? (*Кечкенәне.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балаларга «зур», «кечкенә» төшенчәсен аңлату, ныгыту. Балалар, карагыз әле, матрёшкалар ничек киенгән? Зур матрёшканың яулыгы нинди төстә? (*Кызыл.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, матрёшканың сарафаны нинди төстә? (*Кызыл сарафан.*) (Активлаштыру.) Әйе, балалар, бу — зур матрёшка. Ул кызыл сарафан кигән. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Ул кызыл яулык бәйләгән. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) (Активлаштыру.) Кечкенә матрёшканың яулыгы нинди төстә? (*Сары яулык.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Ә кечкенә матрёшканың сарафаны нинди төстә? (*Сары сарафан.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Дөрес, балалар, бу — кечкенә матрёшка. Ул сары сарафан кигән. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Ул сары яулык бәйләгән. (Активлаштыру.) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Әйе, матрёшкалар төрле-төрле. Аларның зурлыклары төрле. Сарафаннары, яулыклары да төрле төстә. Балалар, әйдәгез, уйнап алыйк әле. Мин бер матрёшканы качырам. Ә сез кайсы матрёшканы качырганны әйтергә тырышыгыз. Кулларыгыз белән күзләрегезне каплагыз. (Зур матрёшканы алып куя.) Күзләрегезне ачыгыз. Кайсы матрёшка качкан? (*Кызыл сарафан кигән зур матрёшка юк.*) (Активлаштыру. Тәрбияче балаларга җавап бирергә ярдәм итә. Аннан соң кечкенә матрёшканы качыра һәм, шул рәвешле, аның турында сорый, балаларга җавап бирергә булыша, җавапларын хуплый, бәяли.) Балалар, әйдәгез, бергәләп матрёшкалар биюен биибез.

Балалар биюне башкаралар.

## *Тугызынчы бүлек.* ЯЗ

### Тема. ЯЗ, ЯЗ КИЛӘ...

**Бурычлар:**

1) балаларга язгы күренешләр (кар эри, тамчы тама, кояш җылыта, сулар җыела) турында башлангыч белемнәр бирү, сүз байлыгын киңәйтү һәм активлаштыру;

2) балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын үстерү;

3) табигатьтәге язгы күренешләр белән кызыксындыру.

**Җиһазлар:** язгы күренешләр сурәтләнгән рәсем, «Язгы тамчы» җырының аудиоязмасы (М. Шәмсетдинова көе, Х. Хәкимуллина сүзләре), Йомшаккай.

**Эшчәнлек барышы.**

Тәрбияче. Балалар, безгә кунакка Йомшаккай килгән. Исәнләшик, балалар. (Исәнләшәләр.) Йомшаккай миңа нидер әйтергә тели. Тыңлап карыйк әле. (Йомшаккайны колагына якын китерә.) Балалар, Йомшаккай шигырь өйрәнгән, шуны сөйләргә тели. Әйдә, Йомшаккай, сөйлә.

Яз килә, яз килә,
Кояш нурларын сибә.

Балалар, Йомшаккай нәрсә турында сөйләде? (*Яз турында.*) Хәзер тышта яз. Язны барлык кешеләр дә көтә. Яз җиткәч, табигатьтә күп кенә үзгәрешләр була. Йомшаккай, яз көне нинди үзгәрешләр була? Әйе, кояш ныграк җылыта. Балалар, кояш нишли? (*Кояш җылыта.*) (Активлаштыру.) Кояш җылыткач, кар эри. Яз көне кар эри. Кар нишли? (*Кар эри.*) (Активлаштыру.) Яз көне тагын нинди үзгәрешләр була? (*Урамнарда сулар җыела.*) Дөрес, яз көне кояш нык җылыта, кар эри һәм сулар җыела. (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар.) Җыелган кар суларын икенче төрле күлдәвекләр диләр. Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: «күлдәвекләр». (*Күлдәвекләр.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Язын тамчылар тып-тып итә. Нәрсәләр тып-тып итә? (*Тамчылар.*) Дөрес, тамчылар тып-тып итә. Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: «тып-тып-тып». (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар.) Тамчылар нишли? (*Тамчылар тама.*) (Активлаштыру.) Балалар, сез бүген матур итеп җавап бирдегез, Йомшаккайга бигрәк тә ошадыгыз. Шуның өчен ул сезгә язгы тамчылар турында җыр тыңлатырга тели. (Тәрбияче аудиоязма куя.)

Тып, тып, тып, ты-пы-тып,
Тып, тып, тып.
Тамчы тама талларга,
Талларымның бөреләре
Куаныша шуңарга, куаныша шуңарга.
Тып, тып, тып, ты-пы-тып,
Тып, тып, тып.
Яз тама тамчы булып.
Кояш нурлары биешә,
Шул тамчыларга куанып,
Шул тамчыларга куанып.

Балалар хәрәкәтләр ясыйлар.

Балалар, яз көне кешеләрнең кәефе күтәрелә. Алар күңелле, шат була. (Активлаштыру.) Сезнең күңелләрдә дә гел шатлык кына булсын!

## Тема. ҖӘНЛЕКЛӘР УРМАНДА ЯШИЛӘР

**Бурычлар:**

1) җәнлекләр турында балаларның белемнәрен киңәйтү һәм ныгыту, җәнлекләрне таный һәм исемнәрен атый белергә өйрәтү;

2) балаларның диалогик сөйләмен активлаштыру, фикерләвен, мөстәкыйльлеген үстерү;

3) җәнлекләр белән кызыксындыру.

**Җиһазлар:** агач макетлары, уенчыклар белән тартма, уенчык йорт, Йомшаккай.

**Эшчәнлек барышы.**

Тәрбияче өстәлендә куян һәм аю уенчыгы салынган тартма.

Тәрбияче. Балалар, бүген безгә Йомшаккай килде. Исәнме, Йомшаккай! Балалар, сез дә Йомшаккай белән исәнләшегез әле. (Балалар исәнләшәләр.) Балалар, Йомшаккай нәрсәдер әйтергә тели. Әйдәгез, аны тыңлап карыйк әле. Балалар, урмандагы җәнлекләр куян белән аюны эзлиләр. Сез аларны күрмәдегезме? (*Юк.*) Балалар, монда бер тартма бар, аның эченә качмадылармы икән, карыйк әле. (Тәрбияче бер баланы тартманы ачарга чакыра. Тәрбияче тартма эченнән куян уенчыгы ала.) Бу нәрсә?(*Куян.*) (Активлаштыру.)

Куркак куян утыра,
Колакларын селкетә
Һәм безгә нидер әйтә.

Балалар, әйдәгез, куяннан кайда яшәгәнен сорыйк әле. Куян, син кайда яшисең? (*Урманда.*) (Активлаштыру.) Балалар, куян соры төстә. Куянның колаклары кыскамы, әллә озынмы?(*Озын.*) (Активлаштыру.) Куянның койрыгы нинди: озынмы, әллә кыскамы?(*Кыска.*) (Активлаштыру.) Куянның койрыгы зурмы, әллә кечкенәме?(*Кечкенә.*) (Активлаштыру. Тәрбияче балаларның җавапларын гомумиләштерә.) Бу — куян. Ул соры төстә. Аның колаклары озын, койрыгы кечкенә һәм кыска. Куян урманда яши. (Тәрбияче яки бер бала куянны «урманга» (агачлар макеты янына) җибәрә.) Куян барабанда уйнарга ярата. Әйдәгез, куянның барабанда уйнаганын күрсәтик әле. (Тәрбияче һәм балалар бергәләп хәрәкәтләр ясыйлар: бармакларны йодрыкка җыялар, имән һәм урта бармакларны өскә каратталар, атсыз һәм чәнти бармаклар баш бармакка кагалар, барабан каккан кебек.)

Тра-та-та,
Тра-та-та,
Куян барабан кага. (Бергәләп кабатлыйлар.)

Булдырдыгыз, балалар! (Балалар кул чабалар.)

Марат, кил әле, тартмада калган уенчыкны ал әле. Ул нәрсә? (*Аю.*) (Активлаштыру.) Аю кечкенәме, зурмы? (*Зур.*) (Активлаштыру.) Аның зурлыгын кулларыгыз белән күрсәтегез әле? (Күрсәтәләр.) Булдырдыгыз! Аюның тәпиләре юанмы? (*Юан.*) Ничек уйлыйсыз, аюның тәпиләре көчлеме? (*Көчле.*) (Активлаштыру.) Аю ничек йөри? (*Алпан-тилпән килеп йөри.*) (Активлаштыру.) Балалар, әйдәгез, аю шикелле алпан-тилпән йөреп күрсәтик әле. (Тәрбияче аю кебек йөреп күрсәтә, балалар тәрбияче артыннан хәрәкәтләрне кабатлыйлар.) Балалар, аю кайда яши? (*Урманда.*) (Активлаштыру. Тәрбияче балаларның җавапларын гомумиләштерә.) Бу — аю. Ул зур. Аның тәпиләре юан һәм көчле. Аю алпан-тилпән килеп йөри. Ул урманда яши. Балалар, аюны да куян янына урманга җибәрегез. (Бер бала аюны агачлар макеты янына куя.) Булдырдыгыз, балалар! (Балалар кул чабалар.) Хәзер аюлар һәм куяннар булып уйнап алыйк.

Аюның өе зур,
(Кулларын өскә күтәрәләр.)
Куянныкы кечкенә.
(Чүгәлиләр.)
Аю йөри алпан-тилпән,
(Алпан-тилпән йөрү хәрәкәтен күрсәтәләр.)
Ә куяннар сикерә.
(Кулларыннан тәпиләр ясап, куян булып сикерәләр.)

Балалар, сез Йомшаккайга урман җәнлекләрен табарга ярдәм иттегез, үзегез дә күп нәрсәләр белдегез. Булдырдыгыз! (Балалар кул чабалар.)

## Тема. СЫЕРЧЫКЛАР, КАРЛЫГАЧЛАР КИЛДЕ (рәсемнәр карау)

**Бурычлар:**

1) балаларны үзләренә таныш кошларны рәсемнән танырга һәм исемнәрен әйтергә өйрәтү; балаларның сүз байлыгын арттыру, сүзлеккә *сыерчык, сыерчык оясы, карлыгач* сүзләрен кертү;

2) игътибарны, күзәтүчәнлекне, тәрбияче белән аралашу, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;

3) кошлар һәм табигать белән кызыксынуларына ирешү, кошларга карата мәрхәмәтлелек, кайгыртучанлык тәрбияләү.

**Җиһазлар:** саескан, чыпчык, күгәрчен, песнәк сурәтләнгән рәсемнәр.

**Эшчәнлек барышы.**

Тәрбияче мольбертка сыерчык рәсемен куя. Балаларга рәсемне карарга мөмкинлек бирә.

Тәрбияче. Балалар, рәсемдә нәрсә күрәсез?(*Кош.*) Бу — сыерчык. Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: «сыерчык». (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, сыерчык яши торган өй сыерчык оясы дип атала. (Тәрбияче сыерчык оясын күрсәтә.) Менә бу — сыерчык оясы. Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: «сыерчык оясы». (Активлаштыру.) Балалар, сезнең сыерчык оясы күргәнегез бармы?(*Бар.*) Әйе, ул безнең мәйданчыкта бар. Гүзәл, кил әле, сыерчыкны күрсәт. Син нәрсә күрсәттең? (*Сыерчык.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Марат сыерчык оясын күрсәт әле. Син нәрсә күрсәттең? (*Сыерчык оясы.*) (Тагын бер-ике баланы чакырып, шуны ук эшләргә куша.) Булдырдыгыз! Хәзер без бармаклардан сыерчык оясы ясап карарбыз. Кул учларын вертикаль рәвештә кара-каршы куябыз. Чәнти бармакларны, «көймә» ясап, берберсенә якын китерәбез. Калган бармаклар башта бөгеләләр, аннан бөкләнәләр. Менә сыерчык оясы барлыкка килде.

Сыерчык оясында
Матур сыерчык яши,
Күңелле җырлар җырлый.

Булдырдыгыз, балалар! (Тәрбияче мольбертка карлыгач төшерелгән рәсем куя. Балаларга рәсемне карарга мөмкинлек бирә.) Бу рәсемдә нәрсә күрәсез? (*Кош.*) Бу кош — карлыгач. Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: «карлыгач». (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Карагыз әле, карлыгач түбә астында оя ясый. Менә карлыгачның оясы. (Тәрбияче карлыгач оясын күрсәтә.) Балалар, түбә астында карлыгач нәрсә ясый? (*Оя.*) (Активлаштыру.) Камил, кил әле, карлыгачны күрсәт. Син нәрсә күрсәттең? (*Карлыгач.*) (Берничә бала шуны ук кабатлыйлар.) Яз килгәч, көннәр җылынгач, сыерчыклар, карлыгачлар җылы яктан очып кайталар. Алар оя ясыйлар. Менә шундый кечкенә кошчыкларын чыгаралар. (Рәсемгә күрсәтә.) Кошлар нәрсә чыгаралар? (*Кошчыклар.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар. Тәрбияче балаларга саескан, чыпчык, күгәрчен, песнәк рәсемнәрен күрсәтә. Балалар аларның исемнәрен атыйлар.) Әйе, балалар, бу кошлар кыш буе безнең янда булдылар. Без аларны көнбагыш, ипи валчыклары, төрле ярмалар белән сыйладык.

Тәрбияче аудиоязма куя. «Кошлар килде» җыры (Ш. Мәҗитов көе, Г. Латыйп сүзләре) яңгырый.

Кояш кыздыра,
Пар күтәрелә,
Күңел шатлана
Язның яменә.
Кошлар да килә
Ерак-еректан,
Яз аларны да
Иртә уяткан.

Сыерчык куна
Оя башына,
Сайрап җибәрә,
Басып каршыга.
— Сагындым,— ди ул,—
Туган илемне,
Канат үстергән
Изге җиремне.

Балалар, кошлар белән күңелле, алар сайрыйлар, очалар, уйныйлар, безгә шатлык китерәләр. Кошларны куркытырга ярамый, аларны сакларга кирәк. Аларга таш белән атарга, таяк белән сугарга да ярамый. Кошлар булмаса, табигать тә матур булмас иде.

## Тема. ПЕСИЛЕ ТАЛ БӨРЕЛӘРЕН КАРАУ

**Бурычлар:**

1) балаларны песиле тал, аның өлешләре (ботаклар, бөреләр) белән таныштыру, табигатьтәге язгы күренешләр турында белемнәр формалаштыруны дәвам итү; сүз байлыгын киңәйтү һәм *песиле тал, ботак, бөре, йомшак, хуш исле* сүзләре исәбенә сүзлекне активлаштыру;

2) балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын, күзәтүчәнлеген, хәтерен, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;

3) табигать белән кызыксыну, табигать матурлыгына соклану хисләре тәрбияләү.

**Җиһазлар:** вазага утыртылган песиле тал ботагы.

### Эшчәнлек барышы.

Тәрбияче. Балалар, карагыз әле, бу нәрсә? (Вазадагы песиле тал ботагына күрсәтә.) Бу — песиле тал. Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: «песиле тал». (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.Тәрбияче песиле тал белән балаларның битеннән сыйпый.) Карагыз әле, менә нинди йомшак, ягымлы песиле тал! Песиле тал нинди? (*Йомшак.*) (Активлаштыру.) Песиле тал йомшак. Балалар, песиле талның нәрсәләре бар? Аның ботаклары бар. Менә ул. Алсу, кил әле, песиле талның ботагын күрсәт әле. Алсу, син нәрсә күрсәттең? Песиле талның ботагы нинди төстә? (*Яшел.*) (Активлаштыру.) Балалар, болар — песиле талның бөреләре. Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: «бөреләр». (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Алмаз, песиле тал бөресен күрсәт әле. Син нәрсә күрсәттең?

(*Бөре.*) (Берничә баланы чакыра, алар да күрсәтәләр.) Балалар, бөреләр зурмы, әллә кечкенәме? (*Кечкенә.*) (Активлаштыру.) Балалар, песиле талны иснәп карагыз әле. Тәмле ис киләме? (Балалар исниләр.) Нинди ис килә? (*Тәмле ис.*) Әйе, тәмле ис килә. Песиле тал хуш исле. Балалар, әйдәгез, тирән сулыш алып, тагын бер кат иснәгез әле. Нинди хуш исле! Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз әле. (Активлаштыру.) Кем «Нинди хуш исле!» дип, матур итеп әйтә, песиле тал шуның битеннән сыйпый. Булдырдың, Гүзәл! Бик матур итеп кабатладың. Шуңа күрә песиле тал синең битеңнән сыйпады. Булдырдың! Балалар, үсемлекләр үссен өчен, аларны карарга, су сибәргә, туфракларын йомшартырга кирәк. Үсемлекләргә шулай ук кояш нурлары кирәк. Әйдәгез, песиле тал белән вазаны тәрәзә төбенә куябыз. Анда песиле талның бөреләре ачылыр. Ул бөреләр йонлач, йомшак песигә охшаган булалар. Шуңа күрә ул песиле тал дип атала.

Әйдәгез, түгәрәккә басыгыз әле, уйнап алабыз. Мин сезгә кояш күрсәтәм, ә сез, кулларыгызны өскә күтәреп, бармакларыгызны менә шулай җәегез. (Күрсәтә.) Кояшта бөреләр уяна, яфраклар, чәчәкләр ачылалар. Кояш йокларга яткач, алар тагын ябылалар. Менә шулай. (Кулларын йодрыклый һәм аска төшерә.) Кояш тагын йокыдан уяна, нурларын сибә. (Уен, шул рәвешле, өч-дүрт тапкыр кабатлана.)

## *Унынчы бүлек.* ҖӘЙ

### Тема. ТУЗГАНАК ЧӘЧӘГЕН КАРАУ

**Бурычлар:**

1) балаларны үсемлекләр белән таныштыруны дәвам итү; тузганак чәчәген күрсәтү, аны танырга, исемен әйтергә, төзелеше (чәчәге, сабагы, яфраклары) буенча аера белергә өйрәтү; сүз байлыгын үстерү; *тузганак, чәчәк, сабак* сүзләрен сөйләмдә активлаштыру;

2) балаларның сенсор тою һәм кабул итү сәләтен, игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерү;

3) табигать белән турыдан-туры аралашудан шатлык хисләре уяту, үсемлекләргә сакчыл караш тәрбияләү.

**Җиһазлар:** эшчәнлек табигатьтә уза.

#### Эшчәнлек барышы.

Т ә р б и я ч е балаларны тузганаклар үскән урынга алып килә.

Т ә р б и я ч е . Балалар, карагыз әле, бу нәрсә? (Үләнгә күрсәтә.) (*Үлән.*) Әйе, бу — үлән. Үлән нинди төстә? (*Яшел үлән.*) (Активлаштыру.) Балалар, әйдәгез, үләнне тотып карыйк

әле. Үлән нинди: йомшакмы? (*Йомшак.*) Үлән нинди: матурмы? (*Матур.*) (Активлаштыру.) Балалар, кулларыгыз белән үләнне яратып сыйпагыз да кулларыгызны иснәп карагыз. Үләннән нинди ис килә? (*Тәмле ис, үлән исе, хуш ис.*) (Активлаштыру.) Игътибар итегез әле: үлән арасында нәрсә күрәсез? (Тәрбияче сары тузганакларны күрсәтә.) (*Чәчәкләр.*) (Активлаштыру.) Үлән арасында чәчәкләр күпме? (*Күп.*) (Активлаштыру.) Чәчәкләр нинди төстә? (*Сары.*) (Активлаштыру.) Бу чәчәкләрнең исеме — тузганак. Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: «тузганак». (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, чәчәкләрне өзмәгез. Хәзер һәрберегез, берәр чәчәк табып, аның янына басыгыз. Балалар, тузганак чәчәкләрен сак кына тотып карагыз әле. Алар нинди? (*Йомшак.*) Әйе, балалар, йомшак, бик йомшак. Әйдәгез, «бик йомшак» дип кабатлагыз. Балалар, чәчәкләрне кулларыгыз белән сак кына сыйпагыз әле. Тәмле ис киләме, кулларыгызны иснәп карагыз. Нинди ис килә? (*Тәмле ис, хуш ис.*) (Активлаштыру.) Балалар, үлән яшел төстә. Ә тузганаклар нинди төстә? (*Сары, сап-сары.*) (Активлаштыру.) Балалар, игътибар итегез әле: яшел үлән арасында сары тузганак чәчәкләре бигрәк матур күренәләр. (Тәрбияче, чүгәләп яки үлән өстенә утырып, үлән арасыннан тузганакны аерып күрсәтә.) Балалар, бу — тузганакның сабагы. Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: «тузганакның сабагы». (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Тузганакның сабагы кыскамы, әллә озынмы? (*Озын.*) Тузганак — искиткеч матур чәчәк! Аның сабагы озын һәм шома. Ә чәчәге сап-сары, йомшак түбәтәйне хәтерләтә. (Балалар тасвирлауны кабатлыйлар.) Тузганак өлгергәч, аның түбәтәе ак шарга әйләнә. Балалар, тузганаклар үссен өчен нәрсә кирәк? (*Яңгыр.*) (Активлаштыру.) Әйе, ә тагын нәрсә кирәк? (*Кояш.*) (Активлаштыру.) Балалар, тузганаклар нәрсәгә охшаган? (*Кояшка.*) Бик дөрес, тузганаклар кояшка охшаганнар.

Балалар, ә хәзер уен уйнап алыйк. Сез тузганак чәчәкләре булырсыз. Яшел үлән өстенә җайлап утырыгыз. Сезгә күктә кояш елмая. Ә сез басыгыз һәм, бармакларыгызны җәеп, кулларыгызны өскә — кояшка күтәрегез. (Күрсәтә.) Кояш чыкты, тузганаклар кояшка карыйлар, аның җылысын тоялар. (Балалар кояшка таба үреләләр.) Кояш йоклый, чәчәкләр дә йоклый. (Чүгәлиләр, кулларны аска төшерәләр. Уен икеөч тапкыр кабатлана.)

Балалар, сез бүген бик матур итеп җавап бирдегез, күңелле уен уйнадыгыз. Мин сезгә кояшлы көннәр генә телим.

## Тема. ЙОРТ ХАЙВАННАРЫ

**Бурычлар:**

1) балаларның йорт хайваннары (сыер, ат, песи, эт) турындагы белемнәрен (кайда яшиләр, нәрсә ашыйлар) киңәйтү, хайваннарның исемнәрен, хәрәкәтләрен әйтергә күнектерү;

2) сүзлекне баету, тәрбиячегенең сорауларына җавап бирү, мөстәкыйльлек һәм активлык күрсәтү теләгән үстерү;

3) йорт хайваннарына карата кызыксыну тәрбияләү.

**Җиһазлар:** йорт хайваннары (сыер, ат, песи, эт) уенчыклары (алар тартмага яшерелгән), коймалар белән әйләндерелеп алынган уенчык йорт.

### Эшчәнлек барышы.

Т ә р б и я ч е балаларны уенчык йорт янына алып килә.

Т ә р б и я ч е. Балалар, бу нинди йорт, анда кемнәр яши икән? Балалар, бу тартмада нәрсә бар? (Тартмадан «без, без» дигән тавышлар ишетелә.) Балалар, нинди тавыш бу? Нәрсәләр бар икән тартмада, карыйк әле. (Тәрбияче сыер уенчыгы ала.) Балалар, бу — сыер. Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: «сыер». (Активлаштыру.) Балалар, сыер ничек мөгри (кычкыра)? (*«Му-му»*.) (Кабатлыйлар.) Сыер нәрсә ашый? (*Үлән.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Дөрес, балалар, сыер үлән ашый һәм «му-му» дип мөгри. (Балалар кабатлыйлар.) Балалар, сыер безгә сөт бирә. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Сыер абзарда яши. Айрат, кил, сыерны абзарга керт әле. (Тәрбияче бер баланы чакыра һәм сыерны «абзар»га кертергә куша.) Балалар, Айрат нәрсә эшли? (*Сыерны абзарга кертә.*) (Активлаштыру.)

Тартмадан тагын тавыш килә. Балалар, нәрсә кычкыра? (Тартмадан ат кешнәгән тавыш килә.) Бу нәрсә? (*Ат.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Ат кечкенәме, зурмы? (*Зур.*) (Активлаштыру.) Балалар, ат кайда яши? (*Абзарда.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, ат та ишегалдындагы абзарда яши. (Активлаштыру.) Балалар, ат ничек кешни (кычкыра)? (*«Миһаһай»*.) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, ат йөк ташый. Әмир, бар, атны абзарга керт әле! Балалар, Әмир нәрсә эшли? (*Атны абзарга кертә.*) (Активлаштыру.) Балалар, әйдәгез, бармаклардан ат ясап карыйк әле. (Уң кул кабыргасына куела, баш бармак өскә караган. Уң кулны сул кулның учы белән тотабыз, ике баш бармак янәшә тора: атның колаклары була.) Менә нинди ат килеп чыкты, булдырдыгыз!

Тәрбияче тартманы күтәрә һәм гаҗәпләнеп әйтә: «Тартманы нәрсәдер тырный, нәрсә икән ул?» (*Песи.*) (Активлаштыру.) Әйе, балалар, бу — песи. (Песине тартмадан ала.) Ул нәрсә дип кычкыра? (*«Мияу-мияу».*) (Кабатлыйлар.) Балалар, песи нәрсә ярата? (*Сөт. Ит. Балык.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, ә песи кайда яши? (*Өйдә.*) Әйе, песи өйдә яши. Балалар, димәк, песинең урыны кайда: ишегалдындамы, әллә өйдәме? (*Өйдә.*) Әйе, балалар, песине өйгә кертергә кирәк. Балалар, әйдәгез, песигә әйтик: «Бар, песи, өйгә кер». (Балалар песине өйгә кертәләр.) Әйдәгез, балалар, бармаклардан песи ясыйк әле. (Урта һәм атсыз бармаклар баш бармак белән тоташа, имән бармак һәм чәнти бармак өскә карап тора.) Менә нинди матур песи килеп чыкты!

Балалар, тартмада тагын нәрсәдер бар: «һау-һау» дип өрә. Ул нәрсә? (*Эт.*) Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: «эт». (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, эт сөяк ярата. Бергәләп кабатлыйк әле: «сөяк». (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Әйе, этне сөяк белән сыйлыйлар. Балалар, эт өйне саклый. Эт кайда яши? (*Ишегалдындагы оясында яши.*) (Балалар этне оясына урнаштыралар.) Тәрбияче гомумиләштерә: «Ат һәм сыер абзарда, песи өйдә яши, ә эт ишегалдындагы оясында яши. Ат, песи, сыер, эт — йорт хайваннары». (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.)

Эшчәнлек ахырында балалар «Маэмаем» җырын
(Г. Гәрәева көе һәм сүзләре) тыңлыйлар.

Койрыгын болгый ул,
Тәпиен ялый ул.
— Һау-һау-һау, — дип өрә,
Уйнап һич туймый ул.

## Тема. БАЛАЛАР ТАВЫК ҺӘМ ЧЕБИЛӘР АШАТА (рәсем буенча)

**Бурычлар:**

1) балаларны рәсемне карарга, эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә, тәрбияче һәм иптәшләренең сөйләгәннәрен тыңларга өйрәтүне дәвам итү;

2) сөйләмне *томшык, тавык, чебиләр, табак* кебек сүзләр хисабына баету, игътибарны, хәтерне, образлы фикерләүне үстерү;

3) йорт кошларына карата мәрхәмәтлелек тәрбияләү.

**Җиһазлар:** «Балалар тавык һәм чебиләр ашата» рәсеме (авторлары: В.Езикеева, Е. Радина).

**Эшчәнлек барышы.**

Тәрбияче балаларның игътибарын рәсемгә юнәлтә. Рәсемне игътибар белән карарга мөмкинлек бирә.

Тәрбияче. Балалар, рәсемдә кемнәрне күрәсез? Бу кем? (Кызга күрсәтә.) (*Кыз.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Ә бу кем? (*Малай.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Дөрес, балалар, болар — кыз һәм малай. Рәсемдә сез тагын нәрсәләр күрәсез? Бу нәрсә? (*Тавык.*) (Активлаштыру.) Ә бу нәрсәләр? (*Чебиләр.*) Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: «чебиләр». (Активлаштыру.) Малай белән кыз нәрсә эшлиләр? (*Тавыкны һәм аның чебиләрен ашаталар.*) Алар тавыкка һәм чебиләргә нәрсә бирәләр? (*Ярма.*) (Активлаштыру.) Балалар, малай белән кыз тавыкка һәм чебиләргә ярма бирәләр. (Ярманы, тәлинкәгә салып, балаларга күрсәтә.) Ярманы нәрсәгә салганнар? (*Тәлинкәгә, табакка.*) (Активлаштыру.) Балалар, кызның табактан ничек итеп ярма алуын, тавыкка һәм чебиләргә ничек итеп сибүен күрсәтегез әле. (Тәрбияче күрсәтә, балалар кабатлыйлар.) Чебиләр нишлиләр? (*Ярма бөртекләрен чүплиләр.*) (Активлаштыру.) Балалар, барлык чебиләр дә бөртек чүплиләрме? (*Юк.*) Әйе, дөрес, менә бу ике чеби генә ярма чүпли. (Чебиләрне күрсәтә.) Гүзәл, кил әле, ярма чүпләп торган чебиләрне күрсәт әле. (Күрсәтә.) Алар нишлиләр? (*Ярма чүплиләр.*) (Активлаштыру.) Калган чебиләр нәрсә эшлиләр? (*Карап торалар.*) Ярманы тагын нәрсә чүпли? (*Тавык.*) (Активлаштыру.) Балалар, карагыз әле, тавыкның томшыгы кечкенәме, зурмы? (*Зур.*) (Активлаштыру.) Ә чебиләрнең томшыгы зурмы, кечкенәме? (*Кечкенә.*) (Активлаштыру. Тәрбияче рәсемнән тавыкның һәм чебинең томшыкларын күрсәтә.) Ә менә бу сары чебиләр кемгә карап торалар? (*Малайга.*) Бу малайның исеме — Булат. Малайның исеме ничек? (*Булат.*) Булат чебиләргә: «Ярма чүпләгез, ярма бик тәмле», — дип әйтә. Малай чебиләргә нәрсә ди? (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, чебиләр нинди? (*Кечкенә. Сары. Йомшак. Нәни.*) (Активлаштыру.) Алсу, табак белән ярма алып, ишегалдына чыкты һәм, «чеп-чеп-чеп» дип, чебиләрне чакыра башлады. Аның янына, үзенең чебиләрен ияртеп, тавык килеп җитте. Тавыкка бирә торган ярманы Алсу зур табакка салды, ә чебиләргә дигәнне җиргә сипте. Чебиләргә җим чүпләргә шулай уңайлы. Тавык һәм ике чеби ярма чүплиләр. Башка чебиләр җим чүпләмиләр, алар карап торалар. Бәлки, алар җим чүпләргә өйрәнмәгәннәрдер? Булат чебиләргә: «Чүпләгез, чүпләгез!

Ярма бөртекләре би-и-к... тәмле!» — ди. (Тәрбияче тагын бер тапкыр рәсемнең эчтәлеген сөйли. Балалар, аңа ияреп, кайбер сүзләрне әйтеп җибәрәләр: *тавык чебиләре белән, табак, уңайлы, карап торалар, өйрәнмәгәндер, тәмле.*)

Балалар, Алсу белән Булат бик тырышлар. Алар тавыкны да, чебиләрне дә яраталар. Алсу белән Булат көн саен кош-кортларны, тавыкларны һәм чебиләрне ярма белән сыйлыйлар. Әйдәгез, чебиләр турында җыр тыңлыйбыз. (М. Фәйзуллина сүзләре, Л. Хәйретдинова көенә язылган «Чебиләр зарядкасы» җыры яңгырый. Балалар, җырга кушылып, хәрәкәтләр ясыйлар.) Булдырдыгыз, балалар!

## Тема. КОМ ҺӘМ АНЫҢ ҮЗЛЕКЛӘРЕ

**Бурычлар:**

1) балаларны комны тикшерергә (комны учка алырга, йомарларга һәм сибәргә), төсе буенча аның дымлылыгын билгеләргә өйрәтү;

2) *коры, дымлы, юеш, сибелүчән, сибелә, әвәләү* сүзләре хисабына балаларның сүз байлыгын киңәйтү, игътибарны, сенсор тою сәләтен үстерү;

3) ком белән уйнарга кызыксындыру.

**Җиһазлар:** ком белән уйнар өчен формалар; ком, су салынган кувшиннар; Алсу исемле курчак.

### Эшчәнлек барышы.

Тәрбияче комда уйнар өчен кирәк булган предметларны балаларга күрсәтә, бергәләп бу предметларның исемен атап чыгалар: чиләк, уенчык көрәк (соскы), тәлинкә, формалар һ.б.

Тәрбияче. Балалар бу уенчыклар белән комда уйныйлар. Балалар, бу уенчыклар нәрсә өчен кирәк? (*Комда уйнар өчен.*) (Активлаштыру.) Бу уенчыкларны Алсу исемле курчак алып килгән. Аның бүген туган көне. Алсу туган көненә калачлар пешерергә тели. Балалар, Алсуга булышасызмы? (Балаларның җаваплары тыңлана.) Бүген Алсуның туган көнендә без сезнең белән бергәләп уйнарбыз, калачлар пешерербез. Алсу эскәмиядә утырып торсын. (Тәрбияче балаларны комлыкка алып килә.) Бу нәрсә? (Комга күрсәтә.) (*Ком.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар. Тәрбияче балаларга формалар тарата.) Балалар, формаларга ком тутырып, калачлар пешерик әле. Кемнең калачы пеште? Балалар, калач ни өчен пешмәде? (Тәрбияче балаларның игътибарын комның таралуына юнәлтә.) Балалар, ни өчен ком тара-

лып тора? (Балалар әйтә алмаса, тәрбияче әйтә.) (*Чөнки ком коры.*) (Активлаштыру.) Балалар, комны кулыгызга алып карагыз әле. (Балалар комны учларына алалар, җиргә сибеп карыйлар.) Дөрес, балалар, коры комнан калач пешереп булмый. Калач ясау өчен нинди ком кирәк: корымы, юешме? (Активлаштыру.) Әйе, калач ясау өчен, юеш ком кирәк. Балалар, юеш комны каян алырга була? (Балалар әйтә алмаса, тәрбияче әйтә.) (*Комны су белән юешләтергә кирәк.*) (Тәрбияче комга кувшиннан су агыза һәм балаларга юеш комны учларына алырга куша.) Балалар, ком нинди? (*Юеш.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Ком юеш, шуңа күрә ул кулга ябышып тора. (Тәрбияче бер кулына коры ком, икенчесенә юеш ком ала.) Балалар, бу кулымда нинди ком? (*Коры.*) Ә монысында нинди? (*Юеш.*) Балалар, коры комның төсе нинди? Ул ачык төстә. (Активлаштыру.) Ә юеш комның төсе нинди? Ул караңгы төстә. (Активлаштыру.) Балалар, бер кулыгызга коры ком, икенчесенә юеш ком алыгыз. Ә хәзер учларыгызны кысыгыз да чагыштырып карагыз. Кайсы ком җиңелрәк: юешме, әллә корымы? (*Коры.*) Әйе, коры ком җиңелрәк. Хәзер кулларыгыздагы комны җиргә сибеп карагыз әле. Нинди ком коела: юеш коммы, әллә коры коммы? (*Коры ком.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Дөрес, коры ком тиз коела, ә юеш ком кулга ябышып кала. Балалар, юеш комны формаларыгызга салыгыз һәм тәмле калачлар ясагыз. Балалар, күрдегезме, юеш комнан калач ясап була. Сез калачларны нинди комнан ясадыгыз? Дөрес, юеш комнан. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Менә нинди матур калачлар килеп чыкты.

Балалар, сез бик тырышлар. Алсу да шатлана, сезгә рәхмәт әйтә. Сез бик уңганнар. Шуңа күрә сезнең өчен кояш та сөенә. (Кояш рәсеме күрсәтә.) Әйдәгез, Алсу белән бергәләп «Ак калач» уенын уйнап алыйк. (Уен ике-өч тапкыр кабатлана.)

# СӨЙЛӘМ ҮСТЕРҮ

## *Беренче бүлек.* БЕЗНЕҢ БАЛАЛАР БАКЧАСЫ

### Тема. КЕМ НӘРСӘ ЭШЛИ?

**Бурычлар:**

1) балаларның сөйләмен үстерергә ярдәм итү, рәсемнәр карарга, анда сурәтләнгән предметларны һәм аларның сыйфатларын атарга, рәсемдә сурәтләнгән уенчыкны, предметны өстәлдә табып, исемен, гамәлен атый белергә өйрәтү;

2) игътибарны, кабул итү сәләтен үстерү;

3) уенчыкларга карата сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү.

**Җиһазлар:** Алсу-курчак, тартма, бер эш гамәле сурәтләнгән сюжетлы рәсемнәр (мәсәлән: кыз курчак белән уйный, малай машина йөртә һ.б.). Тәрбияче өстәленә рәсемдә сурәтләнгән кебек үк уенчыклар куела.

**Эшчәнлек барышы.**

Тәрбияче. Балалар, бүген безгә Алсу-курчак килгән. Исәнләшик курчак белән. (*Исәнме, Алсу-курчак!*)

Алсу-курчак. Исәнмесез, балалар!

Тәрбияче. Балалар, карагыз әле, Алсуның «тылсымлы» тартмасы бар. Нәрсә бар икән ул тартмада? Идрис, кил әле, ач әле тартманы. Менә булдырдың! Тартмада нәрсәләр бар? (*Рәсемнәр.*) Идрис, бу рәсемнәрне балаларга тарат әле. Айратка да бирик бер рәсем, Азалиягә дә бирик бер рәсем, башкаларга да бирик. Булдырдың, Идрис! Барыбызда да рәсемнәр бар. Әдилә, синең рәсемдә кем ясалган? (*Кыз.*) Әйе, дөрес, кыз. Кыз нишли? (*Уйный.*) Әйе, кыз курчак белән уйный. Әдилә, өстәл янына кил әле. Курчакны ал. Курчагыңны балаларга күрсәт әле. Булдырдың! (Әдилә, курчакны алып, үз урынына утыра.) Камил, синең рәсемдә нәрсә ясалган? (*Туп.*) Кем туп белән уйный? (*Малай.*) Әйе, малай туп белән уйный. Камил, өстәл янына кил әле. Тупны тап. Туп белән уйнап күрсәт әле. Булдырдың, Камил. Балалар, Камил нишли? (*Уйный.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Камил туп белән уйный. (Индивидуаль кабатлаулар.) Рамилә, синең рәсемеңдә нәрсә ясалган? (*Сусипкеч.*) Дөрес, кыз сусипкечтән

су сибә. Рамилә, өстәл янына кил әле. Сусипкечне тап. Сусипкечтән ничек су сипкәнне күрсәт әле. Булдырдың, Рамилә! Балалар, Рамилә нишли? (*Су сибә.*) (Индивидуаль кабатлаулар. Рәсемнәр белән эшләү шул рәвешле дәвам итә.) Балалар, безнең уенчыкларыбыз бик күп: курчаклар, туплар, машиналар, бөтергечләр. Аларның сезнең белән уйныйсылары килә. Әйдәгез, шушы уенчыклар белән уйнап алыйк. Алсу-курчак та сезнең белән уйнар.

Балалар уенчыклар белән уйныйлар.

## Тема. ПРЕДМЕТЛАРНЫҢ ТӨСЛӘРЕН ТАНУҺӘМ АТАУ. «ПАРОВОЗ» ДИДАКТИК КҮНЕГҮЕ

**Бурычлар:**

1) төсләрне белдерә торган сыйфатлар хисабына балаларның сөйләмен баету (кызыл, яшел, сары), [ү] авазының дөрес әйтелешенә ирешү;

2) балаларның игътибарын, кабул итү сәләтен, төсләрне тану һәм атау осталыгын үстерү;

3) эшчәнлеккә карата кызыксыну, күмәк эшчәнлек белән шөгыльләнү теләге тәрбияләү.

**Җиһазлар:** йомшак уенчык; һәр балага кызыл, сары, яшел төстәге карандашлар салынган тартма; вагоннары яшел, кызыл, сары төстә булган паровоз.

### Эшчәнлек барышы.

Тәрбияче. Балалар, матур итеп утырыгыз әле. Менә минем кебек. Булдырдыгыз! Ишетәсезме? Ниндидер тавыш бар бит. Барып карыйм әле. (Тәрбияче Йомшаккайны алып керә.)

Йомшаккай. Исәнмесез, балалар! (*Исәнмесез!*)

Тәрбияче. Балалар, Йомшаккай, балалар бакчасында сезгә күңелле булсын дип, карандашлар алып килгән. Карагыз әле. (Карандашлар тартмасын күрсәтә.) Бу нәрсәләр? (*Карандашлар.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Карандашлар күп, алар төрле-төрле төстә. (Тәрбияче карандашлар тартмасын балаларга тарата.) Балалар, Йомшаккайга кызыл карандашны алып күрсәтегез әле. Балалар, Йомшаккай сезнең биремне ничек үтәгәнегезне тикшерә. Әгәр дә дөрес эшләсәгез, ул сезнең аркагыздан сыпыра, дөрес эшләмәсәгез, канәгатьсезлек күрсәтә. Әдилә кызыл карандашны дөрес тапкан. Йомшаккай сиңа: «Булдырдың, Әдилә!» — ди. (Шул рәвешле, тәрбияче балаларның биремне ничек башкаруларын

Йомшаккай белән бергә карап чыга.) Булдырдыгыз, балалар! Кызыл карандашны дөрес таптыгыз. Хәзер яшел карандашны Йомшаккайга күрсәтик әле. Камил дә яшел карандашны күрсәтә, Әдилә дә яшел карандашны күрсәтә. Айрат, синең карандашың нинди төстә? (*Яшел.*) Балалар, Айратның карандашы нинди төстә? (*Яшел.*) (Индивидуаль кабатлаулар.) Йомшаккай сезгә карап сөенә: «Айрат, Камил, Әдилә һ.б. яшел төстәге карандашларны дөрес күрсәттеләр»,— ди. Булдырдыгыз, балалар! Хәзер Йомшаккайга сары карандашларны күрсәтик әле. Рамил дә сары карандашны күрсәтә, Айсылу да сары карандашны күрсәтә. Булат, синең карандашың нинди төстә? (*Сары.*) Балалар, Булатның карандашы нинди төстә? (*Сары.*) (Индивидуаль кабатлаулар.) Балалар, тыңлагыз әле, Йомшаккай миңа әйтә: «Булат та, Айрат та, Әдилә дә һ.б. да карандашның төсләрен дөрес күрсәттеләр, дөрес җавап бирделәр»,— ди. Ул сезгә карап сөенә. Без дә аңа карап елмайыйк әле. Менә шулай. Булдырдыгыз! Балалар, Йомшаккай сезгә уенчык паровоз алып килгән. Карагыз әле. (Күрсәтә.) Тыңлагыз әле, паровоз ничек итеп гүли: «ү-ү-ү!» (Кычкырып һәм сузып әйтә.) Балалар, паровоз ничек итеп гүли, әйтеп күрсәтегез әле. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, паровозның вагоннары бар. Алар төрле төстә. Азат, кил әле монда, паровозга сары вагонны так әле. Булдырдың, Азат! Паровозның вагоны нинди төстә? (*Сары.*) (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) Камилә, паровозга кызыл вагонны так әле. Булдырдың, Камилә. Бу вагон нинди төстә? (*Кызыл.*) (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) Айдар, син паровозга яшел вагонны так әле. Булдырдың, Айдар. Вагон нинди төстә? (*Яшел.*) (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) Балалар, әйдәгез, сез дә, берегез артына икенчегез басып, паровоз ясагыз әле. Менә шулай. Нинди зур паровоз! Хәзер бүлмә буенча барабыз һәм паровозның ничек итеп гүләгәнен күрсәтәбез: «ү-ү-ү-ү!» Булдырдыгыз, балалар! Йомшаккай сезгә рәхмәт әйтә һәм саубуллаша.

## Тема. УЕНЧЫКЛАР БЕЗДӘ КУНАКТА

**Бурычлар:**

1) төсне, зурлыкны, эш-гамәлне белдерә торган сүзләр (*зур, кечкенә, яшел, кызыл, утырт, эчерт, керт*) хисабына балаларның сүз байлыгын арттыру, аралашу осталыгы формалаштыру;

2) балаларның предметны исеме, төсе, зурлыгы буенча табу осталыгын, сенсор тою сәләтен, игътибарын, хәтерен үстерү;

3) уенчыкларга карата сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү.

**Җиһазлар:** кечкенә һәм зур аюлар, кечкенә һәм зур машина, төзү материалыннан ясалган кечкенә һәм зур гараж, яшел һәм кызыл чынаяклар, кечкенә һәм зур шакмаклар.

### Эшчәнлек барышы.

Т ә р б и я ч е балаларны уенчыклар почмагына алып бара.

Т ә р б и я ч е. Балалар, карагыз әле, безнең никадәр уенчыкларыбыз бар! Нәрсә генә юк монда: курчаклар, аюлар, матрёшкалар, шакмаклар, машиналар, казлар, туплар, аюлар. (Күрсәтә.) Алар сезнең килгәнне көтеп алалар, сезне бик яраталар, аларның сезнең белән уйныйсылары килә. Әйдәгез, уенчыклар белән уйнап алабыз. (Тәрбияче өстәлгә зур һәм кечкенә аюлар, машиналар, кызыл һәм яшел чынаяклар куя.) Балалар, әйдәгез, аюларга чәй эчерик. Алсу, зур аюны миңа бир әле. Алсу, бу нәрсә? (*Аю.*) Аю кечкенәме, зурмы? (*Зур.*) (Активлаштыру.) Айдар, зур аюны зур шакмакка утырт әле. Булдырдың! Балалар, Айдар нәрсә эшләде? Дөрес, ул зур аюны зур шакмакка утыртты. Азалия, зур аюны кызыл чынаяклы чәй белән сыйла әле. Син аюны нинди чынаяклы чәй белән сыйладың? (*Кызыл.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Зур аю сиңа рәхмәт әйтә. (Шул рәвешле, кечкенә аюны, кечкенә шакмакка утыртып, яшел чынаяклы чәй белән сыйлыйлар.) Азат, зур машинаны зур гаражга кертеп куй әле. Азат, син зурлыгы буенча нинди машинаны алдың: кечкенәме, әллә зурмы? (*Зур.*) (Активлаштыру.) Зур машинаны нинди гаражга керттең? (*Зур.*) (Активлаштыру. Шул рәвешле, кечкенә машинаны кечкенә гаражга куялар.) Балалар, зур аюны күрсәтегез әле. Ул нинди? (*Зур.*) (Балалар кулларын өскә күтәрәләр.) Әйе, менә нинди зур аю! Ә хәзер кечкенә аюны күрсәтегез. Ул зурлыгы буенча нинди? (*Кечкенә.*) (Балалар чүгәлиләр.) Әйе, менә нинди кечкенә генә аю! Булдырдыгыз! Хәзер уенчыкларны үз урыннарына куегыз. Карагыз әле, уенчыклар сезгә нинди рәхмәтле. Аларга сезнең белән уйнау бик ошады!

## Тема. ПИРАМИДАЛАР

**Бурычлар:**

1) балаларны предметларның зурлыгын, төсен билгеләргә өйрәтү; төсне (*кызыл, яшел, сары, зәңгәр*), зурлыкны (*зур, кечкенә, зуррак, кечкенәрәк, иң зурысы, иң кечкенәсе*) белдерә торган сүзләр ярдәмендә сүз байлыгын арттыру; аваз иртемнәрен ачык әйтүдә күнектерү;

2) игътибарны, кабул итүне, сенсор тою сәләтен үстерү;

3) түземлелек, дидактик уеннар белән кызыксыну тәрбияләү.

**Җиһазлар:** һәр балага җитәрлек санда кызыл, сары, яшел, зәңгәр пирамидалар, кыршаулар, песи баласы битлекләре.

## Эшчәнлек барышы.

Тәрбияче. Балалар, Йомшаккай безгә кунакка килгән. Әйдәгез, Йомшаккай белән исәнләшик әле. (Активлаштыру.) Балалар, Йомшаккай безгә бүләкләр алып килгән. (Тәрбияче пирамидалар күрсәтә.) Бу нәрсәләр? (*Пирамидалар.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Әйе, Йомшаккай безгә пирамидалар алып килгән. (Тәрбияче һәр балага пирамидалар таратып чыга.) Балалар, карагыз әле, нинди матур пирамидалар! Бу нинди төс? (*Кызыл.*) (Активлаштыру.) Әмир, бу нинди төс? (*Яшел.*) (Активлаштыру.) Монысы нинди төс? (*Сары.*) (Активлаштыру.) Ә монысы нинди төс? (*Зәңгәр.*) (Активлаштыру.) Дөрес, бу — кызыл, яшел, сары, зәңгәр боҗралардан ясалган пирамида. (Активлаштыру.) Айгөл, кил әле, бу кызыл боҗра кечкенәме, әллә зурмы? (*Зур.*) (Активлаштыру.) Әминә, ә бу зәңгәр боҗра зурмы, әллә кечкенәме? (*Кечкенә.*) (Активлаштыру.) Дөрес, булдырдыгыз! Монда зур һәм кечкенә боҗралар бар. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, кызыл боҗра — иң зурысы. (Активлаштыру.) Ә зәңгәр боҗра — иң кечкенәсе. (Активлаштыру.) Балалар, бу пирамиданы сүтеп була. Ләкин аның боҗраларын ыргытырга ярамый. Сүткәндә, аларны менә шулай тезеп куярга кирәк. (Тәрбияче пирамиданың боҗраларын эзлекле рәвештә, берсе артыннан икенчесен алып, өстәлгә куя.) Балалар, әйдәгез әле, сез дә шулай тәртип белән генә сүтегез. Башта иң кечкенә зәңгәр боҗраны алып куябыз. (Активлаштыру.) Аннан соң зуррак сары боҗраны алып куябыз. (Активлаштыру.) Ә хәзер зуррак яшел боҗраны алабыз. (Активлаштыру.) Инде иң зур кызыл боҗраны алыгыз. (Активлаштыру.) Менә, балалар, пирамида сүтелде. Хәзер пирамиданы яңадан җыеп куйыйк. Алсу, кил әле монда, иң зур кызыл боҗраны тап әле. (Активлаштыру.) Балалар, сез дә иң зур кызыл боҗраны табыгыз. Ә хәзер аны урынына кертеп куй. (Активлаштыру.) Әмир, ә син иң зур яшел боҗраны тап. (Активлаштыру.) Урынына кертеп куй. (Активлаштыру.) Әминә, кил әле, иң зур сары боҗраны табып, урынына куй. (Активлаштыру.) Камил, иң кечкенә зәңгәр боҗраны табып, урынына куй әле. (Активлаштыру.) Булдырдыгыз, балалар! Пирамиданы

дөрес җыйдыгыз! Ә хәзер, әйдәгез, үзегез сүтеп, җыеп карагыз әле. (Активлаштыру. Тәрбияче балаларның эшен карый һәм ярдәм итә.) Булдырдыгыз, балалар, пирамидаларны бик матур итеп җыйдыгыз. Балалар, карагыз әле, Йомшаккай безгә зур бөҗралар да алып килгән. Без хәзер бер уен уйныйбыз. (Тәрбияче идәнгә бөҗраларны куя.) Бу бөҗралар сезнең өегез була. Ә сез — песи балалары. (Тәрбияче балаларга песи баласы битлекләре тарата.) Мин, сезнең янга килеп: «Әни песи балаларын эзли, мияу!» — дигәч, сез дә, «мияу-мияу» дип, минем янга килегез. (Тәрбияче уенның эчтәлеген уен барышында аңлата. Балалар, шул рәвешле, аваз иялтемнәре күнегүләре башкаралар.)

## Икенче бүлек. КӨЗ

### Тема. ЯШЕЛЧӘЛӘР

**Бурычлар:**

1) яшелчәләрне белдерә торган исемнәр (*бәрәңге, помидор, суган, кишер*) һәм аларның үзлекләрен белдерә торган сүзләр хисабына балаларның сүзлеген баету, яшелчәләрне танырга өйрәтү, сөйләмнең грамматик төзелешен камилләштерү;

2) балаларның сенсор тою сәләтен үстерү;

3) яшелчәләр, аларның файдасы турында мәгълүмат бирү.

**Җиһазлар:** Көз кызы, яшелчәләр: бәрәңге, суган, кишер, помидор; кәстрүл, кәрзин, уенчык газ плитәсе.

### Эшчәнлек барышы.

Көз кызы керә. Балалар белән исәнләшә. Кәрзингә күрсәтә.

Тәрбияче. Балалар, минем кәрзиндә яшелчәләр бар. (Кәрзинне балаларга күрсәтә.) Кәрзиндә нәрсәләр бар? (*Яшелчәләр.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, карагыз әле, кәрзиннән яшелчәләрне мин берәмләп алам. Сез аларны беләсезме? (Көз кызы кәрзиннән кишер ала.) Бу нәрсә? (*Кишер.*) (Активлаштыру.) Кишер кыскамы, озынмы? (*Озын.*) (Активлаштыру.) Кишер нинди төстә? (*Кызыл.*) (Активлаштыру.) Алсу, кил әле, кишерне тотып кара. Кишер йомшакмы, катымы? (*Каты.*) Кишер кытыршымы, әллә шомамы? (*Шома.*) (Активлаштыру.) Балалар, Көз кызы сезгә кишер кисәкләре өләшеп чыгар, ашап карагыз әле. Тәме бу-

енча кишер нинди? (*Баллы.*) (Активлаштыру.) Булдырдыгыз! Айгөл, кил әле, кәрзиннән тагын бер яшелчәне ал. Айгөл нәрсә алды? (*Бәрәңге.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Бәрәңге кечкенәме, зурмы? (*Зур.*) (Активлаштыру.) Бәрәңге нинди төстә? (*Сары.*) Аның кабыгы сары, ә эче нинди була? (*Ак.*) (Активлаштыру.) Рамил, кил әле, бәрәңгене тотып кара. Бәрәңге йомшакмы, катымы? (*Каты.*) (Активлаштыру.) Бәрәңге кытыршымы, шомамы? (*Шома.*) (Активлаштыру.) Балалар, бәрәңгене пешереп ашыйлар. Аны чи килеш ашарга ярамый. Йосыф, кил әле, кәрзиннән тагын бер яшелчәне ал әле. Йосыф нәрсә алды? (*Суган.*) Суган зурмы, кечкенәме? (*Кечкенә.*) (Активлаштыру.) Суган нинди төстә? (*Сары.*) (Активлаштыру.) Рәйсә, кил әле, тотып кара әле суганны, ул кытыршымы, шомамы? (*Шома.*) (Активлаштыру.) Балалар, карагыз әле, суганның кабыгы бар. (Күрсәтә.) Суган ачы, аның кабыгын чистартканда, күзләрдән яшь ага. Мәрьям, кәрзиндә нинди яшелчә калды? Килеп кара әле. Мәрьям нәрсә алды? (*Помидор.*) (Активлаштыру.) Помидор нинди төстә? (*Кызыл.*) (Активлаштыру.) Помидор кечкенәме, зурмы? (*Зур.*) (Активлаштыру.) Мәрьям, бармакларың белән помидорны тотып кара әле, ул нинди? Әйе, помидор йомшак. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, Көз кызы сезгә помидор өләшеп чыга. Помидор тәме буенча нинди? (*Тәмле, сусыл.*) (Активлаштыру. Тәрбияче яшелчәләргә күрсәтә.) Балалар, кишер, бәрәңге, суган, помидор — болар барысы да яшелчәләр. Яшелчәләр бик файдалы. Яшелчәләрне ашагач, сез зур, сәламәт, акыллы булып үсәрсез. Балалар, Көз кызы бу яшелчәләрдән аш пешерергә булды. Ул кәстрүлгә су салды. Плитәгә куйды. (Тәрбияче сөйли, Көз кызы эшләп күрсәтә.) Көз кызы, сиңа нәрсә кирәк? (*Бәрәңге.*) Балалар, кем Көз кызына бәрәңге китереп бирә? Әмир, Көз кызына бәрәңге бир әле. Синең кулыңда нәрсә? (*Бәрәңге.*) Йосыф, Әмир кәрзиннән нәрсә алды? (*Бәрәңге.*) Әмир, Көз кызына бәрәңге бир. «Мә, сиңа бәрәңге»,— дип әйт. Аш тәмле булсын өчен, аңа суган салырга кирәк. Көз кызына кем суган табып бирә? Айсылу, суган бир әле. Синең кулыңда нәрсә? (*Суган.*) Ә хәзер ашка кишер салырга кирәк. Айрат, Көз кызына кишер бир әле. «Менә сиңа зур кызыл кишер»,— дип әйт. (Активлаштыру.) Ашка помидор саласы калды. Көз кызына помидор китереп бир әле, Әдилә. Синең кулыңда нәрсә? (*Помидор.*) (Активлаштыру.) Көз кызы безгә ашны пешереп бетерер, без аны урамнан кергәч ашарбыз. Хәзер без Көз кызына рәхмәт әйтик тә урамга чыгыйк.

## Тема. «ҖИЛ ИСӘ» УЕН КҮНЕГҮЕ. «КЕМ НӘРСӘ АШЫЙ?» ДИДАКТИК КҮНЕГҮЕ

**Бурычлар:**

1) балаларның төсләр турындагы күзаллавын ныгыту, җәнлекләрнең нәрсә ашавы турындагы белемнәрен ачыклау; *ялап эчә, кимерә, чүпли, ашый* фигыльләрен сөйләмдә активлаштыру; авыз аша һаваны әкрен, салмак кына чыгарырга өйрәтү;

2) игътибарны, күзәтүчәнлекне үстерү;

3) җәнлекләргә, кошларга карата кызыксыну тәрбияләү.

**Җиһазлар:** һәр балага башларына кызыл, яшел, сары төстәге юка кәгазь тасмалар ныгытылган 15 см озынлыктагы таякчыклар; рәсемнәр: 1) малай ботка ашый; 2) песи сөт эчә; 3) эт сөяк кимерә; 4) әтәч ярма чүпли.

### Эшчәнлек барышы.

Тәрбияче балаларга шигырь сөйли.

Көз килде.
Үләннәр саргайды, шиңде.
Сап-сары яфраклар
Җиргә сибелде.

Тәрбияче. Балалар, менә көз килеп җитте. Җил исә. Агачтагы яфраклар кыштыр-кыштыр киләләр, алар кыштырдыйлар. Яфраклар нишли эшли? (*Кыштыр-кыштыр киләләр.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар. Тәрбияче балаларга чуклы таякчыклар таратып чыга.) Балалар, болар — таякчыклар. Һәр таякчыкка төрле-төрле төстәге кәгазьләр эленгән: яшел, кызыл, сары. (Бер таякчыкны ала.) Бу таякчыкның кәгазьләре нинди төстә? (*Яшел.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Ә бу чуклар нинди төстә? (*Кызыл.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Бу чуклы таякчыкның кәгазьләре нинди төстә? (*Сары.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, карагыз әле, кәгазьләр ничек кыштырдый! (Тәрбияче таякка тагылган юка кәгазь тасмаларга өрә.) Балалар, сез дә минем кебек өреп карагыз әле. (Балалар чуклы таякчыкларны иреннәреннән 8—10 см ераклыкта тотарга тиеш. Тәрбияче карап, тикшереп тора.) Балалар, барыгыз бергә кәгазь тасмаларга өрегез. (Өрәләр.) Хәзер ял итегез. Менә шулай. Кәгазь тасмаларга өрегез. Булдырдыгыз! Балалар, хәзер кызыл кәгазь тасмаларның кыштырдавын тыңлап карыйк әле. Әлфиянең, Әмирнең, Мәрьямнең кызыл тасмалары менә шулай кыштырдый. Булдырдыгыз! Хәзер сары (яшел) кәгазь тасмалар кыштырдый.

(Тәрбияче балаларның авыздан сулышны салмак итеп, җилкәләрен күтәрмичә чыгаруларын күзәтеп тора. Сулыш чыгарулары йомшак булган балаларны игътибарга ала.) Балалар, карагыз әле бу рәсемгә. Бу нәрсә? (*Песи.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Песи нишли? (*Песи сөтне теле белән ялап эчә.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Бу нәрсә? (*Эт.*) (Активлаштыру.) Эт нишли? (*Эт сөяк кимерә.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Бу нәрсә? (*Әтәч.*) (Активлаштыру.) Әтәч нишли? (*Әтәч ярма чүпли.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Бу кем? (*Малай.*) Ул нишли? (*Малай ботка ашый.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, рәсемнәргә тагын бер тапкыр карагыз әле. (Тәрбияче барлык рәсемнәрне дә мольбертка элә һәм балаларга фразаларны кабатлата: «Малай ботка ашый», «Песи сөт эчә», «Эт сөяк кимерә», «Әтәч ярма чүпли».) Булдырдыгыз! Хәзер бер-берегезгә карап елмаегыз, кулларыгызны чабыгыз. Менә шулай.

## Тема. УРМАНДА

**Бурычлар:**

1) балаларның олылар белән аралашу теләген хуплау, исем һәм сыйфатларны кулланырга өйрәтү: *йомшак йонлы койрык, озын колаклы куян, юан тәпиле аю, соры бүре*; кыргый хайваннарның тышкы билгеләрен һәм гадәтләрен белдерә торган сүзләр хисабына сүзлекне активлаштыру (*төлке бара, куян сикерә, аю алпан-тилпән йөри* һ.б.);

2) ишетү игътибарын, координацияне, ритм хисен үстерү;

3) кыргый хайваннарга карата кызыксыну тәрбияләү.

**Җиһазлар:** фланелеграф (анда көзге пейзаж, агачлар яфрак коя, яшел чыршы), төлке, куян, бүре, аю сурәтләре.

### Эшчәнлек барышы.

Тәрбияче. Балалар, карагыз әле монда. (Фланелеграфка күрсәтә.) Бу нәрсә? (*Урман.*) (Активлаштыру.) Урманда нәрсәләр үсә? (*Агачлар үсә.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Урманда җәнлекләр яши. (Тәрбияче фланелеграфка төлкенең контурлы сурәтен куя.) Бу нәрсә? (*Төлке.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, төлкенең койрыгы нинди? (*Зур. Йомшак. Йонлы.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, төлкегә урманда берүзенә күңелсез. Ул урман буйлап китте һәм үзенә дуслар эзли башлады. (Тәрбияче сөйли һәм фланелеграфта төлкенең гамәлләрен күрсәтә.) Барды-барды төлке һәм куянны очратты.

Төлке куянга: «Исәнме!» — диде. Балалар, куян нинди төстә? (*Соры.*) (Активлаштыру.) Балалар, карагыз әле, куянның колаклары кыскамы, озынмы? (*Озын.*) (Активлаштыру.) Әйе, куян озын колаклы. (Активлаштыру.) Куян йөриме, сикерәме? (*Сикерә.*) Әйе, куян, алгы тәпиләренә басып, арттагы тәпиләре белән сикерә. Әйдәгез әле, куян кебек сикереп карагыз. (Балалар куян кебек сикерәләр.) Булдырдыгыз! Бик җитез һәм шук куяннар булдыгыз. Карагыз әле, төлке белән куян урманда уйнадылар, йөгерделәр, сикерделәр. Шулвакыт алар алдына нәрсә килеп чыкты? (Тәрбияче фланелеграфка аюның контурлы сурәтен куя.) (*Аю.*) (Активлаштыру.) Аю кечкенәме, зурмы? (*Зур.*) Аюның тәпиләре нечкәме, юанмы? (*Юан.*) Әйе, аюның тәпиләре юан. Балалар, аю юан тәпиләре белән алпан-тилпән йөри. (Күрсәтә.) Аю ничек йөри? (*Алпан-тилпән.*) (Активлаштыру.) Аю да куян, төлке белән уйнады. Аларның тавышын ишетеп, бүре чыкты. (Тәрбияче бүренең контурлы сурәтен фланелеграфка куя.) Бу нәрсә? (*Бүре.*) (Активлаштыру.) Бүре соры төстә, аның тешләре бик үткен. Балалар, төлке, куян, аю, бүре урманда яшиләр. Алар — кыргый хайваннар. Хәзер, әйдәгез, бер уен уйнап алыйк.

Аюның өе зур,

(Кулларын өскә күтәрәләр.)

Куяннныкы кечкенә.

(Чүгәлиләр.)

Аю бара алпан-тилпән,

(Алпан-тилпән йөрү хәрәкәтен күрсәтәләр.)

Ә куяннар сикерә.

(Кулларыннан «тәпиләр» ясап сикерәләр.)
(Уен берничә тапкыр кабатлана.)

Тәрбияче. Булдырдыгыз, балалар! Без кыргый хайваннар турында рәсемнәр дә карарбыз әле.

## *Өченче бүлек.* МИН — ДӨНЬЯНЫҢ БЕР КЕШЕСЕ

### Тема. АЛСУ БҮЛМӘСЕ

**Бурычлар:**

1) балаларны өй җиһазларын таный һәм атый белергә өйрәтү; *өстәл, урындык, караватт, шкаф, көзге* кебек исемнәр хисабына сүзлекне активлаштыру, сөйләмнең грамматик төзелешен камилләштерү;

2) балаларның эмоциональлеген, кызыксынуларын үстерү;

3) эшчәнлектә бергәләп катнашу теләге тәрбияләү.

**Җиһазлар:** Алсу-курчак, җиһазланган курчак бүлмәсе.

**Эшчәнлек барышы.**

Тәрбияче. Балалар, бүген безгә Алсу килде. Алсу белән исәнләшегез. («*Исәнме, Алсу!*») Ул сезне кунакка чакыра. Аның сезгә үзенең бүлмәсен күрсәтәсе килә. Алсуның бүлмәсен карыйбызмы? (Тәрбияче балаларга курчак өенең бер бүлмәсен күрсәтә.) Балалар, бу — Алсу бүлмәсе. Нинди җиһазлар бар икән Алсу бүлмәсендә? Бу нәрсә? (*Караватп.*) (Индивидуаль кабатлаулар.) Караватп ни өчен кирәк? (*Йоклар өчен.*) Балалар, карагыз әле, караватп өстендә җәймә һәм мендәр бар. Камилә, җәймәне күрсәт әле. Син нәрсә күрсәттең? (*Җәймә.*) Бу нәрсә? (*Җәймә.*) (Активлаштыру.) Камил, мендәрне күрсәт әле. Син нәрсә күрсәттең? (*Мендәр.*) Бу нәрсә? (*Мендәр.*) (Активлаштыру.) Ә бу нәрсә? (*Өстәл.*) Өстәл ни өчен кирәк? Әйе, өстәл артына утыралар, ашыйлар, китаплар карыйлар, рәсем ясыйлар. (Активлаштыру.) Ә бу нәрсә? (*Урындык.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Урындык ни өчен кирәк? (*Утыру өчен.*) (Активлаштыру.) Урындык нәрсәләрдән тора? (*Урындыкның аркасы бар, утыргычы һәм аяклары бар.*) (Урындыкның өлешләрен балалар белән аерым-аерым карыйлар. Активлаштыру.) Ә бу нәрсә? (*Шкаф.*) Шкаф ни өчен кирәк? Әйе, Алсу шкафка уенчыкларын, китапларын куя. (Активлаштыру.) Балалар, ә бу нәрсә? (*Көзге.*) Көзге ни өчен кирәк? Әйе, Алсу, көзгегә карап, чәчен тарый, күлмәген кия. Балалар, без Алсуның бүлмәсен карадык. Аның бүлмәсе бик матур һәм чиста. Ә хәзер Алсуның сезнең белән качышлы уйныйсы килә. «Мин качам, ә сез эзләгез», — ди Алсу. Күзләрегезне йомыгыз. Бер, ике, өч! Күзләрегезне ачыгыз! Балалар, Алсу кая качкан? (*Шкаф артына.*) Рамилә, Алсуга әйт: «Алсу, шкаф артыннан чык!» (Индивидуаль кабатлаулар. Тәрбияче Алсуны башка урыннарга да качыра.) «Алсу, өстәл астыннан чык!» (Индивидуаль кабатлаулар.) «Алсу, караватп өстеннән төш!» (Индивидуаль кабатлаулар.) «Алсу, көзге артыннан чык!» (Индивидуаль кабатлаулар.) Булдырдыгыз, балалар! Алсу сезгә дә рәхмәт әйтә. Алсу кая гына качмасын, сез аны таба алдыгыз. Алсу уйнап арыды, урындыкка килеп утырды. Балалар, сез дә урындыкларга утырыгыз әле. Бармак уены уйнап алырбыз.

Бу бармак — бабай,
Бу бармак — әби,
Бу бармак — әти,
Бу бармак — әни,
Бу бармак — бәби,
Аның исеме — чәнти!

Тәрбияче уенның сүзләрен әйтә, бармаклар белән уйнап күрсәтә. Балаларны да уенда катнаштыра.

## Тема. «БУ ӨЙДӘ КЕМ ЯШИ?» ДИДАКТИК УЕНЫ

**Бурычлар:**

1) төркемгә йөрүче балаларның исемнәрен истә калдырырга ярдәм итү, фигыльләрне хәзерге һәм киләчәк заманда куллана белергә өйрәтү, сорауны белдерә торган сүзләрне кулланырга күнектерү;

2) игътибарны, кабул итү сәләтен, диалогик сөйләмне үстерү;

3) бер-береңә карата игътибарлылык тәрбияләү.

**Җиһазлар:** фланелеграф, «Теремкәй» әкияте персонажлары сурәтләре, картоннан ясалган өй.

### Эшчәнлек барышы.

Тәрбияче балаларга рус халык әкияте «Теремкәй»не сөйли. Сөйләвен җәнлекләрнең контурлы сурәтләрен демонстрацияләү белән бергә алып бара.

Тәрбияче. Балалар, әйдәгез, без дә бергәләп «Бу өйдә кем яши?» дигән уенны уйнап алыйк. Менә безнең өебез. (Картоннан ясалган өйне китереп куя.) Әдилә өй янына килә, ишек шакый һәм сорый: «Бу өйдә кем яши?» — ди. Кил әле, Әдилә, кабатла мин әйткәнне. (Әдилә картоннан ясалган өй янына килә һәм сорауны кабатлый.) Әдиләгә беркем дә җавап бирмәгән. Ул өйдә яши башлаган. (Әдилә өй артына кереп китә. Тәрбияче үзе янына Камиләне чакыра.) Камилә өй яныннан үтеп бара икән. Ул ишеккә шакыган.

Камилә. Бу өйдә кем яши?

Әдилә. Мин — Әдилә, ә син кем?

Камилә. Мин — Камилә, мине өйгә керт әле, бергә яшәрбез.

Тәрбияче. Әдилә Камиләне өйгә керткән, алар бергә яши башлаганнар. Булат өй яныннан үтеп бара икән. Ул ишеккә шакыган.

Булат. Бу өйдә кем яши?

Әдилә. Мин — Әдилә.

Камилә. Мин — Камилә. Ә син кем?

Булат. Мин — Булат, мине өйгә кертегез әле, бергә яшәрбез. (Шулай итеп, төркемдәге барлык балалар да, «өй» янына килеп, үзләренең исемнәрен атыйлар.) Шулай итеп, балалар бу өйдә яши башлаганнар. Балалар, безнең төркемгә йөрүче балаларның исемнәре бик матур: Булат, Әдилә, Мәрьям, Әмир... Әти-әниләрегез сезгә бик мәгънәле исемнәр куйган. Бер-берегезгә ягымлы итеп эндәшегез. Мин сезнең барыгызны да яратам!

## *Дүртенче бүлек.* МИНЕМ ӘЙЛӘНӘ-ТИРӘМ
### Тема. АЛСУ БЕЗДӘ КУНАКТА

**Бурычлар:**

1) балаларга табиб, полиция хезмәткәре һөнәрләре турында мәгълүмат бирү; грамматик яктан җөмләләрне аңларга һәм аларны сөйләмдә дөрес кулланырга өйрәтүне дәвам итү;

2) игътибарны, хәтерне, күзәтүчәнлекне, кабул итү сәләтен үстерү;

3) һөнәрләргә карата кызыксыну тәрбияләү.

**Җиһазлар:** Алсу-курчак, кәрзин, кәрзиндә: табибә, полиция хезмәткәре рәсемнәре, фуражка, халат, витаминнар.

**Эшчәнлек барышы.**

Ишек шакыйлар. Алсу-курчак керә.

Алсу-курчак. Исәнмесез, балалар! (*Исәнме, Алсу!*)

Тәрбияче. Алсу, син бүген нигә боек? Нигә шундый күңелсез?

Алсу-курчак. Минә бу төркемдә бик акыллы балалар бар, диләр. Алар миңа ярдәм итмәсләр микән? Минем әтием, әнием эшлиләр. Ә аларның кем булып, кайда эшләгәннәрен мин белмим. Шуңа мин бик боек, шуңа күңелсез.

Тәрбияче. Балалар, әйдәгез, Алсуга ярдәм итик. Алсу, ә синең кәрзинеңдә нәрсәләр бар? (Алсу кәрзиненнән рәсемнәр чыгара.)

Алсу-курчак. Бу — минем әтием. (Алсу урамда машиналарны күзәтеп торучы полиция хезмәткәре сурәтен күрсәтә.)

Тәрбияче. Балалар, Алсуның әтисе кем булып эшли икән? (*Полиция хезмәткәре.*) Әйдәгез, кабатлагыз әле: «полиция хезмәткәре». (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар.) Балалар, Алсу тагын бер рәсем күрсәтә:

Алсу-курчак. Бу — минем әнием.

Тәрбияче. Балалар, әйтегез әле: Алсуның әнисе кем булып эшли икән? (*Табиб.*) (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар.) Әйе, Алсуның әнисе табиб, яисә врач булып эшли. Балалар, врач татарча табиб була. Абый кеше табиб була. Ә апа кеше табибә була. Кабатлагыз әле бу сүзләрне. (*Табиб, табибә.*) (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар.) Алсу, синең әтиең полиция хезмәткәре булып эшли, әниең табибә булып эшли икән. Балалар, әйдәгез, уйнап алабыз! Алсуның кәрзинендә булган уенчыкларны карыйк әле. Бу нәрсә? (Фуражка күрсәтә.) (*Фуражка.*) (Активлаштыру.) Фуражка кемгә кирәк? (*Әтигә.*) Алсуның әтисе кем булып эшли? (*Полиция хезмәткәре.*) Азат, бу фуражканы кем кия?

(*Полиция хезмәткәре.*) (Активлаштыру.) Ә бу нәрсә? (Халат күрсәтә. Активлаштыру.) Халат кемгә кирәк? (*Табибәгә. Алсуның әнисенә.*) Алсуның әнисе кем булып эшли? (*Табибә.*) Табибә囲 эштә нәрсә кия? (*Халат кия.*) (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар.) Балалар, сез Алсуга бик булыштыгыз. Ул сезгә рәхмәт әйтә. Аңа әнисе күп итеп витаминнар биргән. Хәзер ул сезне витаминнар белән сыйлый. (Витаминнар тарата.) Балалар, әйдәгез, Алсуга рәхмәт әйтегез! (Балалар Алсуга рәхмәт әйтәләр.) Сау булыгыз, бервакытта да авырмагыз! Балалар, Алсу сезгә дә рәхмәт әйтә. Сез аңа әти-әнисенең кем булып эшләгәнен дөрес әйтеп бирдегез. Безнең төркемгә йөрүче балаларның әти-әниләре — төрле һөнәр кешеләре. Алар арасында полиция хезмәткәрләре, табиблар, укытучылар, тәрбиячеләр, төзүчеләр, шофёрлар да бар. Булдырдыгыз, балалар! (Кул чабалар.)

## Тема. ӘМИНӘНЕҢ ТУГАН КӨНЕНӘ КИЛЕГЕЗ

**Бурычлар:**

1) [к] һәм [к] авазларының сүзләрдә һәм сөйләмдә дөрес әйтелешен ныгыту, килеш кушымчаларын дөрес әйтергә өйрәтү, савыт-сабаларны белдерә торган сүзләр хисабына сүз байлыгын арттыру һәм активлаштыру, гомумиләштерүче сүзләрне (савыт-саба) аңлый һәм куллана белүләренә ирешү, җөмләләр белән җавап бирергә күнектерүне дәвам итү;

2) инициативалы сөйләмне, игътибарны, хәтерне үстерү, башкаларга мөрәҗәгать итәргә теләк тудыру;

3) үзара аралашуга омтылыш тәрбияләү.

**Җиһазлар:** курчаклар, уенчык савыт-сабалар (чынаяк, тәлинкә, чәйнек), калачлар.

### Эшчәнлек барышы.

Т ә р б и я ч е . Балалар, бүген бездә бәйрәм. Әминәнең туган көне. Бүген бездә нинди бәйрәм? (*Әминәнең туган көне.*) (Активлаштыру.) Туган көн бәйрәменә кемнәр килә? (*Кунаклар.*) Алинә, кемнәр килә? (*Кунаклар килә.*) (Активлаштыру.) Балалар, кунак чакырганда, ягымлы сүзләр әйтәләр. Әйдәгез әле, Мәдинә исемле курчакны кунакка чакырабыз. Мәдинә, без сине туган көн бәйрәменә чакырабыз. Алия, әйтеп кара әле, син Мәдинәне ничек итеп туган көнгә чакырырсың? (Активлаштыру.) Әйе, балалар, бик дөрес: «Мәдинә, без сине туган көн бәйрәменә чакырабыз. Кил, яме. Көтәбез!» — дияргә кирәк. Марат, син Әмирне кунакка чакыр әле. (*Әмир,безгә кунакка кил, яме.*) Марат, син кемне чакырдың? (*Әмирне.*) Яхшы. Дилә, ә син кемне чакырасың? (*Лилияне.*) Чакырганда

нәрсә дип әйтәсең?(*Лилия,бүген безгә кунакка кил!*) Балалар, менә сез кунаклар чакырдыгыз. Кунаклар килгәнче, коймак пешерик. Нәрсә пешерәбез? (*Коймак.*)

Балалар, учларына җиңелчә сугып, «коймак пешереп», тәрбияче белән түбәндәге шигырьне кабатлыйлар:

Әминәнең туган көненә
Без чакырдык кунаклар,
Кунакларның килүенә
Без пешердек коймаклар.

Тәрбияче. Булдырдыгыз, балалар! Ә хәзер кунаклар килүенә өстәл әзерлик. Өстәлгә нәрсә куярбыз? Алия, әйт әле: син өстәлгә нәрсәләр куярсың? (*Тәлинкә.*) (Активлаштыру.) Балалар, тәлинкә ни өчен кирәк? (*Тәлинкәгә торт, коймак, бәлеш салалар.*) Азат, син өстәлгә нәрсә куярсың? (*Чынаяк.*) (Активлаштыру.) Чынаяк ни өчен кирәк? (*Чынаякка чәй салалар.*) (Активлаштыру.) Балалар, бу нәрсә? (Чәй тәлинкәсе күрсәтә.) (*Чәй тәлинкәсе.*) Әйе, бу — чәй тәлинкәсе. Чынаякны чәй тәлинкәсенә куялар, менә шулай. (Күрсәтә.) Балалар, бу нәрсә?(*Чәйнек.*) (Активлаштыру.) Чәйнек ни өчен кирәк? (*Анда чәй пешерәләр.*) Әйе, чәйнектә чәй пешерәләр. (Активлаштыру. Тәрбияче тагын бер тапкыр савыт-сабаны күрсәтеп чыга: чынаяк, чәй тәлинкәсе, чәйнек. Активлаштыру.) Балалар, тәлинкә, чынаяк, чәй тәлинкәсе, чәйнек бер сүз белән ничек атала әле? (*Савыт-саба.*) (Активлаштыру. Тәрбияче балалар белән өстәл әзерли, бергәләп өстәлгә савыт-сабаларны куялар, аларның исемнәрен төрлечә кабатлыйлар.) Балалар, менә өстәл әзер. Сез бүген Әминәнең туган көнендә — үзегез кунаклар. Әйдәгез, рәхим итегез, түрдән узыгыз! Мәдинәне дә утыртып куябыз. Ул да кунак бит. Балалар, бүген нинди бәйрәм әле? (*Әминәнең туган көне.*) Әйе, туган көн бәйрәме. Балалар, туган көндә матур теләкләр телиләр. Әйдәгез, Әминәгә теләкләр телик әле. Әминәгә шатлыклар телик, зур үссен, сәламәт булсын дигән теләкләр телик. Балалар, Әминә сезгә теләкләрегез өчен рәхмәт әйтә. Әйдәгез, бергәләп «Ак калач» уенын уйныйбыз. (Уеннан соң балалар чәй эчәләр.)

## Тема. МИНЕМ ГАИЛӘМ

**Бурычлар:**

1) сөйләмдә ягымлы сүзләрне (*әти — әтием, әни — әнием, әби — әбием, сеңел — сеңлем*) кулланырга өйрәтү; [ә] авазының әйтелешен

ныгыту, аны ачык, тиешле дәрәҗәдә кычкырып әйтүләренә ирешү, тәрбияче сорауларына җавап бирергә күнектерү;

2) игътибарны, хәтерне үстерү; зурлар һәм үз яшьтәшләре белән ирекле аралашуларына ирешү;

3) гаилә әгъзаларына ихтирам тәрбияләү.

**Җиһазлар:** гаилә рәсеме, курчаклар.

## Эшчәнлек барышы.

Тәрбияче. Балалар, бүген безгә кунак килгән. (Тәрбияче курчак күрсәтә.) Балалар, бу нәрсә? (*Курчак.*) (Активлаштыру.) Балалар, курчак белән исәнләшегез әле. (Исәнләшәләр.) Гүзәл, кил әле, курчакның исемен сора.

Гүзәл. Курчак, синең исемең ничек?

Курчак. Әнисә. (Активлаштыру.)

Тәрбияче. Балалар, Әнисә тартма алып килгән. Нәрсә алып килгән? (*Тартма.*) (Активлаштыру.) Әйдәгез, тартманы ачып карыйк әле. Тартма эчендә нәрсә бар? (*Рәсем.*) (Тәрбияче гаилә төшерелгән рәсем ала. Аны, мольбертка куеп, балаларга карарга мөмкинлек бирә.) Балалар, бу рәсемдә *әти, әни, бабай, әби, апа, абый, сеңел, энекәш* сурәтләнгән. (Тәрбияче балаларны активлаштыра.) Марат, кил әле, әтине күрсәт. Бу кем? (*Әти.*) Әйдәгез, *әти* сүзен ягымлы итеп, *әтием* дип әйтегез әле. (Активлаштыру. Шул рәвешле, башкаларны да күрсәтеп һәм ягымлы итеп (*әнием, әбием, бабам, апам, абыем, сеңлем, энем*) әйтеп чыгалар.) Балалар, бу гаилә дус, тату. Алар күңелле яшиләр. Сезнең гаиләдә кемнәр бар? (Балаларның җаваплары.) Алсу, минем арттан кабатла әле: «Минем әтием бар». (Алсу кабатлый. Активлаштыру.) Гүзәл, кабатла әле: «Минем әнием бар». (Активлаштыру.) Әмир, кабатла әле: «Минем әбием бар». (Активлаштыру.) Булат, кабатла әле: «Минем сеңлем (апам, абыем, энем) бар». (Активлаштыру.) Булдырдыгыз, балалар! Балалар, әти, әни, әби, бабай — сезнең бик якын кешеләрегез. Якын кешеләрегезне яратыгыз!

Балалар, сез сорауларга бик матур җавап бирдегез. Сез бик акыллылар. Алга таба да шундый булыгыз! Сезнең һәрберегезгә мин бүген елмайган кояш рәсеме бүләк итәм. Әйдәгез, бергәләп кояш нурлары ясыйк әле. Кулларыгызны алга сузыгыз, бер-берегез белән кулга-кул тотышыгыз. Үзегезне җылы кояш нурлары кебек тоеп, тыныч кына басып торыгыз. Менә безнең бүлмәбезне нинди матур кояш яктырта! Аның җылысы нурлар аша бөтен бүлмәгә тарала. Бүлмәбез тагын да якты, җылы була!

## *Бишенче бүлек.* ЯҢА ЕЛ БӘЙРӘМЕ

### Тема. КУПШЫ ЧЫРШЫ

**Бурычлар:**

1) сузык һәм тартык авазларны, аваз ияртемнәрен ачык әйтергә, *түбәндә* сүзен сөйләмдә кулланырга өйрәтү; сыйфатларны дөрес кулланырга күнектерү;

2) сорауларга җавап бирү осталыгын, игътибарны, күзәтүчәнлекне үстерү;

3) табигатькә соклану хисләре тәрбияләү.

**Җиһазлар:** бүлмәгә бизәлгән чыршы куела, конфетлар салынган «тылсымлы» капчык, күңелле бию көе аудиоязмасы, каз, үрдәк, әтәч, бал корты, чыпчык, күгәрчен, эт, елан, ат битлекләре.

### Эшчәнлек барышы.

Тәрбияче балаларны кабул итү бүлмәсенә алып чыга. Уен бүлмәсенә бизәлгән чыршы куела.

Тәрбияче. Балалар, бүген бездә бәйрәм. Җәнлекләр, кошлар, бөҗәкләр, еланнар өчен бәйрәм башлана. Җырлар да булыр, биюләр дә булыр. (Тәрбияче балаларны, парлап, үзе янына чакыра.) Гүзәл, Арслан, минем яныма килегез әле. Сез ак казлар булырсыз! (Тәрбияче балаларга җәнлек, кош-корт битлекләрен кидерә.) Исәнмесез, ак казлар! Казлар кебек тавыш бирегез әле. (*«Ка-ка-ка!»*) Менә казлар ничек матур итеп каңгылдыйлар: «Ка-ка-ка!» Исәнмесез, үрдәкләр! (Тәрбияче тагын ике баланы чакыра.) Үрдәк булып кычкырыгыз әле. (*«Бак-бак-бак!»*) Әйе, үрдәкләр «бак-бак!» диләр. Исәнмесез, бал кортлары! (Тагын ике бала чакырыла.) Бал кортлары кебек безелдәгез әле. (*«Без-з-з!»*) Исәнмесез, таң әтәчләре! Әтәч кебек кычкырыгыз әле. (*«Кикрикү-күк! Кикрикү-күк!»*) (Этләр «һау-һау» дип өрәләр, еланнар «ш-ш-ш» дип ысылдыйлар, атлар «ми-һа-һай» дип кешниләр, күгәрченнәр «гөр-гөр» дип гөрлиләр, чыпчыклар «чырык-чырык» дип чыркылдыйлар һ.б.) Балалар, менә барыгыз да чыршы янына җыелдыгыз. Хәзер барыгыз да казлар кебек каңгылдагыз әле. Елан булып ысылдагыз. (Шулай итеп, барлык кошлар, хайваннар, бөҗәкләр чыгарган тавышларга охшатып кычкыралар. Күңелле бию көе куела.)

Их, безнең чыршы,
Ул нинди купшы!
Янында күмәк
Уйнавы яхшы.

(*К. Кинзәбулатова*)

Балалар, әйдәгез, чыршы янында биеп алыгыз әле! Менә шулай. Булдырасыз! Балалар, хәзер чыршыны мактагыз әле. Матур сүзләр әйтеп чыршыны куандырыйк. (*Матуркай, йомшаккай, хуш исле, энәле, әйбәт, шәп, төз, биек, бик матур, купшы* һ.б.) Афәрин! Балалар, чыршы төбендә нәрсәдер бар. Әйдәгез, карыйк әле. Чыршы төбендә нәрсә бар? (*«Тылсымлы» капчык.*) (Активлаштыру.) Балалар, «тылсымлы» капчык кайда ята? (*Чыршы төбендә.*) (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар. Капчыкны ачып карыйлар. Аның эчендәге конфетларны алып, тәрбияче балаларны чәй эчәргә чакыра.) Балалар, конфет белән чәй эчәргә утырыгыз! Чәйләрегез тәмле булсын!

## Тема. КУЯН ЧЫРШЫ ЯНЫНДА

**Бурычлар:**

1) сөйләмдә бәйлек сүзләрне (*эчендә, артында, астында, өстендә*) кулланырга, *кайда? кая?* сорауларына җавап бирергә, тәрбияче һәм иптәшләре белән ирекле аралашырга өйрәтүне дәвам итү; тавыш көчен дөрес куллану осталыгы формалаштыру;

2) игътибарны үстерү, тәрбияче күрсәтмәләрен үтәүдә күнектерү;

3) нәфис сүз белән кызыксыну тәрбияләү.

**Җиһазлар:** «тылсымлы» тартмага салынган куяннар (һәр балага җитәрлек), бизәп куелган уенчык чыршы, уенчык төлке; «Куяннар һәм төлке» аудиоязмасы (татар халык сүзләре, В. Вәлиева көе).

### Эшчәнлек барышы.

Уен бүлмәсендә бизәлгән чыршы тора. Тәрбияче балаларны чыршы янына чакыра. Шигырь укый.

Чыршы үсә урманда,
Чыршылар бик күп анда.
«Уенчыклар әләм», — дип
Сикереп йөри куян да.

(*К. Даян*)

Тәрбияче. Балалар, нинди матур чыршы! Ягез әле, чыршыны мактыйк. (*Яшел, бик матур, биек, купшы, төз, хуш исле, ямьле, энәле, йомшак, матуркай* һ.б.) Булдырдыгыз, балалар! Сез чыршыны матур сүзләр әйтеп куандырдыгыз! Балалар, карагыз әле, чыршы төбендә нәрсәдер бар. Нәрсә икән бу? (*Тартма.*) (Активлаштыру.) Әйе, балалар, «тылсым-

лы» тартма. (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар.) Тартма кайда ята?(*Чыршы төбендә.*) (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар.) Тартма матурмы? (*Матур.*) Аның эчендә нәрсәдер бар. (Селкетә.) Ишетәсезме, тавыш ишетелә. Балалар, тартманы ачмыйча гына, аның эчендә нәрсә барлыгын әйтеп буламы? (*Юк.*) Әгәр дә мин тартма эчендәге әйбер турында озын колаклы, кишер ярата дисәм әйтә аласызмы? Нәрсә ул: үзе озын колаклы, кишер ярата? (*Куян.*) Дөрес, куян. (Активлаштыру.) Балалар, куяннар кайда? (*Тартма эчендә.*) (Активлаштыру.) Хәзер тартманы ачабыз. (Тәрбияче тартманы ача һәм балаларга күрсәтә.) Монда куяннар күп. Гүзәл, кил әле, син бер куянны үзеңә кунакка чакыр! Гүзәл, син нәрсәне кунакка чакырдың? (*Куянны.*) Хәзер Марат, Алсу, Дилә, Әмир, берәр куянны үзегезгә кунакка чакырыгыз. Дилә, ал куянны. Син нәрсә алдың?(*Куян.*) (Активлаштыру.) Балалар, барыгыз да берәр куян алыгыз. Куян төлкедән курка. (Төлкене күрсәтә.) Куян нәрсәдән курка? (*Төлкедән.*) (Активлаштыру.) Куян төлкедән курка, шуңа күрә ул кача. (Тәрбияче куянны артына яшерә.) Балалар, сез дә куянны артка яшерегез. Куян качты. Хәзер куянны өскә күтәрегез, минем кебек. Менә шулай. (Күрсәтә.) Алсу, син куянны кая яшердең? (*Өскә.*) (Активлаштыру.) Куян кайда? (*Өстә.*) (Активлаштыру.) Куянны өстәл өстенә куегыз! Куян кайда? (*Өстәл өстендә.*) Әйдәгез, тыныч кына кабатлагыз! (*Өстәл өстендә.*) Төлке ишетә күрмәсен! Төлке килә. (Төлкене күрсәтә.) Әйдәгез, куянны тагын артка качырыгыз. Менә шулай, булдырдыгыз! Хәзер куян кайда? (*Артта.*) (Активлаштыру.) Хәзер куянны тартма эченә яшерегез. Сез куянны кая яшердегез? (*Тартма эченә.*) (Активлаштыру.) Куян чыршы артына качты. Куян, син кайда? Балалар, куян кайда? (*Чыршы артында.*) (Активлаштыру.) Ә хәзер куян чыршы артыннан чыкты. Куян чыршы астына качты! Рамил, куян кая качты?(*Чыршы астына.*) (Активлаштыру.) Әйдәгез, тыныч кына кабатлагыз, төлке ишетә күрмәсен. (Балалар кабатлыйлар: *«Куян чыршы астына качты».*) Балалар, әйдәгез, «Куяннар һәм төлке» уенын уйныйк әле.

Ап-ак куян утыра,
(Балалар чүгәләп утыралар.)

Колакларын селкетә.
(Куян колаклары ясап, кулларын башка куялар һәм селкетәләр.)

Менә шулай, менә шулай
Колакларын селкетә.

Аңа тик тору кыен,
Җылыта ул тәпиен.

(Кулларын сыйпыйлар, уалар.)

Һап, һап, һап, һап,

(Кулларын чәбәклиләр.)

Җылыта ул тәпиен.
Куян тик торса туңа,

(Кулларын билгә куеп, куян кебек сикерәләр.)

Сикергәли ул шуңа.
Һап, һап, һап, һап,
Сикергәли ул шуңа.
Кем куянны куркытты?
Куян сикереп качты.

(Балалар, куян кебек сикереп,)

Ай, качты, качты, качты,

(тәрбияче янына киләләр.)

Куян сикереп качты.

Булдырдыгыз, балалар! Сез бик җитез, өлгер куяннар булдыгыз!

## Тема. ПЕСИ БЕЛӘН КӘҖӘ ЧЫРШЫ ЯНЫНДА

**Бурычлар:**

1) балаларны тәрбияче сорауларына җавап бирергә өйрәтүне дәвам итү, сөйләмдә фигыльләр һәм сыйфатлар куллануны активлаштыру; [ж] авазын иҗекләрдә, сүзләрдә һәм җөмләләрдә дөрес һәм ачык әйтүләренә ирешү; аваз иялтемнәрен кабатлаганда, тавыш көчен җайлый белергә күнектерү;

2) игътибарны, кабул итү сәләтен, тәрбияче күрсәтмәләрен үтәү осталыгын үстерү;

3) хайваннарга карата мәрхәмәтлелек тәрбияләү.

**Җиһазлар:** уенчык песи, кәҗә; бүлмәдә бизәп куелган чыршы; песи, кәҗә хәрәкәтләре сурәтләнгән рәсемнәр.

### Эшчәнлек барышы.

Тәрбияче. Балалар, чыршы янына басыгыз әле. Бүген чыршы янына хайваннар килгән. Нәрсәләр килгән? (*Хайваннар.*) (Активлаштыру.) Балалар, чыршы янына йорт хайваннары килгән. Марат, нинди хайваннар килгән? (*Йорт хайваннары.*) (Активлаштыру.) Нинди йорт хайваннары килгәнен сез хәзер белерсез. «Мияу-мияу» дип кычкыра, тәмле итеп сөт ялый, тычканнарны да аулый. Балалар, бу нәрсә?

(*Песи.*) (Активлаштыру.) Булат, песине чыршы төбеннән алып кил әле. Булат нәрсә алып килде? (*Песи.*) (Активлаштыру.) Балалар, песи турында матур сүзләр әйтик әле: «Песи йомшак, матур, кечкенә, акыллы» һ.б. (Активлаштыру.) Әйдәгез, песигә ягымлы итеп эндәшегез әле: «пескәй, песием, йомшаккай, матурым». (Активлаштыру. Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар. Тәрбияче песинең хәрәкәтләре сурәтләнгән рәсемнәр күрсәтә.) Балалар, песи нәрсә эшли? (*Сикерә. Уйный. Сөт эчә.*) (Активлаштыру.) Балалар, песи баласы зурмы, кечкенәме?(*Кечкенә.*) Әйдәгез, аңа исем кушыгыз әле. (*Йомшаккай.*) Песи ничек мияулый? (*«Мияу!»*) Әйдәгез, әни песи булып мияулап күрсәтегез әле. Хәзер песи баласы булып мияулагыз! (Балалар әни песи тавышын калынрак, ә песи баласын нечкәрәк тавыш белән белдерәләр.) Хәзер, балалар, уйнап алыйк. Мин әни песи булам, ә сез — песи балалары. Менә песи балалары йокыдан тордылар, тәпиләре белән битләрен юдылар, аларга бик күңелле, һәм алар уйный, йөгерә, сикерә башладылар. (Уен ике тапкыр кабатлана.) Булдырдыгыз, балалар! Карагыз әле, чыршы янына тагын бер йорт хайваны килгән. Ул чыршы төбенә качкан. Аның сакалы бар, мөгезе бар, сөт бирә, кәбестә ярата. Бу нәрсә? Табыгыз әле аны. (Тәрбияче балаларга кәҗәне табарга ярдәм итә.) Алсу, кәҗәне алып кил әле монда. Балалар, әйдәгез, кәҗәне бергәләп чакырыйк әле. (*Кәҗә, кил әле монда!*) Әйдәгез, тагын да ягымлырак итеп чакырыгыз әле. (*Кәҗәкәй, кил әле монда!*) (Активлаштыру.) Балалар, кәҗә ничек кычкыра? (*«Мә-ә-ә!»*) Балалар, кәҗәнең мөгезен күрсәтегез әле. (Тәрбияче бер-ике баланы чакыра.) Хәзер кулларыгызны баш өстенә куеп, кәҗәнең мөгезен ясап күрсәтегез әле. Кәҗәнең мөгезләре бик матур. Матур итеп күрсәтегез. Булдырдыгыз! Балалар, кәҗә мөгезле, ак төстә, акыллы, җитез, чиста була һ.б. (Активлаштыру. Тәрбияче кәҗә хәрәкәтләре сурәтләнгән рәсемнәр күрсәтә.) Кәҗә нәрсә эшли?(*Печән ашый. Сөт бирә. Кычкыра. Сикерә. Сөзә.*) (Активлаштыру.) Дөрес, балалар. Әгәр дә кәҗәне кыерсытсаң, ул мөгезләре белән сөзәргә мөмкин. Шуңа күрә кәҗәне кыерсытырга ярамый, аны яратырга кирәк. Хәзер уйнап алырбыз. Мин әни кәҗә булам, ә сез кәҗә бәтиләре булырсыз. Кәҗә бәтиләре йөгерәләр, сикерәләр. Әниләре килгәнен күрделәр дә: «Җә-җә-җә, килә монда кәҗә!» — диделәр. (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар.) Балалар, бик күңелле итеп уйнадыгыз. Чын кәҗә бәтиләре шикелле йөгердегез, сикердегез. Сез бүген мине куандырдыгыз!

## Тема. «ТЫЛСЫМЛЫ» ТАЯКЧЫК

**Бурычлар:**

1) балаларны сузык һәм тартык авазларны, аерым сүзләрне ачык итеп әйтергә өйрәтү; төсләр турындагы күзаллауларын ныгыту, төсне белдерә торган сыйфатларны активлаштыру;

2) балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын, ишетү осталыгын үстерү;

3) эшчәнлектә бергәләп шөгыльләнү теләге тәрбияләү.

**Җиһазлар:** «тылсымлы» таякчык, бизәлгән чыршы, «Чыршыкай-матуркай» җырының аудиоязмасы (В. Вәлиева көе һәм сүзләре).

### Эшчәнлек барышы.

Тәрбияче. Балалар, бүген минем кулымда «тылсымлы» таяк бар. Менә ул! (Күрсәтә.) Таяк белән нинди дә булса предметка кагылсаң, ул аның исемен кычкырып атый. Ә сез «тылсымлы» таяк әйткән сүзне кабатларсыз. Башта игътибар белән карагыз. (Тәрбияче «тылсымлы» таяк белән чыршыга күрсәтә.) Мин хәзер сезгә бер сүз әйтәм. Тыңлагыз әле: «чыршы». Әйдәгез, бергәләп минем белән кабатлагыз. Сүзнең ничек яңгырашын тыңлагыз: «чыр-шы». Булдырдыгыз, дөрес итеп әйттегез бу сүзне! Чыршы нинди төстә?(*Яшел.*) Бергәләп кабатлыйк әле: «яшел чыршы». Менә бу уенчык ничек атала икән? (Чыршыдагы шарга күрсәтә.) Әйт әле, Марат. (*Шар.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Хәзер бу сүзнең әйтелешен тыңлагыз әле: «шар». Тагын бер кат кабатлагыз әле, балалар. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Шар нинди төстә? (*Зәңгәр.*) Бергәләп кабатлыйк әле: «зәңгәр шар». Хәзер «тылсымлы» таяк нәрсәгә күрсәтер икән? (Чыршыда эленеп торган йолдызга күрсәтә.) Балалар, «тылсымлы» таяк нәрсә күрсәтә?Бу нәрсә? (*Йолдыз.*) (Активлаштыру.) Хәзер бу сүзнең яңгырашын тыңлагыз: «йол-дыз». (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Йолдыз нинди төстә?(*Кызыл.*) Бергәләп кабатлыйк әле: «кызыл йолдыз». Балалар, хәзер «тылсымлы» таяк нәрсәгә күрсәтер икән?(Күркәгә күрсәтә.) Бу нәрсә? (*Күркә.*) (Активлаштыру.) Хәзер бу сүзнең яңгырашын тыңлагыз: «күр-кә». (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Булдырдыгыз! Әйдәгез, ул сүзләрне тагын бер кат бергәләп кабатлап чыгыйк әле: «чыршы, шар, йолдыз, күркә». Рәхмәт сезгә дөрес җавапларыгыз һәм сүзләрне теләп кабатлавыгыз өчен.

Балалар, ә хәзер, «Чыршыкай-матуркай» җырын җырлап, чыршы тирәли әйлән-бәйлән уйнап алыйк.

Күрәсеңме, яшел чыршы,
Безне, нәниләреңне.
Без бик-бик яратабыз
Синең тәтиләреңне.

Син, чыршыкай-матуркай!
Тәтиләреңне кабыз!
Без сине бик яратып,
Шатланып кул чабабыз!

Балалар, әйдәгез, чыршы тирәли кулга-кул тотышып басыйк әле. Күзләрегезне йомыгыз, кулларыгызның җылысын тоеп, бер-берегезгә шатлык теләгез. Булдырдыгыз, балалар!

## *Алтынчы бүлек.* КЫШ

### Тема. КОШЛАР

**Бурычлар:**

1) балаларны аваз ияртемнәрен дөрес һәм ачык итеп әйтергә, алардан фигыльләр (*гөр — гөрли, чырык — чыркылдый, кар — каркылдый*) ясарга өйрәтү; гомумиләштерүче сүзләрне (*тавык, әтәч, каз — йорт кошлары*) кулланырга күнектерү; кош исемнәрен, гәүдә өлешләрен, хәрәкәтләрне белдерүче сүзләр хисабына сүз байлыгын активлаштыру, балаларны кошлар белән таныштыруны дәвам итү;

2) балаларның игътибарын, хәтерен, сөйләмен үстерү;

3) кошларга карата кызыксыну, кайгыртучанлык тәрбияләү.

**Җиһазлар:** уенчык кош, төрле кош битлекләре, йорт кошлары һәм безнең якта кышлаучы кош рәсемнәре.

### Эшчәнлек барышы.

Тәрбияче. Балалар, карагыз әле, безгә бер кош кунакка килгән. Әйдәгез, аның белән исәнләшик. (Балалар исәнләшәләр.)

Тәрәз каршына
Килгән бер чыпчык.
Миңа кычкыра:
— Чык әле, ди, чык!

Алдый ул, беләм.
Гел шулай итә.
Йөгереп чыксам
Оча да китә.

Тәрбияче уенчык кошны читкәрәк алып куя.

Тәрбияче. Балалар, бу кош — чыпчык. Ул безгә күчтәнәчкә рәсемнәр алып килгән. Карагыз әле, бу рәсемдә сез нәрсә күрәсез? (*Әтәч.*) (Активлаштыру.) Дөрес, балалар, бу — әтәч. Ул кайда яши? (*Авылда, ишегалдында.*) Әйе, ул ишегалдында яши. Балалар, әтәч ничек кычкыра? (*«Кикрикүк!»*) (Активлаштыру.) Әмир, әйт әле: бу рәсемдә син нәрсә

күрәсең? (*Тавык.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Тавык кайда яши? (*Ишегалдында.*) Әмир, тавык ничек кычкыра? (*«Кыт-кытак!»*) (Активлаштыру.) Балалар, тавык безгә нәрсә бирә? (*Йомырка.*) (Активлаштыру.) Гадел, кил әле, бу рәсемдә син нәрсә күрәсең? (*Каз.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Гадел, каз кайда яши? (*Ишегалдында.*) (Активлаштыру.) Каз ничек кычкыра? (*«Ка-ка-ка!»*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, тавык, әтәч, каз — болар йорт кошлары, чөнки алар авылда, ишегалдында яшиләр. Әйдәгез, бергә кабатлыйбыз: «йорт кошлары». (Активлаштыру.) Булдырдыгыз, балалар! Сез йорт кошларын яхшы беләсез. Мин сезгә хәзер башка рәсемнәр күрсәтәм. Бу рәсемнәрдә дә кошлар, ләкин алар — безнең янга очып килә торган кошлар. Без аларны көн саен сезнең белән бергә ашатабыз, җимлекләргә җим сибәбез. (Активлаштыру.) Алинә, әйт әле: бу нинди кош? (*Күгәрчен.*) Күгәрчен нинди тавыш чыгара? (*«Гөр-гөр!»*) Әйе, күгәрчен гөрли. Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк: «гөрли». (Активлаштыру.) Әминә, ә бу нәрсә? (*Чыпчык.*) (Активлаштыру.) Ул ничек кычкыра? (*«Чырык-чырык!»*) Әйе, «чырык-чырык!» дип чыркылдый. Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк: «чыркылдый». (Активлаштыру.) Чыпчык йөриме, сикерәме? (*Сикерә.*) (Активлаштыру.) Әмин, син әйт әле: бу нинди кош? (*Карга.*) Ул ничек кычкыра? (*«Кар-кар!»*) Әйе, «кар-кар!» дип каркылдый. Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк: «каркылдый». (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Булдырдыгыз! Балалар, кошларның нәрсәләре бар? Бу нәрсә? Әйе, бу — кошның башы. Башында нәрсәләре бар? Айгөл, күрсәт әле. Дөрес, аның күзләре бар. (Активлаштыру.) Тагын томшыгы бар. (Активлаштыру.) Томшыгы белән кош җим чүпли. (Активлаштыру.) Балалар, күрсәтегез әле, кошлар ничек җим чүплиләр? (Балалар кошларның ничек итеп җим чүпләүләрен күрсәтәләр.) Кошларның тагын нәрсәсе бар? (*Гәүдәсе.*) (Активлаштыру.) Кошларга очар өчен нәрсә кирәк? (*Канатлар.*) (Активлаштыру.) Дөрес, балалар, кошларның канатлары бар. Әйдәгез, кошлар кебек, канатларны җилпеп «очыгыз» әле. Балалар, ә кайсы кошлар сикерә? (*Чыпчык.*) (Активлаштыру.) Ә кайсы кошлар йөри? (*Күгәрчен, карга.*) (Активлаштыру.) Балалар, әйдәгез, бер уен уйнап алабыз. Сез кошлар булырсыз. (Тәрбияче балаларга кошлар төшерелгән битлекләр тарата.) Күгәрченнәр кебек йөрегез. Ә хәзер чыпчыклар кебек сикерегез. Күгәрченнәр һәм чыпчыклар канатларын җилпеп очалар, томшыклары белән җим чүплиләр. Менә зур кош — карга очып килде: «кар-кар!» Карга кыч-

кыргач, күгәрченнәр һәм чыпчыклар үз ояларына качтылар. (Урындыкларга утыралар.) Күгәрченнәр һәм чыпчыклар бик җитез булдылар. Карга аларны тота алмады.

Уен ике-өч тапкыр кабатлана.

## Тема. ЮЛНЫ ЧИСТАРТАБЫЗ

**Бурычлар:**

1) балаларның кыш һәм кыш көне башкарыла торган хезмәт күнекмәләре турындагы белемнәрен формалаштыру, көрәк белән эшләргә өйрәтү, ишегалды җыештыручы хезмәте белән таныштыру; балаларның сүз байлыгын арттыру һәм активлаштыру, аерым сүзтезмәләрне (*зур көрәк, кечкенә көрәк, ак кар, күп кар, әз кар*) дөрес әйтергә өйрәтү;

2) хезмәт күнекмәләрен, кеше хәрәкәтләрен имитацияләү осталыгын үстерү;

3) зурларга ярдәм итү һәм гади хезмәт хәрәкәтләре үтәү теләге тәрбияләү.

**Җиһазлар:** зур көрәк, кечкенә көрәкләр.

### Эшчәнлек барышы.

Тәрбияче. Балалар, без хәзер сезнең белән саф һавага чыгабыз. Урамда кыш. Сез урамда нәрсәләр күрәсез? (*Кар.*) Әйе, балалар, бөтен җирне кар каплаган. Урамда йөрергә уңайлы булсын өчен, җирне кардан чистартырга кирәк.

Йомшак кына кар яуды,
Бөтен җирне каплады.
Ап-ак булды урамнар,
Ап-ак булды түбәләр.

Безнең ишегалдын кардан Марат абый чистарта. Балалар, әйдәгез, Марат абыйга ярдәм итик. Юлларны кардан нәрсә белән чистартабыз? (*Көрәк.*) (Активлаштыру.) Дөрес, балалар, менә сезгә көрәкләр. (Көрәкләр тарата.) Балалар, әйдәгез, Марат абый белән исәнләшик. (Активлаштыру. Ишегалды җыештыручы балалар белән исәнләшә һәм кар көрәвен дәвам итә.) Балалар, карагыз әле, Марат абый нәрсә эшли? (*Кар көри.*) Марат абый кар көри. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, Марат абый карны нәрсә белән көри? (*Көрәк белән.*) Дөрес, Марат абый көрәк белән кар көри. (Активлаштыру.) Балалар, Марат абыйның көрәге кечкенәме, зурмы? (*Зур.*) Әйе, Марат абыйның көрәге зур. (Активлаштыру.) Марат абыйның көрәге зур булгач, аның көрәгенә

кар күп сыя. Әйдәгез, кабатлыйк: «кар күп». (Активлаштыру.) Балалар, көрәкләрегезгә кар алып карагыз әле. Сезнең көрәкләргә кар күп сыямы, әллә әзме? (*Әз.*) Әйе, әз кар сыя. (Активлаштыру.) Балалар, сезнең көрәкләр зурмы, кечкенәме?(*Кечкенә.*) (Активлаштыру.) Әйе, сезнең кулларда кечкенә көрәкләр. (Активлаштыру.) Кечкенә көрәкләргә кар әз сыя. Көрәкләрегез кечкенә булса да, алар белән дә кар көрәп була. Менә шулай. (Тәрбияче кар көрәп күрсәтә.) Әйдәгез, Марат абыйга кар көрәргә булышабыз, юлны чистартабыз. Балалар, сез нәрсә эшлисез? (*Кар көрибез.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Миндә зур көрәк, ә сездә кечкенә көрәкләр. (Активлаштыру.) Карны көрәк белән менә шулай алабыз һәм читкәрәк атабыз. Булдырдыгыз! Марат абый, карагыз әле, безнең балалар юлны ничек яхшы итеп көриләр! (Ишегалды җыештыручы балаларның эшен бәяли һәм мактау сүзләре әйтә.) Әйдәгез, көрәкләрне куябыз. Сез арыгансыздыр, ял итеп алыйк. Юл бик чистарды, булдырдыгыз! Сез чистарткан юлда куышлы уйнап алыйк.

## *Җиденче бүлек.* ӘТИЛӘР ҺӘМ ӘНИЛӘР, БАБАЙЛАР ҺӘМ ӘБИЛӘР

### Тема. «ШУНДЫЙ УК ПРЕДМЕТНЫ ТАП» ДИДАКТИК УЕНЫ

**Бурычлар:**

1) үз фикерләрен грамматик яктан дөрес итеп ике-өч сүздән торган гади җөмләләр белән белдерергә өйрәтү, гомумиләштерү күнекмәсе булдыру, предметларны чынбарлыкта һәм рәсемдә танырга өйрәтү, предметларның билгеләнешен ачыклау, сүз байлыгын арттыру һәм активлаштыру;

2) тәрбияче сорауларына гади җөмлә белән тулы җавап бирү осталыгын, игътибарны, сенсор тою сәләтен үстерү;

3) гигиена күнекмәләре тәрбияләү.

**Җиһазлар:** сабын, теш щёткасы, теш пастасы, сөлге, кыстыргычлар, губка, тарак, су белән таз, кувшин, мольберт, рәсемнәр, курчак күлмәге, Мәрьям-курчак.

**Эшчәнлек барышы.**

Т ә р б и я ч е . Балалар, безгә кунакка Мәрьям-курчак килгән. Әйдәгез, аның белән исәнләшик әле. (Активлаштыру.) Балалар, Мәрьям бик матур, чиста күлмәк киеп килгән. Мәрьямнең иртән йокыдан торгач сезнең нәрсәләр эшләгәнегезне беләсе килә. Әйдәгез, аңа бу турыда сөйлик. Алинә,

кил әле. Алинә, син иртән йокыдан торгач юынасыңмы? (*Юынам.*) (Активлаштыру.) Юынгач нәрсә эшлисең? (*Чәч тарыйм, киенәм.*) (Активлаштыру.) Әйдә, әйт әле: «Мин чәч тарыйм». (Активлаштыру.) Әмир, әйтче: «Мин киенәм»,— диген. (Активлаштыру. Тәрбияче өйрәткән үрнәк буенча балалар җөмләләрне кабатлыйлар.)

Без иртә-кич юынабыз
Һәм шулай чистарабыз.
Теш пасталары, щёткаларыбыз,
Хуш исле сабын,
Сөлге яшәсен!

Балалар, карагыз әле, Мәрьям безгә нәрсәләр алып килгән? (Өстәлдә алдан әзерләп, салфетка белән каплап куйган предметларны күрсәтә.) Алия, кил әле, әйт: монда нәрсәләр бар? (*Сабын, теш щёткасы, теш пастасы, сөлге.*) (Активлаштыру.) Кәрим, ә син тагын нәрсәләр күрәсең?(*Губка, тарак.*) (Активлаштыру. Тәрбияче ике-өч баладан сорый һәм «Монда сабын (тарак, губка, теш пастасы, теш щёткасы, сөлге) бар» дигән җавап бирүләренә ирешә.) Йосыф, кил әле, кулыңа сабын ал. Сабын ни өчен кирәк? Әйе, сабын юыну өчен кирәк. (Шул рәвешле, өстәлдә булган юыну предметларын карыйлар һәм нәрсә өчен кирәклеген әйтәләр. Активлаштыру.) Балалар, әле монда рәсемнәр дә бар. Әминә, таракны рәсемнән күрсәт әле. Тарак ни өчен кирәк?(*Чәч тарарга.*) (Шул рәвешле, тәрбияче балаларны һәр предметны һәм аның нәрсә өчен кулланылуын әйттерә, рәсемнән табып күрсәттерә.) Булдырдыгыз, балалар! Балалар, Мәрьям үзенең салган киемнәрен юарга алып килгән. Аның хәзер кигән киемнәре бик матур, чиста. Әйдәгез, аның салган киемнәрен юып куйыйк, ул сөенсен. Балалар, бу нәрсә? (*Таз.*) (Активлаштыру.) Әйдәгез, тазга кувшиннан су салабыз. Булат, кулыңны тыгып кара әле: су салкынмы, җылымы? (*Җылы.*) (Активлаштыру.) Айгөл, урындыктагы киемне миңа бир әле. Син миңа нәрсә бирдең?(*Күлмәк.*) (Активлаштыру.) Мәрьямнең күлмәген юыйк. Күлмәкне юар өчен нәрсә кирәк? (*Сабын.*) (Активлаштыру.) Гөлназ, миңа сабынны бир әле. Мин күлмәкне суда чылатам һәм күлмәкне сабынлыйм. Мин нәрсә эшлим? (*Сабынлыйм.*) (Активлаштыру.) Дөрес, күлмәкне сабынлыйбыз һәм юабыз. Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк: «Күлмәкне сабынлыйбыз һәм юабыз». (Активлаштыру.) Ә хәзер, балалар, бу суны түгәбез дә чиста су салабыз. Гөлнур, су салкынмы, җылымы? (*Су җылы.*) (Активлаштыру.) Хәзер Мәрьямнең киемнәрен чиста

суда чайкыйбыз. Сәлим, Мәрьямнең күлмәген миңа бир әле. Син миңа нәрсә бирдең? (*Күлмәк.*) (Активлаштыру. Тәрбияче, шул рәвешле, шул эзлеклелектә курчакның носкиларын юа.) Балалар, ә хәзер курчакның киемнәрен киптерергә элеп куябыз. Моның өчен безгә кер кыстыргычлары кирәк. Менә алар — кер кыстыргычлары. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Фәнил, бу кер кыстыргычы нинди төстә? (Тәрбияче яшел кер кыстыргычы күрсәтә.) (*Яшел.*) Әйе, яшел кер кыстыргычы. (Активлаштыру.) Алсу, миңа кызыл кер кыстыргычын бир әле. Бу кер кыстыргычы нинди төстә? (*Кызыл.*) Әйе, кызыл кер кыстыргычы. (Активлаштыру. Төсләрне аеруда кыенлык кичерүче балалар белән эш оештырыла.) Булдырдыгыз, балалар! Без бик күп эшләдек. Мәрьям безгә рәхмәт әйтә.

## Тема. МАШИНА ҺӘМ САМОЛЁТ

**Бурычлар:**

1) балаларны уенчыкларның өлешләрен, төсен, формасын аерырга һәм атарга өйрәтү; исемнәрне сыйфатлар белән яраклаштыру күнекмәләре формалаштыруны дәвам итү; [у] сузык авазын әйтүдә күнектерү, сүзлекне активлаштыру; уенчыклар белән таныштыруны дәвам итү;

2) балаларның *нинди? кайда? нәрсә ташый?* сорауларына төзек гади җөмләләр белән җавап бирү осталыгын, игътибарын үстерү;

3) шофёр, очучы һөнәрләренә хөрмәт тәрбияләү.

**Җиһазлар:** уенчык йөк машинасы һәм самолёт, шакмаклар.

### Эшчәнлек барышы.

Тәрбияче шакмаклар тутырылган уенчык йөк машинасы һәм самолёт әзерли, аларның өстен каплап, өстәлгә куя.

Тәрбияче. Балалар, бу нәрсә? (*Машина.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, карагыз әле, машина нәрсәләр алып килгән? (*Шакмаклар.*) (Активлаштыру.) Балалар, бу нинди машина? (*Йөк машинасы.*) (Активлаштыру.) Әйе, йөк ташый торган машина «йөк машинасы» дип атала. (Активлаштыру.) Йөк машинасы яңа шакмаклар алып килгән. Айдар, шакмакларны нинди машина алып килгән? (*Йөк машинасы.*) (Активлаштыру.) Балалар, әйдәгез, машинаны карыйк әле, аның нәрсәләре бар икән? Дамир, әйт әле: бу нәрсә? (*Кабина.*) (Активлаштыру.) Кабинада нәрсә бар? (*Руль.*) (Активлаштыру.) Кабинада кем утыра? (*Шофёр.*) (Активлаштыру.) Әйе, машинаны шофёр йөртә. (Индивидуаль һәм күмәк

кабатлаулар.) Кабина нинди төстә? (*Зәңгәр.*) (Активлаштыру.) Булдырдың, Дамир! Кәрим, кил әле, машинаның кузовын күрсәт әле. Бу нәрсә? (*Кузов.*) (Активлаштыру.) Анда нәрсәләр төялгән? (*Шакмаклар.*) (Активлаштыру.) Кузов нинди төстә? (*Сары.*) (Активлаштыру.) Булдырдың! Рамил, кил әле, машинаның тәгәрмәчләрен күрсәт әле. Тәгәрмәчләр кечкенәме, зурмы? (*Зур.*) Әйе, йөк машинасының тәгәрмәчләре зур. Бу тәгәрмәчләр тагын нинди? (*Зур, түгәрәк.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Әйе, балалар, машинаның кабинасы, руле, кузовы һәм зур түгәрәк тәгәрмәчләре бар. Булдырдыгыз! Балалар, без хәзер сезнең белән йөк машинасын бушатабыз. Мин сезгә шакмакларны күрсәтәм, ә сез аларның нинди төстә икәнлеген әйтерсез. (Әлеге эш төсләрне кыенлык белән аеручы балалар белән эшләнә.) Алинә, бу нинди төстәге шакмак? (*Бу шакмак кызыл төстә.*) (Активлаштыру. Эш шул рәвешле дәвам итә.) Менә, балалар, без йөк машинасын бушаттык. (Активлаштыру.) Балалар, без нәрсә эшләдек? (*Машинаны бушаттык.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, машина китә. Ул нәрсә эшли? (*Китә.*) (Активлаштыру.) Машина киткәндә кычкырта: «Би-биип, би-биип!» Машина ничек кычкырта? (*«Би-биип, би-биип!»*) (Активлаштыру.) Балалар, машина белән саубуллашыйк. (Активлаштыру.)

Балалар, монда тагын нәрсәдер бар. Бу нәрсә? (*Самолёт.*) (Активлаштыру.) Әйдәгез, самолётның нәрсәләре бар икән, карыйк әле. Камил, кил әле. Самолёт кечкенәме, зурмы? (*Зур.*) (Активлаштыру.) Балалар, менә бу — самолётның кабинасы, анда очучы утыра. Самолётның канатлары бар. Ә монысы — самолётның койрыгы. (Активлаштыру.) Ринат, бу нәрсә? (*Кабина.*) Самолётның канатларын күрсәт әле. (Активлаштыру.) Ә бу нәрсә? (*Койрыгы.*) (Активлаштыру.) Самолётны кем йөртә? (*Очучы.*) (Активлаштыру.) Булдырдың, Ринат! Балалар, самолёт «у-у-у!» дип оча. (Самолётны «очыртып» күрсәтә.) Илһам, самолёт очканда, нинди тавыш чыгара? (*«У-у-у!»*) (Активлаштыру.) Балалар, менә самолёт очып китте. Самолёт нәрсә эшләде? (*Очып китте.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Ә хәзер, балалар, самолёт яңадан очып килде. Самолёт нәрсә эшләде? (*Очып килде.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, әйдәгез, самолётлар булып уйнап алыйк. Сез самолётлар булырсыз. Кулларны ян-якка канатлар кебек җәябез һәм самолёт тавышы чыгарып «очып китәбез» һәм «очып киләбез». (Уен берничә тапкыр кабатлана.)

## Тема. МӘРЬЯМНЕ ТАБЫЙК

**Бурычлар:**

1) балаларны *кайда? кая?* сорауларына җавап бирергә; сөйләмдә *өстенә, артына, астына* сүзләрен кулланырга өйрәтү;

2) балаларның игътибарын, хәтерен үстерү;

3) уен белән кызыксыну тәрбияләү.

**Җиһазлар:** Мәрьям-курчак, курчакның йорт җиһазлары (карават, өстәл).

### Эшчәнлек барышы.

Тәрбияче. Балалар, безгә кунакка Мәрьям-курчак киләсе иде. Ул әле килеп җитмәгән. Кая икән ул? Бәлки, ул бездән качкандыр?Аны эзләргә кирәк.

Мәрьям качышлы уйный.
Каян табарга аны?
Карават астын карадык,
Ишек артын карадык,

Өстәл астын карадык —
Һич кенә дә тапмадык.
Мәрьям, Мәрьям, син кайда?
Кая китеп югалдың?

Мәрьям качкан җирдән килеп чыга.

Тәрбияче. Балалар, Мәрьям нинди уен уйнады? (*Качышлы.*) (Активлаштыру.) Балалар, без Мәрьямне карават, өстәл астыннан, тагын ишек артыннан эзләдек. (Активлаштыру.) Балалар, без Мәрьямне таба алдыкмы? (*Юк.*) Мәрьям, син кайда?(*Мин монда.*) Әйдәгез, Мәрьямне тагын эзлик әле. (Тәрбияче балаларны Мәрьям качкан урынга алып бара. Мәрьям карават астында утыра.) Менә ул Мәрьям. Балалар, Мәрьям кайда? (*Карават астында.*) Уен дәвам итә. Шул рәвешле, тәрбияче Мәрьямне качыра, ә балалар тәрбияче белән бергә «Мәрьям кайда?» соравына «өстәл астында», «ишек артында» дип җавап бирәләр. Әйдәгез, балалар, Мәрьям белән тагын бер тапкыр качышлы уйныйбыз. Уен почмагына килегез әле. (Балалар уен почмагында идәндәге паласка утыралар.) Балалар, Мәрьям кача, ә без аны эзлибез. Күзләрегезне йомыгыз әле. (Тәрбияче Мәрьямне ишек артына качыра.) Күзләрегезне ачыгыз! Азалия, Мәрьям кая качты икән, эзләп кил әле. Булдырдың, Азалия, Мәрьямне таптың. Ул кая

качкан иде? (*Ишек артына.*) (Активлаштыру.) Күзләрегезне йомыгыз әле. (Тәрбияче Мәрьямне өстәл астына качыра.) Күзләрегезне ачыгыз! Алмаз, ә хәзер Мәрьям кая качты, эзләп кил әле. Булдырдың, Алмаз, Мәрьямне таптың. Ул кая качкан иде? (*Өстәл астына.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, Мәрьям тагын кача, ә без аны эзлибез. Күзләрегезне йомыгыз әле. (Тәрбияче Мәрьямне карават астына качыра.) Күзләрегезне ачыгыз! Дамир, Мәрьям кая качты? (*Карават астына.*) (Активлаштыру.) Булдырдыгыз, балалар, сез Мәрьямне карават астыннан, ишек артыннан, өстәл астыннан таптыгыз. Ә хәзер без дә качышлы уйнап алыйк.

## Тема. КЫНА ГӨЛЕ

**Бурычлар:**

1) балаларны бүлмә гөле — кына һәм аның өлешләре белән таныштыру; *сабак, яфрак, чәчәк* сүзләре хисабына сүзлекләрен активлаштыру;

2) балаларның зурлар белән аралашуына, аларны аңлауларына ирешү; күзәтүчәнлекләрен, игътибарларын үстерү;

3) бүлмә гөлләренә карата кызыксынучанлык, аларны карау теләге тәрбияләү.

**Җиһазлар:** кына гөле (бальзамин), төбен йомшарту өчен таякчыклар, сусипкеч; кояш, болыт рәсемнәре.

### Эшчәнлек барышы.

Тәрбияче. Балалар, без сезнең белән әниләр бәйрәменә шигырьләр өйрәнгән идек. Алия, әйдә, сөйлә әле шигыреңне.

Алия.

Бик зур үстем инде мин,
Әниемә булышам:
Гөлләренә су сибәм.
Тәрәз төбендә гөлем
Ал чәчәккә күмелгән!

Тәрбияче. Булдырдың, Алия. Балалар, әйдәгез әле, тәрәзә төбендә үсеп утыра торган матур чәчәкле гөл карыйк. Кызыл чәчәкле гөлне күрсәтегез әле. Булдырдыгыз! (Тәрбияче кызыл чәчәкле кына гөлен, тәрәзә төбеннән алып, өстәлгә куя.) Балалар, карагыз әле, нинди матур гөл! Аның яшел яфраклары күпме? (*Күп.*) Кызыл чәчәкләре күпме? (*Күп.*) (Активлаштыру.) Кына гөленең яфраклары һәм чәчәкләре сабагында үсә. (Активлаштыру.) Алсу, кил әле, гөлнең са-

багын күрсәт. Бу нәрсә? (*Гөлнең сабагы.*) (Активлаштыру.) Ә бу нәрсә? (*Гөлнең яфрагы.*) Яфрак нинди төстә? (*Яшел.*) Әйе, яшел яфрак. (Активлаштыру.) Дамир, гөлнең чәчәген күрсәт әле. Ул нинди төстә? (*Кызыл.*) Әйе, кызыл чәчәк. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Бу төсне тагын ал дип тә әйтәләр. (Активлаштыру.) Балалар, бу гөлнең исеме — кына. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Ринат, гөлнең исеме ничек? (*Кына.*) (Активлаштыру.) Балалар, гөл матур булып үссен өчен, аның төбен менә мондый таякчык белән йомшарталар. Менә сезгә таякчыклар. Кәрим, кил әле, гөлнең төбен син йомшартып кара. Син нәрсә эшлисең? (*Йомшартам.*) (Активлаштыру.) (Әлеге йомышны тәрбияче берничә балага куша.) Балалар, гөл матур булып үссен өчен, аңа су сибәләр. Суны сусипкечтән сибәргә кирәк. Балалар, карагыз әле, мин гөлгә су сибәм. Әйдәгез, кабатлыйк әле: «Гөлгә су сибәм». (Активлаштыру.) Балалар, гөлнең төбен йомшарттык, аңа су сиптек, ул бик сөенде. Матур булып үссен өчен, аңа тагын кояш яктысы кирәк. Шуңа күрә гөлне тәрәзә төбенә куябыз. Балалар, гөл безгә рәхмәт әйтә. Әйдәгез, хәзер уен уйнап алабыз. Уен «Кояш һәм болытлар» дип атала. Мин сезгә кояш рәсемен күрсәткәч, сез йөрисез, уйныйсыз. Ә болыт рәсемен күрсәткәч, йөгереп барып, урындыкларга утырасыз.

## *Сигезенче бүлек.* ХАЛЫК ИҖАТЫ

### Тема. БАРМАК УЕНЫ БЕЛӘН ТАНЫШТЫРУ. «ЙОРТ ХАЙВАННАРЫ» УЕН КҮНЕГҮЕ

**Бурычлар:**

1) халык авыз иҗаты белән таныштыруны дәвам итү, катлаулы булмаган фразаларны куллануда күнектерү, йорт хайваннарының исемнәрен ныгыту; *мөгри, кычкыра, мияулый, өрә* фигыльләре хисабына балаларның сүзлеген активлаштыру; [м], [у] авазларын дөрес әйтергә өйрәтү;

2) хәтерне, кабул итү сәләтен, авазларны әйтү күнекмәләрен үстерү;

3) халык авыз иҗатына, йорт хайваннарына карата кызыксыну тәрбияләү.

**Җиһазлар:** уенчык эт, песи, сыер, кәҗә.

**Эшчәнлек барышы.**

Тәрбияче. Балалар, кулларыгызга карагыз әле. Менә нинди безнең куллар: үзләре йомшак, үзләре эшлиләр. Алар ашарга пешерәләр, идән юалар, уйныйлар! Балалар,

кулларда бармаклар бар. Күрсәтегез әле бармакларыгызны. Әйе, менә алар.

Бармак, бармак,
Кайда булдың?
«Бу абый белән
Урманда булдым.
Бу абый белән
Кырда йөгердем.
Бу абый белән
Ботка ашадым.
Бу энем белән
Җыр җырладым».

Тәрбияче ике тапкыр сөйли.

Балалар, бармак кайда булган? Әйе, бу абый белән урманда булган. Бу абый белән кырда йөгергән. Бу абый белән ботка ашаган. Бу энесе белән җыр җырлаган. (Активлаштыру.)

Тәрбияче уенны тагын бер тапкыр уйнап карый, уенга балаларны да җәлеп итә.

Тәрбияче. Булдырдыгыз, балалар! Карагыз әле монда. (Тәрбияче өстәлгә йорт хайваннары: уенчык сыер, кәҗә, песи, этне куя.) Балалар, бу нәрсә? (*Сыер.*) (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар.) Балалар, сыер печән ашый. Сөт бирә. «Му-му!» — дип мөгри. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Бу нәрсә? (*Кәҗә.*) Кәҗә дә сөт бирә. Ләкин ул мөгри белми. Ул: «Меее-меее!» — дип кычкыра. Кәҗә ничек кычкыра? (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Менә песи дә килде. Карагыз әле, ул нинди матур! Ул сөт эчә. Балалар, песи сөтне теле белән ялап эчә. (Тәрбияче күрсәтә.) Песи мияуларга ярата: «Мияу-мияу!» Песи ничек мияулый? (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Менә эт тә килеп җитте. Эт сөяк кимерә. Эт нишли? (*Сөяк кимерә.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Ул: «Һау-һау-һау!» — дип өрә. Эт ничек өрә? (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Алсу, кил әле. Сыерны тап әле. Ул ничек мөгри? (Активлаштыру.) Әмир, кәҗәне күрсәт әле. Ул ничек кычкыра? (Активлаштыру.) Йосыф, этне күрсәт әле. Ул ничек өрә? (Активлаштыру.) Мәрьям, песине күрсәт әле. Песи ничек мияулый? (Активлаштыру.) Булдырдыгыз! Балалар, сыер, кәҗә, эт, песи — йорт хайваннары. Алар хуҗалары белән яшиләр. Хуҗалары алар турында кайгырталар, аларны ашаталар, алар яшәгән урынны җыештыралар. Без дә йорт хайваннарын яратабыз.

## Тема. «ЧУАР ТАВЫК» ӘКИЯТЕН УКУ

**Бурычлар:**

1) балаларны халык авыз иҗаты әсәрләре белән таныштыруны дәвам итү, әкиятне тыңлау теләге тудыру; *чуар, күкәй, алтын, гади, тычкан* кебек сүзләр хисабына балаларның сүзлеген баету;

2) тәрбияче башлаган җөмләне дәвам итү осталыгын, хәтерне, игътибарны, кабул итү сәләтен үстерү;

3) әкият персонажларына карата кызыксыну тәрбияләү.

**Җиһазлар:** «Чуар тавык» әкияте персонажларының контурлы сурәтләре, фланелеграф, сары төскә буялган зур йомырка.

### Эшчәнлек барышы.

Тәрбияче. Балалар, безгә кунакка Алсу килгән. Исәнме, Алсу!

Алсу. Исәнмесез, балалар!

Тәрбияче. Балалар, Алсу безгә әкиятләр китабы алып килгән. Ул миннән әкият укуымны сорый. Тыңлагыз әле, мин сезгә Чуар тавык турында әкият сөйлим. Яшәгән, ди, бер бабай белән әби. (Тәрбияче фланелеграфка әби белән бабайның сурәтләрен куя.) Беркөнне тавык йомырка салган. (Тәрбияче сары төскә буялган йомырканы балаларга күрсәтә.) Бу — гади йомырка түгел, алтын йомырка. Бабай йомырканы ватып караган — вата алмаган. Бер тычкан үтеп бара икән, аның койрыгы йомыркага тиеп киткән. (Тәрбияче фланелеграфта күрсәтә.) Йомырка тәгәрәп төшкән, урталайга ярылган, ди. Бабай да елый, әби дә елый икән. Ә Чуар тавык болай дигән: «Елама, бабай, елама әби! Сезгә мин тагын йомырка салырмын, алтынны түгел — гади йомырка!» Балалар, сезгә әкият ошадымы? Алсуга да әкият ошаган. Тагын бер тапкыр тыңлагыз әле. (Тәрбияче әкиятне тагын сөйли.) Балалар, миңа әкиятне сөйләргә ярдәм итегез әле. (Балаларны чакыра.) Яшәгән, ди... (*бер бабай белән... әби*). Аларның булган ... (*чуар тавыклары*). Чуар тавык ... (*күкәй салган*). Гадине түгел ... (*алтынны*). (Тәрбияче җөмләне башлый, балалар дәвам итәләр.) Балалар, чуар тавык әби белән бабайны ничек юаткан? Кил әле, Мәрьям, син әйтеп кара әле. (Шулай итеп, фразаны дүрт-биш баладан кабатлата.)

# *Тугызынчы бүлек.* ЯЗ

## Тема. БҮЛМӘ ГӨЛЛӘРЕ (ФИКУС, ЯРАН)

**Бурычлар:**

1) балаларның гади сорауларга җавап бирү осталыгын камилләштерү, бүлмә гөлләренең өлешләрен өйрәтү, аларның сыйфат билгеләрен белдерә торган сүзләр хисабына сүзлекне баету;

2) гөлләр белән кызыксынуларын үстерү;

3) гөлләрне караганда, өлкәннәргә ярдәм итү теләге тәрбияләү.

**Җиһазлар:** бүлмә гөлләре: фикус, яран; сусипкеч, йомшак чүпрәк, матрёшка.

### Эшчәнлек барышы.

Тәрбияче балаларны өстәл янына чакыра. Өстәлдә фикус һәм яран гөлләре.

Тәрбияче. Яз җитте. Кояш елмая. Бүлмә гөлләре дә кояшка таба үрелә. Балалар, карагыз әле, бу нәрсәләр? (*Бүлмә гөлләре.*) Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: «бүлмә гөлләре». (Тәрбияче фикуска күрсәтә.) Балалар, бу — фикус. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Фикус кечкенә агачка охшаган. Балалар, карагыз әле, бу нәрсә? (Тәрбияче гөлнең сабагына күрсәтә.) (*Сабак.*) Әйе, бу — сабак. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, фикусның сабагы кыскамы, әллә озынмы? (*Озын.*) (Активлаштыру.) Сабак нинди төстә? (*Яшел.*) Әйе, сабак яшел. (Кабатлаулар.) Илдар, фикусның яфрагын күрсәт әле. Илдар, син нәрсә күрсәттең? (*Яфрак.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Фикусның яфраклары нинди? (*Зур, киң.*) (Активлаштыру.) Фикусның яфраклары нинди төстә? (*Яшел.*) Әйе, яфраклары яшел. (Кабатлаулар.) Балалар, карагыз әле, яфракларга тузан утыра, шуңа күрә аларны сөртергә кирәк. Карагыз әле, мин яфрактагы тузанны менә шулай сөртәм. (Тәрбияче күрсәтә.) Сул кулымны яфракның астына куям, уң кулым белән, сак итеп, яфракны сөртәм. Айгөл, син дә яфракның тузанын сөрт әле. Балалар, Айгөл нәрсә эшли? (*Яфракның тузанын сөртә.*) Булдырдың, Айгөл. Балалар, карагыз әле, яфраклар чиста, алар кояш нурында ялтырыйлар! Балалар, яфраклар нинди? (*Чиста.*) Әйе, яфраклар чиста булсын өчен, аларны сөртеп торырга кирәк. (Тәрбияче яран гөлен ала.) Балалар, бу — яран гөле. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Яранның нәрсәләре бар? (Тәрбияче яранның яфрагына, сабагына, чәчәкләренә күрсәтә.) Әйе, яранның сабагы, яфраклары, чәчәкләре бар. (Активлаштыру.) Балалар, яранның сабагы озынмы, кыскамы? (*Кыска.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Сабак нинди төстә? (*Яшел.*) (Активлаштыру.) Әйе, сабак яшел. Яранның яфраклары зурмы, кечкенәме? (*Кечкенә.*) Яфраклар нинди төстә? (*Яшел.*) Әйе, яфраклар яшел. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, карагыз әле, яран чәчәк ата. Аның чәчәкләре нинди төстә?

(*Кызыл.*) Яран гөле бик матур. Чәчәкләре күп, безне сөендерә. Яранны иснәп карагыз әле, ул хуш исле. (Тәрбияче гөлне балаларга иснәтеп карый.) Яранның исе нинди? (*Хуш исле.*) Бергәләп кабатлыйк әле: «хуш исле». Балалар, гөлләр үссен өчен, аларга су сибәргә кирәк. Әмир, мә сусипкечне, фикуска су сип. Булдырдың, Әмир! Мәрьям, ә син яран гөленә су сип. Булдырдың, Мәрьям! Балалар, Әмир белән Мәрьям нәрсә эшләделәр? (*Гөлләргә су сиптеләр.*) (Активлаштыру.) Балалар, күрәсезме, безгә матрёшка килгән. «Алсу, фикус гөлен күрсәт әле», — ди матрёшка. (Алсу фикус гөлен күрсәтә.) «Камил, бу гөл ничек атала?» — дип сорый матрёшка. (*Яран.*) «Йосыф, кайсы гөлнең яфраклары зур һәм киң?» — дип сорый матрёшка. (*Фикус.*) Балалар, матрёшка качты. Ул нинди гөл артына качты? (Уен ике-өч тапкыр кабатлана.) Балалар, матрёшка арыды. Әйдәгез, аны уенчыклар почмагына куйыйк. Гөлләрне дә табигать почмагына илтик. Алар кояшка үрелсеннәр. Матур булып үссеннәр. Без сезнең белән урамга чыгабыз.

## Тема. ЙӨК МАШИНАСЫ

**Бурычлар:**

1) машина, аның өлешләре турында белемнәрен арттыру, ком һәм аның үзлекләре белән таныштыру, машинаның төрен, өлешләрен, комның үзлекләрен белдерә торган исемнәр, сыйфатлар хисабына сүзлекне активлаштыру; [в], [п] авазларын дөрес әйтүдә күнектерү;

2) кызыксынучанлыкны, кабул итү сәләтен үстерү;

3) тәрбияче һәм яшьтәшләре белән аралашу теләге тәрбияләү.

**Җиһазлар:** 2 йөк машинасы, берсендә елга комы; елга комы салынган ике таз.

### Эшчәнлек барышы.

Ишек артында машина тавышы ишетелә.

Тәрбияче. Балалар, ишетәсезме, нәрсә тавышы ишетелә? Әйе, машина сигнал бирә. Безнең төркемгә нинди машина килде икән?! (Тәрбияче йөк машинасы алып керә.) Балалар, бу нәрсә? (*Машина.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Бу нинди машина: җиңел машинамы, әллә йөк машинасымы? (*Йөк машинасы.*) Балалар, бу — йөк машинасы. Йөк машинасы кибеткә товарлар илтә, төзелешкә кирпеч, ком ташый, балалар бакчасына ипи китерә, бакчадан

чүп чыгара. (Тәрбияче машинаның өлешләренә күрсәтә.) Балалар, машинаның нәрсәсе бар? Дөрес, йөк машинасының кабинасы, кузовы, тәгәрмәчләре, руле бар. (Күрсәтә.) Дамир, машинаның кузовын күрсәт әле. (Күрсәтә.) Син нәрсә күрсәттең? (*Кузов.*) Булдырдың! (Тәрбияче балаларны берәм-берәм чакыра һәм машинаның өлешләрен күрсәтеп әйтергә куша.) Балалар, машина барганда нинди тавыш чыгара? Тыңлап карагыз әле. Әйе, машина барганда «в-в-в» дигән тавыш чыгара. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Машина ничек итеп сигнал бирә? (*«Би-биип! Би-биип!»*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, йөк машинасы зур, ул сигналны да каты итеп бирә. Тыңлагыз әле: «Би-биип!» (Тәрбияче машинаның сигналын гадәтигә караганда катырак итеп чыгара. Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, яз җитте, кояш җылыта. Без дә хәзер ишегалдында күбрәк уйныйбыз. Ишегалдында сез нәрсә белән уйнарга яратасыз? (*Ком белән.*) Йөк машинасы безнең мәйданчыкка ком алып килде. Карагыз әле. (Тәрбияче ком салынган икенче йөк машинасын күрсәтә.) Балалар, шофёр комны кая салган? (*Кузовка.*) (Активлаштыру.) Тотып карагыз әле, ком нинди? (*Җылы, коры.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар. Тәрбияче балаларны ком салынган таз янына чакыра.) Балалар, карагыз әле, ком нинди: юешме, корымы? (Активлаштыру.) Әйе, ком коры. Айгөл, комны учыңа ал әле. Менә шулай. Ком нишли? (*Ком сибелә, чәчелә.*) Әйе, ком коры, шуңа күрә ул сибелә, чәчелә. (Активлаштыру.) Коры комнан бернәрсә дә ясап булмый. Ком салынган йөк машинасын без урамга алып чыгарбыз, аның комын комлыкка аударырбыз. Сез ком белән уйнарсыз. Ә хәзер кулларны юарбыз.

## Тема. ЯЗГЫ УРМАНДА

**Бурычлар:**

1) *кайда? нинди?* сорауларына җавап бирергә өйрәтү; *өстә, агач төбендә* сүзләрен куллану хисабына сөйләмнең грамматик төзелешен камилләштерү; аваз ияртемнәрен дөрес әйтүдә күнектерү; [ш] авазының дөрес әйтелешен ныгыту, ел фасылларына бәйле табигатьтәге үзгәрешләр турында белемнәрен формалаштыруны дәвам итү;

2) балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерү;

3) табигать объектларына сакчыл караш тәрбияләү.

**Җиһазлар:** язгы урман күренешен сурәтләү өчен агачлар; агач башындагы тиен һәм куян рәсеме; җил тавышы аудиоязмасы.

**Эшчәнлек барышы.**

Т ә р б и я ч е . Балалар, без бүген сезнең белән язгы урманга барып кайтабыз. Барасыгыз киләме? Әйдәгез, «поезд»га утырып барыйк әле.

Тәрбияче — «паровоз», ә балалар «вагоннар» була. Тәрбияче җырлый, ә балалар аваз иялтемнәрен кабатлыйлар.

Алга таба барабыз: «Тип-тап-тап, тип-тап-тап!»
Гөрләп чаба паровоз: «Тип-тап-тап, тип-тап-тап!»
Ак төтен артта кала: «Пух-пах-пах, пух-пах-пах!»
Вагоннар җырлап чаба: «Ах-ох-ух, ах-ох-ух!»
Свисток яңгырап китә: «Пу-ту-ту, пу-ту-ту!»
Тавыш еракка китә: «У-у-у, у-у-у!»
Бик күп җирләрне үттек: «Чаң-чаң-чаң, чаң-чаң-чаң!»
Урманга да без җиттек: «Дың-дың-дың, дың-дың-дың!»
Зур паровоз уфылдый: «Пуф-пуф-пуф, пуф-пуф-пуф!»
Бүген бик арыдың, ди: «Уф-уф-уф, уф-уф-уф!»

Т ә р б и я ч е . Менә, балалар, без килеп җиттек. Без кая килдек? (*Урманга.*) (Активлаштыру.) Урманда нәрсәләр үсә? (*Агачлар үсә.*) (Активлаштыру. Тәрбияче урман рәсеме күрсәтә.) Балалар, урмандагы агачлар биекме? (*Биек.*) (Активлаштыру.) Әйдәгез, кулларны өскә күтәреп, биек агачларны күрсәтегез әле! Менә шулай. Бик яхшы. Балалар, агачларга карагыз әле. Агачларда нәрсәләр бар? (*Яфраклар.*) (Активлаштыру.) Яфраклар нинди төстә? (*Яшел.*) (Активлаштыру.) Әйе, яфраклар яшел төстә. Балалар, кыш көне агачларның яфраклары бар идеме? (*Юк.*) (Активлаштыру.) Кыш көне агачлар ял итәләр, ә яз көне уяналар. Яз көне яфраклар барлыкка килә. Балалар, әйдәгез, тыңлап карыйк әле. Менә җил исә, агачларның яфраклары селкенәләр һәм җырлыйлар: «ш-ш-ш». Яфраклар нишлиләр? (*Җырлыйлар.*) Ничек җырлыйлар? Әйдәгез, яфраклар кебек җырлап алыйк әле: «ш-ш-ш». (Балалар кабатлыйлар.) Балалар, урманда нинди җәнлекләр яши, беләсезме? (*Куян, тиен, бүре, аю* һ.б.) Бик дөрес. Җәнлекләр дә язга сөенәләр. Алар да урман буйлап йөриләр. Мин сезгә табышмаклар әйтәм, ә җавапларын бергәләп урманнан эзләрбез. Колагы озын, үзе йомшак, үзе куркак, урманда яши. (*Куян.*) Булдырдыгыз! Җавабын дөрес әйттегез. Куян кайда утыра? (*Агач төбендә.*) (Активлаштыру.) Балалар, ничек уйлыйсыз, куян ни өчен агач төбенә поскан икән? (*Бүредән курыккан. Яңгыр ява* һ.б.) Балалар, куян да, яз килүен белеп, тунын алмаштырган.

Кыш көне куянның туны нинди төстә иде? (*Ак.*) Әйе, ә хәзер аның туны соры төстә. Куян чык агач төбеннән, утырма анда. Балалар, әйдәгез, куянны чакырыйк әле: «Куян, кил монда!» Әйдә, куян, кил монда! Балалар белән уйнап алыйк.

Соры куян, йомшак куян
Безгә кунакка килгән.
Койрыгы кыска гына, (Күрсәтәләр.)
Колагы озын икән. (Күрсәтәләр.)
Әйдәгез, кунакны без
Бергәләшеп сыйлыйбыз. (Күрсәтәләр.)
Сикереп тә йөгереп, (Сикерәләр, йөгерәләр.)
Аның белән уйныйбыз.

Балалар, карагыз әле, монда да бер җәнлек бар. (Балаларның игътибарын агач башында утырган тиенгә юнәлтә.) Бу — тиен. (Активлаштыру.) Тиеннең өе кайда? (*Агач башында.*) (Активлаштыру.) Әйдәгез, тиеннең өен күрсәтегез әле. (Балалар кулларын өскә күтәрәләр.) Әйе, тиен агач башында яши. (Активлаштыру.) Балалар, тиен бик матур! Аның койрыгы йомшак, зур. Балалар, тиеннең койрыгы нинди? (*Йомшак, зур, матур.*) (Активлаштыру.) Тиеннең койрыгы озын. (Активлаштыру.) Балалар, тиеннең койрыгының озынлыгын куллар белән күрсәтик әле. (Ике кулның учларын кушып, кара-каршы якка аерып, озынлыкны күрсәтәләр.) Булдырдыгыз, балалар! Карагыз әле, тиен дә яз килгәнгә сөенә. Әйдәгез, без дә тиен белән бергә сөенеп сикереп алыйк. (Тәрбияче, ике кулын бөгеп, күкрәгенә таба кысып, озынлыкка сикереп күрсәтә.) Балалар, куяннарны, тиеннәрне яратырга, сакларга кирәк. Балалар, язгы урманда рәхәт булдымы? (Активлаштыру.) Әйе, язгы урманда бик рәхәт! Тик безгә инде бакчабызга кире кайтырга вакыт җитте. Әйдәгез, «поезд»га утырыгыз.

Тәрбияче — «паровоз», ә балалар «вагоннар» була. Тәрбияче җырлый, ә балалар аваз ияртемнәрен кабатлыйлар.

## Тема. БОЗАУ, БӘРӘН, КОЛЫН, КӘҖӘ БӘТИЕ, СЕЗ КАЙДА?

**Бурычлар:**

1) балаларның йорт хайваннары турындагы белемнәрен киңәйтү; *бозау, бәрән, колын, кәҗә бәтие* сүзләре хисабына сүзлекне

баету һәм активлаштыру, тәрбияче күрсәтмәләрен үтәү осталыгы формалаштыру;

2) игътибарны, хәтерне үстерү;

3) башкаларга ярдәм итү теләге, тыңлаучанлык, хайваннарга карата кайгыртучанлык тәрбияләү.

**Җиһазлар:** ширма, тартмага салынган уенчык сыер, сарык, ат, кәҗә, бозау, бәрән, колын, кәҗә бәтие; «Без атларны яратабыз» җырының аудиоязмасы.

### Эшчәнлек барышы.

Тәрбияче. Балалар, килегез әле монда. Бу нәрсә? (Тартма күрсәтә.) (*Тартма.*) (Активлаштыру.) Тартма эчендә нәрсәдер бар. Әйдәгез, карыйк әле, нәрсә бар икән? (Тәрбияче тартманы ача.) Балалар, тартма эчендә нәрсәләр бар соң? Айдар, бу нәрсә? (*Сыер.*) (Активлаштыру. Балалар һәрбер хайванны шулай атап чыгалар.) Балалар, хайваннар балаларын югалтканнар икән. Әйдәгез, аларны табарга булышыйк әле. Булышабызмы? (*Әйе.*) Урамда хәзер яз. Яз көне табигатьтә нинди үзгәрешләр була? (Активлаштыру.) Әйе, кояш җылыта, кар эри, яшел үләннәр чыга. Сыер, сарык, ат, кәҗә дә, яз килгәнен сизеп, үзләренең балаларын яшел чирәм ашарга алып бармакчы булганнар. Ә алар әниләрен көтеп тормаганнар, каядыр китеп югалганнар. Балалар, әниләргә әйтмичә генә китәргә ярыймы? (Активлаштыру.) Әниләргә әйтмичә, бер җиргә дә китәргә ярамый. Менә хәзер сыер, сарык, ат, кәҗә балаларын югалтканнар да елыйлар да елыйлар. Әйдәгез, аларга балаларын табарга булышабызмы? (*Әйе.*) Әйдәгез, хайваннарның балаларын эзләп карыйк әле, бәлки, табылырлар. Кая киткәннәр икән алар, әниләренә әйтмичә! Менә нинди тыңлаусызлар! (Тәрбияче һәм балалар бүлмә буйлап йөриләр һәм бозау, бәрән, колын, кәҗә бәтиен ширма артыннан табалар.) Менә алар! Сез адаштыгызмы? Әниләрегезне эзлисезме? Әниләрегезнең нәрсә икәнен әйтсәгез, балалар сезгә аларны табып бирерләр. Алмаз, кил әле, бозаудан сора әле, аның әнисе нәрсә икән? Алмаз, әйдә, бергәләп сорыйк: «Бозау, синең әниең бармы? Ул нәрсә?» (*Сыер.*) (Активлаштыру.) Бозау, син әниеңне ничек чакырасың? (*«Му-у-му-му!»*) Балалар, әйдәгез, бозау белән бергәләп аның әнисен чакырабыз. (*«Му-у-му-му!»*) Булдырдыгыз! Алмаз, хәзер бозау белән бергәләп кабатлагыз әле: «Му-у-у! Кайтсын минем бозау!» (Балаларны активлаштыру. Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар. Тәрбияче тартмадан сарыкны ала.) Балалар, бу нәрсә? (*Сарык.*) (Ак-

тивлаштыру.) Балалар, сарык: «Бә-ә, бә-ә! Тимәгез минем бәрәнгә!» — ди. Сарык нәрсә ди? (Активлаштыру.) Сарык нәрсә эзли? (*Бәрәнне.*) (Активлаштыру.) Монда тагын нәрсә бар әле? (Тартмадан атны ала.) Әйе, ат. Ул болай ди: «Миһа-һа-һай, колынкаем, кил монда!» Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле, бәлки, колын табылыр. (Активлаштыру. Тәрбияче тартмадан кәҗәне ала.) «Ми-ки-ки-ки, күрмәдегезме сез минем йонлач бәтине?» Әйдәгез, балалар, бергәләп кабатлагыз әле. (Активлаштыру.) Балалар, кәҗә нәрсә эзли? (*Кәҗә бәтиен.*) (Активлаштыру.) Балалар, әйдәгез, бозауны, бәрәнне, колынны, кәҗә бәтиен әниләре янына куйыйк. Кабат беркайчан да әниләрегез яныннан читкә китмәгез! Бозау, бәрән, колын, кәҗә бәтие, бүтән беркайчан да әниләрегезне югалтмагыз. Югалтмас өчен, әниләрне тыңларга кирәк. Балалар, сыер, сарык, ат, кәҗә һәм бозау, бәрән, колын, кәҗә бәтие сезгә рәхмәт әйтәләр. Сез аларга зур ярдәм иттегез, бер-берсен табарга булыштыгыз. Бозау, бәрән, колын, кәҗә бәтие табылдылар. Ә хәзер рәхәтләнеп уйнап алсак та ярый. «Без атларны яратабыз» уенын уйныйк әле.

Атларны без яратабыз,
Чистартабыз, ашатабыз.
И атым, атым, тукта,
Чиста су бирәм сиңа.

Атларны оста җигәбез,
Йөгәнләп тота беләбез.
И киттек без, атлылар,
Атлы кыю батырлар.

Афәрин, балалар! Сез бүген мине бик шатландырдыгыз. Сезгә дә шатлык-сөенечләр телим.

## *Унынчы бүлек.* ҖӘЙ

### Тема. БАЛАЛАР БАКЧАСЫ ИШЕГАЛДЫНДА

**Бурычлар:**

1) исемнәр, фигыльләр, сыйфатлар хисабына сүз байлыгын үстерү, фигыльләрне һәм сыйфатларны исемнәр белән яраклаштыруда күнектерү; балаларны бакча ишегалдында үсә торган үсемлекләр исеме белән таныштыруны дәвам итү, табигатьтәге сезонлы үзгәрешләр турында белемнәрен киңәйтү;

2) төсләрне, матурлыкны белдерүче сыйфатлар ярдәмендә сөйләм теле компонентларын үстерү;

3) табигать объектларына карата кызыксыну, хезмәткә хөрмәт тәрбияләү.

**Җиһазлар:** зур һәм кечкенә сусипкечләр.

**Эшчәнлек барышы.**

Тәрбияче. Балалар, бүген көн шундый матур, бөтен җир ямь-яшел. Әйдәгез, саф һавага чыгабыз.

Җәй, җәй, җәй килә,
Кояш елмаеп көлә.
Каеннар яфрак яра,
Үләннәр үсеп бара.

Балалар, карагыз әле, нинди матур үләннәр! Алинә, үлән нинди төстә? (*Яшел.*) (Активлаштыру.) Балалар, үләнне таптарга ярамый. Аны таптасаң, ул шиңә. Илназ, үләнне таптарга ярыймы? (*Юк.*) Ул таптагач нишли? (*Шиңә.*) (Активлаштыру.) Балалар, карагыз әле, бу үләннәр арасында нинди чәчәк үсә? (*Сары.*) (Активлаштыру.) Алсу, бу чәчәкнең исеме ничек? (*Тузганак.*) (Активлаштыру.) Балалар, безнең ишегалдында тагын нәрсәләр бар икән, карыйк әле. Монда агачлар да күп. Менә бу — каен агачы. Килегез әле, каенны тотып карагыз. Аның кәүсәсе ак, шома, ә яфраклары яшел. Кәрим, бу нинди агач? (*Каен.*) (Активлаштыру.) Аның нәрсәсе бар? (*Кәүсәсе.*) (Активлаштыру.) Каенның кәүсәсе нинди төстә? (*Ак.*) (Активлаштыру.) Булдырдың, Кәрим! Лилия, каен кәүсәсе кытыршымы, шомамы? (*Шома.*) (Активлаштыру.) Каен агачының яфраклары нинди төстә? (*Яшел.*) (Активлаштыру.) Булдырдыгыз, балалар! Безнең ишегалдында чәчәкләр дә үсә. Чәчәкләр чәчәклектә үсә. Алия, чәчәкләр кайда үсә? (*Чәчәклектә.*) (Активлаштыру.) Бу чәчәкләрнең исеме — лалә. (Активлаштыру.) Лалә чәчәкләре нинди төстә? (*Сары, кызыл.*) (Активлаштыру.) Кабатлагыз әле: кызыл, сары лалә чәчәкләре». (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, чәчәкләр матур булып үссен өчен, аларга су сибәргә кирәк. Менә сезгә сусипкечләр. Миндә зур сусипкеч. Миндә нинди сусипкеч? (*Зур.*) (Активлаштыру.) Ә сезнең сусипкечләр нинди? (*Кечкенә.*) (Активлаштыру.) Әйдәгез, чәчәкләргә су сибәбез. Алия дә сибә, Лилия дә сибә, Илназ да сибә һ.б. Булдырдыгыз, балалар! Иртәгә башка балалар су сибәрләр. Безнең мәйданчык бигрәк матур! Бар

дөнья яшел: үләннәр, агачлар. (Активлаштыру.) Матур кызыл, сары чәчәкләр үсә. (Активлаштыру.) Ә хәзер бер уен уйнап алабыз. Балалар, мин «каен янына» дигәч, сез каен янына йөгерегез, «чәчәклек янына» дигәч, чәчәклеккә таба йөгерегез.

Уен шул рәвешле дәвам итә.

## Тема. КЫЗЫКСЫНУЧАН ТЕЛ

**Бурычлар:**

1) балаларны [т], [д], [к], [қ] авазлары кергән аваз ияртемнәрен әйтергә өйрәтү; аваз ияртемнәрен калын һәм нечкә тавыш белән әйтүдә күнектерү; [т], [д], [к], [қ] авазларының сүзләрдә, фразаларда дөрес әйтелешенә ирешү;

2) балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын үстерү;

3) игътибарлылык тәрбияләү.

**Җиһазлар:** туп, уенчык аю.

### Эшчәнлек барышы.

Тәрбияче. Балалар, минем телем бик кызыксынучан. Ул авыздан чыгып карарга ярата. (Телен чыгарып күрсәтә.) Сез дә телегезне күрсәтегез әле! (Балалар телләрен күрсәтәләр.)

Әйдәгез, бер уен уйныйбыз. Зур сәгать «кылт-кылт, кылт-кылт» дип йөри. (Кул белән сәгать теле йөрешен күрсәтәләр. Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Кечкенә сәгать «келт-келт, келт-келт» дип йөри. (Активлаштыру.) Илгиз, зур сәгать ничек йөри? («*Кылт-кылт*».) (Активлаштыру.) Ә кечкенә сәгать ничек йөри? («*Келт-келт*».) Булдырдың! (Тәрбияче туп ала. Тупны идәнгә бәрә.) Тыңлагыз әле: туп «туп-туп» итә. (Активлаштыру.)

Туп-туп-тубыбыз,
Син безнең матурыбыз.

Алинә, туп нинди тавыш чыгара? («*Туп-туп*».) (Активлаштыру.) Аю «лап-лап» итеп йөри. (Активлаштыру.) Әйдәгез, аюлар булып күрсәтик әле: «лап-лап» итеп атлыйк. (Активлаштыру.) Быргы «ду-ду» дип уйный. (Быргы уйнаган хәрәкәт ясау.) Әйдәгез, быргыга өреп уйныйбыз. («*Ду-ду-ду!*») (Активлаштыру. Уен берничә тапкыр кабатлана.) Балалар, бүген сез сәгать тә, туп та, аю да, быргы да булып уйнадыгыз. Мин әйткәннәрне дөрес эшләдегез. Булдырдыгыз!

## Тема. ЗООПАРК

**Бурычлар:**

1) җылы якта яшәүче кайбер хайваннар белән таныштыру; сөйләмдә исемнәрне берлек һәм күплек санда дөрес кулланырга өйрәтүне дәвам итү;

2) сөйләшеп, әңгәмә корырга өйрәтү; кабул итү сәләтен, игътибарны үстерү;

3) җылы як хайваннарына карата сакчыл караш тәрбияләү.

**Җиһазлар:** уенчык филләр, жирафлар һәм фил, жираф рәсемнәре; аудиоязма.

### Эшчәнлек барышы.

*«Ашыгыгыз! Ашыгыгыз! Бары бездә генә,бары бер көн — зоопарк. Тиздән тамаша башлана!»* дигән аудиоязма яңгырый.

Тәрбияче. Балалар, ишеттегезме, күчмә зоопарк килә! Әйдәгез, карыйк әле. (Цирк артисты киеме кигән тәрбияче уенчык фил, жираф алып керә.) Балалар, бу нәрсәләр? (*Хайваннар.*) (Активлаштыру.) Балалар, без хайваннарны йөртергә чыгарыйк. Булат, менә бу җәнлекне ал әле. Бу нәрсә? (*Фил.*) Әйе, ул кечкенәме, зурмы? (*Зур.*) (Активлаштыру.) Аның нәрсәләре бар? (Тәрбияче филгә күрсәтә.) (*Башы.*) (Активлаштыру.) Башында нәрсәләре бар? (*Колаклары.*) (Активлаштыру.) Филнең колаклары кечкенәме, зурмы? (*Зур.*) (Активлаштыру.) Балалар, филнең борыны бик озын. Аны хортум дип атыйлар. Бергәләп кабатлыйк әле: «филнең хортумы». (Активлаштыру.) Булат, филнең хортумын күрсәт әле. Филнең тагын нәрсәләре бар? (*Гәүдәсе, койрыгы, аяклары.*) (Активлаштыру.) Филнең аяклары нечкәме, юанмы? (*Юан.*) (Активлаштыру.) Булдырдың! Айгөл, бу нәрсә? (Тәрбияче жирафка күрсәтә.) (*Жираф.*) (Активлаштыру.) Жираф кечкенәме, зурмы? (*Зур.*) Жирафның муены кыскамы, озынмы? (*Озын.*) (Активлаштыру.) Әйе, аның муены озын. (Активлаштыру.) Жирафның тагын нәрсәләре бар? (*Башы, колаклары, авызы, гәүдәсе, койрыгы, аяклары.*) (Активлаштыру.) Булдырдыгыз! Жираф һәм филне зоопаркта гына күрергә мөмкин. Балалар, бу җәнлекләр барысы да җылы якта яшиләр. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Ә хәзер бер уен уйныйбыз. (Тәрбияче бүлмәнең бер урынына бер жираф, икенче бер урынына күп жирафлар; бер фил, икенче бер урынга күп филләр куя.) Мин «жираф» дигәч, сез жираф янына килегез. Жираф. (Балалар бер жираф янына киләләр.) Бу нәрсә? (*Жираф.*) (Активлаштыру.) Мин «жирафлар» дигәч, сез жирафлар янына килегез. Жирафлар. (Балалар жираф-

лар янына киләләр.) Бу нәрсәләр? (*Жирафлар.*) (Активлаштыру. Шул рәвешле, уен фил һәм филләр белән дә үткәрелә.) Булдырдыгыз, балалар!

Тәрбияче «жираф» дигәч, балалар бер жираф торган урынга киләләр, тәрбияче «жирафлар» дигәч, күп жирафлар янына киләләр. Фил белән дә шулай ук кабатлыйлар.

## Тема. РӘХМӘТ, ҖӘЙ!

**Бурычлар:**

1) балаларны яшелчәләрне, җиләк-җимешләрне тәме буенча аерырга өйрәтүне дәвам итү; яшелчәләр, җиләк-җимешләр, агачлар турындагы белемнәрен киңәйтү;

2) кабул итү сәләтен, игътибарны үстерү;

3) игътибар белән тыңларга өйрәтү, табигатькә сакчыл караш тәрбияләү.

**Җиһазлар:** сандык, конвертка беркетелгән тасма, шар, «алтын чикләвек», кыяр, помидор, кишер, алма, груша кисәкләре, сливалар.

### Эшчәнлек барышы.

Эшчәнлек ишегалдында бара.

Тәрбияче. Балалар, карагыз әле, нәрсә бу? (*Сандык.*) (Активлаштыру.) Сандык йозак белән бикләнгән. Кем калдырды икән бу сандыкны? Аның эчендә нәрсә бар икән? (Сандык эченнән бер тасма чыгып тора, ул матур конвертка беркетелгән, аны җайлы гына тартып чыгарып була. Тәрбияче конвертны ала, ача һәм укый.) Балалар, монда ниндидер хат бар, әйдәгез, укыйбыз. «Исәнмесез! Мин — Җәй. Мин бу сандыкны кече төркем балаларына җибәрдем. Сандыкның ачкычы яшерелгән. Уеннар уйнагач, ачкычны табып була. Иң беренче, балалар ишегалдындагы каенга бәйләнгән шар эченнән «алтын чикләвек» табарга тиешләр». Балалар, әйдәгез, каен агачын табыйк әле. Гүзәл, каен агачын күрсәт әле. Марат, каенның кәүсәсе нинди төстә? (*Ак.*) (Активлаштыру.) Аның яфраклары нинди төстә? (*Яшел.*) (Активлаштыру.) Балалар, сез шарны күрәсезме? Ул нинди төстә? (*Зәңгәр.*) (Активлаштыру. Тәрбияче шар эченнән «алтын чикләвек» ала.) Булдырдыгыз, балалар, бу уен бик кызыклы булды. Тагын уйныйк әле. Әйдәгез, балалар, үзебезнең беседкага барабыз. Карагыз әле, беседкага кереп булмый бит. (Шул вакыт Җәй кызы киеменнән икенче тәрбияче балалар каршысына чыга, аның кулындагы тәлинкәдә кыяр, помидор,

кишер, алма, груша кисәкләре, сливалар.) Исәнмесез, балалар! (Активлаштыру.) Хәзер без сезнең белән «Тәмен бел» уены уйнарбыз. Күзләрегезне йомыгыз, мин сезгә яшелчәләр, җиләк-җимешләр каптырам, ә сез аның нәрсә икәнен әйтерсез. Алмаз, күзеңне йом әле. Хәзер мин биргән тәмле әйберне кап. Бу нәрсә? (*Кыяр*.) Булат, ә син нәрсә каптың? (*Слива*.) (Уен шул рәвешле дәвам итә.) Булдырдыгыз, балалар, сез яшелчәләрне дә, җиләк-җимешләрне дә бик яхшы беләсез икән. Бу яшелчәләрне, җиләк-җимешләрне Җәй алып килде. Сез биремнәрне яхшы үтәдегез, менә сезгә сандык ачкычы. Балалар, әйдәгез, Җәй кызына рәхмәт әйтик. (Активлаштыру.) Балалар, әйдәгез, хәзер сандыкны ачып карыйк инде, анда нәрсәләр бар икән? Карагыз әле, Җәй безгә күпме күчтәнәч җибәргән! Монда нәрсәләр бар? (*Җиләк*.) (Активлаштыру.) Нинди матур, хуш исле кызыл җиләкләр! Балалар, Җәйгә бу күчтәнәчләр өчен зур рәхмәт әйтик. (Активлаштыру.) Бу җиләкләрне кергәч ашарбыз.

# МАТУР ӘДӘБИЯТ БЕЛӘН ТАНЫШТЫРУ

## *Беренче бүлек.* БЕЗНЕҢ БАЛАЛАР БАКЧАСЫ

### Тема. «ҮЧТЕКИ, ҮЧТЕКИ» ТАКМАГЫН УКУ

**Бурычлар:**

1) фольклор әсәрләре белән кызыксыну уяту, шигъри әсәрнең эчтәлеген аңларга өйрәтү;

2) балаларның кабул итү сәләтен, хәтерен, уңай эмоцияләрен үстерү;

3) нәфис сүзгә мәхәббәт тәрбияләү.

**Җиһазлар:** ширма, кыз курчак һәм малай курчак.

**Эшчәнлек барышы.**

Ширма артыннан кечкенә кыз һәм малай курчак чыга.

Тәрбияче. Балалар, карагыз әле, безгә кунаклар килгән. Нинди кунаклар килгән? Бу кем? (*Малай.*) (Активлаштыру.) Бу кем? (*Кыз.*) (Активлаштыру.) Әйе, нинди матур кечкенә кыз һәм малай килгәннәр. Кызның исеме — Мәрьям. Кызның исеме ничек? (*Мәрьям.*) (Активлаштыру.) Малайның исеме — Гайсә. Малайның исеме ничек? (*Гайсә.*) (Активлаштыру.) Мәрьям белән Гайсәнең зур булып үсәсе килә. Әйдәгез, аларны такмак әйтеп үстерик әле. (Тәрбияче такмакны укый.)

Үчтеки, үчтеки,

(Кулларны алга сузып, куллар белән сикерткән хәрәкәтләр ясала.)

Үсмәгәнгә кечтеки,

(Чүгәләп, кулы белән бәләкәйлекне күрсәтә.)

Үсә-үсә зур булыр,

(Кулларын өскә күтәреп, зур үсүне күрсәтә.)

Бигрәк матур кыз булыр,
Бик батыр егет булыр.

(Ике кулы белән башын, битен, колакларын, кулларын, гәүдәсен, аякларын сыйпый.)

(Тәрбияче такмакны икенче тапкыр укый. Балалар аның артыннан хәрәкәтләрне кабатлыйлар.) Балалар, сез ясаган хәрәкәтләр Гайсә белән Мәрьямгә бик ошады. Әйдәгез, Гайсә белән Мәрьямне машинага утыртып йөртик әле. Аларга күңелле булсын. (Балалар курчакларны машинага утырталар. Машинага озын бау тагылган була. Балалар барысы да бергә бауга тотыналар. Шулай итеп, курчакларны машинада йөртәләр.) Балалар, машина кычкырта. Машина ничек кычкырта? (*Би-биип!*) (Бергәләп кабатлыйлар.) Мәрьям һәм Гайсә китәргә җыеналар. Алар сезнең матур кызлар, акыллы егетләр булып үсүегезне телиләр. Балалар, Мәрьям һәм Гайсә белән саубуллашыгыз! (*Сау булыгыз*!)

## Тема. Ә. БИКЧӘНТӘЕВАНЫҢ «ТУП-ТУП-ТУБЫБЫЗ» ШИГЫРЕН УКУ

**Бурычлар:**

1) балаларга шигырьнең эчтәлеген аңларга ярдәм итү, таныш предметларны таный һәм атый белергә, шигырьнең авыр әйтелешле аерым сүзләрен дөрес әйтергә өйрәтү, төсләрне ныгыту;

2) балаларның кабул итү сәләтен, хәтерен, уңай эмоцияләрен үстерү;

3) уенчыкларга сакчыл караш тәрбияләү.

**Җиһазлар:** «тылсымлы» янчык, зур туп, кәрзин белән кечкенә туплар, кыршаулар.

### Эшчәнлек барышы.

Тәрбияче «тылсымлы» янчык алып керә, балаларга күрсәтә. Аннан, тупны алып, сораулар бирә.

Тәрбияче. Туп нинди? (*Түгәрәк, матур, кызыл.*) Туп белән нәрсә эшләргә була? (*Уйнарга була: тәгәрәтеп, чөеп, ыргытып.*) Балалар, хәзер шул турыда шигырь тыңлагыз. (Тәрбияче шигырьне укый.) Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк: «туп-туп-тубыбыз». Туп нинди, матурмы? Әйе, син безнең матурыбыз. Әйдәгез, тупка ягымлы итеп, «матурыбыз» дип әйтик. (Активлаштыру.) Туп нишли?(Тәрбияче тупны идәнгә бәреп сикертә.) (*Туп сикерә.*) Әйе, дөрес әйтәсез, туп сикерә. Балалар, тупны өскә чөеп уйнарга да була. Менә карагыз әле. (Тәрбияче тупны чөеп күрсәтә.) Балалар, туп белән шулай уйныйлар. Шигырьне тагын бер кат укыйм, игътибар белән тыңлагыз. (Икенче тапкыр укыганда, кайбер сүзләрне балалардан әйттерә.)

Туп-туп-тубыбыз,
Син безнең ... (*матурыбыз*).
Тишмәбез дә югалтмабыз,
Оста тота ... (*кулыбыз*).
Рөстәм, сиңа да бирәбез,
Әйдә, уйныйбыз ... (*бергә*),
Кирәк аны чөеп-чөеп
Тотып ала ... (*белергә.*)

Туп сикерә, син дә сикер,
Тыпыр-тыпыр ... (*тыпырда*),
Дуслар белән уйна бергә,
Читтә генә ... (*утырма*).
Туп-туп-тубыбыз,
Сикерәбез, ... (*көләбез*),
Югары оч, түбәнгә ... (*төш*),
Без тотып ... (*өлгерәбез.*)

Шигырьне укыганда, тәрбияче туп белән шигырьнең эчтәлегенә туры килгән хәрәкәтләр ясый. Тәрбияче кәрзин белән балалар санынча туплар алып керә. Тупларны кыршаулардан ясалган «яланга» тарата. Һәр балага берәр туп алып, кәрзингә салырга куша. Тупны салганда, балалардан сорый: «Синең тубың нинди төстә?» Балалар әйтә алмаса, тупның төсен тәрбияче үзе әйтә.

Тәрбияче. Булдырдыгыз, балалар! Шигырьне укыганда, миңа ярдәм иттегез. Бик күңелле итеп, туп белән уйнадыгыз.

## Тема. С. СӨЛӘЙМАНОВАНЫҢ «ИКЕ» ШИГЫРЕН УКУ

**Бурычлар:**

1) балаларда шигъри әсәр белән кызыксыну уяту, аның эчтәлеген аңларга өйрәтү, баланың үзе турында күзаллавын формалаштыруны дәвам итү; *кул, аяк, колак, күз* сүзләре хисабына сүз байлыгын арттыру һәм активлаштыру;

2) кабул итү сәләтен, игътибарны, уңай эмоцияләрне үстерү;

3) гигиена күнекмәләре тәрбияләү.

**Җиһазлар:** аудио- яки видеомузыка (релаксация өчен).

### Эшчәнлек барышы.

Музыка яңгырый.

Тәрбияче. Балалар, үзегезнең аякларыгызга карагыз әле. Алар нәрсә өчен кирәк? (*Йөгерү, йөрү, атлау, туп тибү* һ.б. *өчен.*) Әйе, аяклар безгә хәрәкәтләр ясау өчен кирәк. Балалар, ә хәзер кулларыгызга карагыз. Алар да бит күп нәрсә эшли алалар. (*Кочаклыйлар, әйберләрне тоталар, төшкән әйберне алалар, кошларга, җәнлекләргә ашарга бирәләр, өстәл әзерлиләр, бармакларны саныйлар* һ.б.) Әйе, дөрес, балалар. Карагыз әле кулларыгызга. (*Алар күтәреләләр, төшәләр, борылалар* һ.б.) Балалар, колакларыгызны тотып карагыз әле.

Алар нәрсә өчен кирәк? (*Ишетер, тыңлар өчен.*) Ә хәзер күзләрегезне күрсәтегез әле. Күзләр нәрсә эшлиләр?(*Күрәләр, карыйлар, йоклыйлар, ачылалар, йомылалар.*) Хәзер мин сезгә аяклар, куллар, колаклар, күзләр турында шигырь укыйм.

Шигырьне беренче кат уку.

Тәрбияче. Балалар, Әнвәрнең ничә аягы бар? (*Ике.*) Ә кулы ничә?(*Ике.*) Ничә колагы бар?(*Ике.*) Ә күзләре ничә икән?(*Ике.*) Кулында ничә тубы бар?(*Ике.*) Балалар, бу туплар зурлыгы буенча нинди?(*Кечкенә, зур.*) Әнвәр нинди ике сүзне бик яратып әйтә, теленнән дә төшерми? (*Әти, әни.*) Балалар, Әнвәргә ничә яшь? (*Ике.*)

Шигырьне икенче кат укый. Тәрбияче, *аягы, кулы, колагы, күзе* сүзләрен әйткәндә, балалар аның белән бергә кабатласын өчен, аякларны, кулларны, күзләрне кулы белән күрсәтеп бара. Бүлмәдә музыка яңгырый.

Тәрбияче. Балалар, мин сезне бик яратам. Аякларыгыз, кулларыгыз, колакларыгыз, күзләрегез сәламәт булсыннар. Әйдәгез, аларны яратып сыйпагыз әле. Алар да сез яратканны тоялар. Үзегезне яратсагыз, чиста тотсагыз, барыгыз да сәламәт булырсыз.

## *Икенче бүлек.* КӨЗ

### Тема. ХАЙВАННАРНЫ ЧАКЫРУ ЭНДӘШЕН УКУ

**Бурычлар:**

1) эндәшнең эчтәлеген аңлату, текстның эчтәлегеннән чыгып, аваз ияртемнәрен, ымлыкларны дөрес әйтүләренә, тәрбияче сорауларына дөрес җавап бирүләренә ирешү;

2) балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерү;

3) хайваннарны ярату хисе тәрбияләү.

**Җиһазлар:** кәҗә, ат, эт рәсемнәре яки уенчыклар, «Автобус» уенына кирәкле әйберләр.

**Эшчәнлек барышы.**

Тәрбияче. Балалар, без бүген сезнең белән авылга, әби белән бабай янына кунакка кайтабыз. Менә бу — безнең автобус. (Урындыклардан төзелгән «автобус» күрсәтелә.) Балалар, урындыкларга утырыгыз. (Музыка куела, «автобус» кузгала.) Менә без килеп тә җиттек. (Келәмгә уенчык йорт хайваннары куела: кәҗә, ат, эт.) Балалар, карагыз әле, әби

белән бабайның ишегалдында нинди хайваннар бар? (*Кәҗә, эт, ат.*) (Активлаштыру.) Кәҗә ничек кычкыра? (*«Ми-ки-ки!»*) Кәҗә нәрсә ашарга ярата? (*Кәбестә.*) Әйдәгез, кәҗәне чакырыгыз: «кәҗ-кәҗ-кәҗ! Кәҗ-кәҗ-кәҗ!» (Активлаштыру.) Бу нәрсә? (*Эт.*) Ул нишли? (*Өрә.*) Эт ничек өрә? (*«Һау-һау!»*) Әйдәгез, этне чакырыгыз әле: «маһ-маһ-маһ! Маһ-маһ-маһ!» (Активлаштыру.) Ә бу нәрсә? (*Ат.*) Атның нәрсәләре бар? (*Башы, гәүдәсе, койрыгы, аяклары* һ.б.) (Активлаштыру.) Әйдәгез, атны чакырыгыз әле: «бах-бах-бах! Бах-бах-бах!» (Активлаштыру.) Балалар, кәҗә, эт, ат инде арыдылар. Алар ял итсеннәр. Без дә сезнең белән «автобус» белән бакчабызга кире кайтабыз. «Автобус»ка утырыгыз.

## Тема. Д. ГАРИФУЛЛИННЫҢ «ЙӘ, АЛАР КЕМНӘР ИКӘН?» ШИГЫРЕН УКУ

**Бурычлар:**

1) шигъри әсәрне аңлап кабул итәргә өйрәтүне дәвам итү; *бак-бак, мә-ә, мә-ә, кар-р, кар-р* аваз ияртемнәрен кабатлату; балаларны шигырьдә бирелгән диалогка җәлеп итү, сүзлекне активлаштыру;

2) игътибарын, күзәтүчәнлеген, кабул итү сәләтен үстерү;

3) кошларга, хайваннарга карата шәфкатьлелек тәрбияләү.

**Җиһазлар:** уенчык үрдәк, бәрән, карга яки аларның рәсемнәре.

### Эшчәнлек барышы.

Ширма артыннан «бак-бак!» дигән тавыш ишетелә.

Тәрбияче. Балалар, нинди тавыш килә, кабатлагыз әле. (*«Бак-бак!»*) Нәрсә шулай кычкыра? (*Үрдәк.*) Әйе, менә ул үрдәк! Исәнмесез, балалар! Исәнмесез! (Үрдәкне өстәл өстенә куя.)

Ширма артыннан «мә-ә, мә-ә!» дигән тавыш ишетелә.

Тәрбияче. Балалар, нинди тавыш килә, кабатлагыз әле. (*«Мә-ә, мә-ә!»*) Нәрсәләр шулай кычкыралар? (*Бәрәннәр.*) Бик дөрес. (Уенчык бәрән өстәл өстенә куела.)

Ширма артыннан «кар-р, кар-р!» дигән тавыш ишетелә.

Тәрбияче. Балалар, ә бу нәрсә тавышы? (*Карга.*) Дөрес, карга тавышы. (Уенчык карга өстәл өстенә куела. Карга нәрсә дип әйткән иде әле? (*«Кар-кар, мичтә бәлеш бар-бар!»*) (Искә төшерә алмасалар, тәрбияче үзе балаларга әйтеп җибәрә.) Балалар, карагыз әле, нинди уенчыклар бар монда?

(Тәрбияче үрдәккә, аннары бәрәнгә, аннары каргага күрсәтә.) Хәзер үрдәк, бәрән, карга турында бер шигырь укыйм:

### Йә, алар кемнәр икән?

— Тезелешеп кайталар,
«Бак-бак-бак» дип әйтәләр,
Йә, алар кемнәр икән?
— Алар үрдәкләр икән.
— Сикерешеп уйныйлар,
Мәэлдәшеп туймыйлар.
Йә, алар кемнәр икән?
— Алар бәрәннәр икән.
— Юлны күктән сузалар,
Каркылдашып узалар.
Йә, алар кемнәр икән?
— Алар каргалар икән.

Бу шигырь нәрсә турында? (Балаларның җаваплары.) Әйе, балалар, бу шигырь үрдәкләр, бәрәннәр, каргалар турында. Нәрсәләр тезелешеп кайталар? (*Үрдәкләр.*) Нәрсәләр сикерешеп уйныйлар? (*Бәрәннәр.*) Нәрсәләр каркылдашалар? (*Каргалар.*) (Активлаштыру.) Хәзер мин сезгә шигырьне тагын бер кат укырмын. (Тәрбияче балаларны келәм янына алып килә. Уенчык үрдәк, бәрән, карганы келәмгә аерым урыннарга урнаштыра.) Балалар, хәзер мин шигырь укыйм, ә сез, мин нәрсә турында укысам, шуның янына барыгыз.

(Тәрбияче үрдәк турында укый. Балалар үрдәк янына барып басалар.) Үрдәк ничек кычкыра? (*«Бак-бак!»*) (Шул рәвешле, шигырьнең икенче, өченче куплетлары укыла. Балалар уенчык бәрән, карга янына баралар. Аларның ничек кычкырганын әйтәләр.) Балалар, үрдәк һәм карга — кошлар. Бәрән — йорт хайваны. Кошларны һәм хайваннарны яратырга кирәк.

## Тема. Б. РӘХМӘТНЕҢ «СУ» ШИГЫРЕН УКУ

**Бурычлар:**

1) текстка туры китереп, хәрәкәтләр ясарга өйрәтү; [йу] аваз кушылмасын дөрес итеп әйтергә күнектерү, сүз байлыгын үстерү һәм активлаштыру;

2) кабул итү сәләтен, игътибарны, кызыксынучанлыкны үстерү;

3) гигиена күнекмәләре тәрбияләү.

**Җиһазлар:** су салынган кувшин, таз.

**Эшчәнлек барышы.**

Тәрбияче кувшиннан тазга су агыза.

Т ә р б и я ч е. Балалар, нәрсә бу? (*Су.*) Су нишли? (*Ага.*) Хәзер мин сезгә су турында шигырь укыйм. (Укый.) Балалар, бу шигырь нәрсә турында? (*Су турында.*) Су белән нәрсәләрне

юалар? (*Битне, кулларны.*) (Активлаштыру.) Салкын су бит-кулларны нишләтә? (*Туңдыра.*) Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: «туңдыра». Игътибар белән тыңлагыз әле, шигырьне тагын бер тапкыр укыйм. (Тәрбияче, шигырьне икенче тапкыр укыганда, шигырьнең эчтәлегенә туры килгән хәрәкәтләр ясый, балаларга да бу хәрәкәтләрне ясарга куша.) Балалар, су белән тагын нәрсә эшләргә була? (*Аш пешерергә, чәй кайнатырга, эчәргә, кер юарга* һ.б.) Әйе, балалар, кер юарга була. Әйдәгез, без сезнең белән кер юып алыйк.

Аюның күлмәген юам,

(Кер юуны имитациялиләр.)

Аннары чайкыймын,

(Чайкыйлар.)

Әйбәтләп сыгамын

(Сыгалар.)

Һәм бауга эләмен.

(Ике кул белән элү хәрәкәте күрсәтәләр.)

Аю күлмәген кисен,

(Җилкәдән аска таба ике кул белән гәүдәләрен сыйпыйлар.)

Чисталыкка сөенсен!

(Аякларын аю кебек аерып куеп, як-якка авышып йөриләр.)

Булдырдыгыз, балалар! Игътибар белән су турындагы шигырьне тыңладыгыз, тырышып кер юдыгыз. Аю сезгә рәхмәт әйтә.

## *Өченче бүлек.* МИН — ДӨНЬЯНЫҢ БЕР КЕШЕСЕ

### Тема Г. ТУКАЙНЫҢ «ГАЛИ БЕЛӘН КӘҖӘ» ШИГЫРЕН УКУ

**Бурычлар:**

1) шигъри әсәрне аңлап кабул итүләренә ирешү, «Мин — дөньяның бер кешесе» дигән күзаллау булдыру; *кәҗә, чирәм, сакал* сүзләре хисабына сүз байлыгын арттыру, хәрәкәтләр өйрәтүне дәвам итү;

2) кабул итү сәләтен, игътибарны, уңай эмоцияләрне үстерү;

3) балаларда бер-берсенә һәм хайваннарга карата кайгыртучанлык тәрбияләү.

**Җиһазлар:** Г. Тукайның «Гали белән кәҗә» әсәренә иллюстрация.

**Эшчәнлек барышы.**

Т ә р б и я ч е . Балалар, әйдәгез әле, кулга-кул тотынып, түгәрәккә басыйк. Бер-берегезгә карап елмаегыз, шулай итеп, бер-беребезне сәламлибез.

Кулга-кул тотышып басыйк без,
Бергәләп түгәрәк ясыйк без.
Түгәрәкнең була зурысы,

(Балалар түгәрәкне зурайталар.)

Түгәрәкнең була кечесе.

(Балалар түгәрәкне кечерәйтәләр.)

Түгәрәк эчендә
Урын бар һәркемгә:
Миңа да, сиңа да, безгә дә.

(Бала үзен, янәшәсендәге иптәшләрен һәм башкаларны күрсәтә.)

Дусларыннан читтә
Калмасын беркем дә!

(Кулга-кул тотышып, түгәрәк ясыйлар.)

Балалар, өлкәннәр һәм сезнең кебек балалар белән бергә җирдә кошлар да, хайваннар да яши. Өлкәннәр һәм кечкенә балалар алар турында кайгырталар. Шундый балаларның берсе турында мин сезгә шигырь укыйм. Игътибар белән тыңлагыз. (Тәрбияче шигырьне укый. Икенче тапкыр укыганда, тәрбияче иллюстрациягә мөрәҗәгать итә: Гали кайсы хайван белән тату, дус булган? (*Кәҗә.*) (Активлаштыру.) Гали кәҗәне нәрсә белән сыйлый, кунак итә? (*Чирәм белән.*) Кәҗә Галигә нәрсә укый? (*Рәхмәт.*) Кәҗә нәрсәсен селкетә? (*Сакалын.*) (Активлаштыру. Өченче тапкыр шигырьне укыганда, тәрбияче шигырьдәге кайбер сүзләрне балалардан әйттерә.)

Безнең ... (*Гали*) бигрәк тату ... (*кәҗә*) белән,
Менә ... (*кәҗә*) карап тора ... (*тәрәзәдән*).
Гали аны ... (*чирәм*) белән кунак итә,
Кәҗә ... (*рәхмәт*) укый: ... (*сакалын*) селкетә.

Әйдәгез, хәзер уйнап алыгыз әле. Бармаклардан кәҗә ясыйбыз: кулны алга сузабыз, учлар алга караган, имән һәм чәнти бармаклар бөгелмәгән, алга карап торалар. Урта һәм исемсез бармак учка каратып бөкләнгән, баш бармак алар өстенә куелган. Менә шулай (күрсәтә):

Кәҗәнең бар мөгезе,
Сөзә күрмәсен сезне!

Булдырдыгыз! Әйдәгез, кабатлыйк әле: «Без булдырабыз!» (Балалар кабатлыйлар, кул чабалар.)

## Тема. 3. ТУФАЙЛОВАНЫҢ «УЛ ЗУ-У-У-УР ҮСКӘН» ШИГЫРЕН УКУ

**Бурычлар:**

1) шигъри әсәрне аңлап кабул итүләренә ирешү һәм хезмәтнең нәтиҗәсен күрә белергә өйрәтү; *утырткан, сипкән, үскән* кебек эш-хәрәкәтне белдерә торган фигыльләр хисабына сүз байлыгын арттыру һәм активлаштыру, диалогик сөйләм күнекмәсе формалаштыру;

2) балаларның эмоциональлеген үстерү;

3) гөлләргә карата сакчыл караш, матурлыкка соклану тәрбияләү.

**Җиһазлар:** гөлләр, Ләлә-курчак.

### Эшчәнлек барышы.

Тәрбияче гөлләр янына килә.

Тәрбияче. Балалар, бу нәрсәләр? (*Гөлләр.*) Балалар, мин хәзер сезгә бер шигырь укыйм.

— Кем утырткан бу гөлләрне?
Кем су сипкән?
— Ләлә утырткан, Ләлә су сипкән.
Гөл зу-у-у-ур үскән.

Балалар, бу гөлләрне кем утырткан? (*Ләлә утырткан.*) Кем гөлләргә су сипкән? (*Ләлә су сипкән.*) Гөл нинди булып үскән? (*Зу-у-у-ур булып үскән.*) Балалар, карагыз әле, нинди матур гөл! Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: «Нинди матур гөл!» Гүзәл, син дә кабатла. Ә хәзер, Илнар, син кабатла. (Активлаштыру.) Гөлләр шундый матур булып үссен өчен, аларны яратырга, сакларга, су сибәргә, карарга кирәк.

Шигырь икенче кат укыла. Тәрбияче кайбер сүзләрне балалардан әйттерә.

— Кем утырткан бу ... (*гөлләрне*)?
Кем ... (*су*) сипкән?
— Ләлә ... (*утырткан*), Ләлә ... (*су сипкән*).
Гөл ... (*зу-у-у-ур үскән*).

(Тәрбияче гөл исеменнән сөйли.) Балалар, мин сезне, сезнең күзләрегезне, сезнең йомшак кулларыгызны яратам. Сез гөлләрне бик яратасыз икән. Сезнең яратуыгыз мине куандыра, минем гел үсәсем, чәчәк атасым килә. Сез минем кайчан су эчәсе, юынасы килгәнне дә сизәсез. (Балалар гөлләргә су сибәләр.)

## Тема. «ПЕСИ-НЕЧКӘБИЛ» БИШЕК ҖЫРЫН ҖЫРЛАУ

**Бурычлар:**

1) шигъри әсәрне аңлап кабул итүләренә ирешү, бишек җыры текстына туры китереп, хәрәкәтләр башкарырга өйрәтү;

2) балаларның игътибарын үстерү;

3) фольклор әсәрләре белән кызыксыну тәрбияләү.

**Җиһазлар:** уенчык песи, бишеккә яки коляскага йоклатырга салынган курчак, елаган бала тавышы язмасы яисә елый белгән курчак.

**Эшчәнлек барышы.**

Тәрбияче. Балалар, ишетәсезме, кемдер елый түгелме? (Бала елаган тавыш ишетелә, моның өчен аудиоязма яисә елый белгән курчак кулланыла.) Әйдәгез, эзләп карыйк әле. (Балалар бүлмә буйлап эзлиләр, коляскага салынган курчак янында туктыйлар.) Менә кем елый икән! Ни өчен елыйсың? (Тәрбияче курчакны ала.) Балалар, ә сез ничек уйлыйсыз, курчак ни өчен елый? (*Ашыйсы килә, йоклыйсы килә* һ.б.) Әйе, балалар, курчакның йоклыйсы килгән. Кайда йоклатырга була? (*Бишектә, караватта, колякада.*) Без курчакны бишеккә (коляскага) салабыз. Курчак йокласын өчен, аны тирбәтергә кирәк. Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк: «тирбәтергә». (Активлаштыру.) Ә йокысы тәмле булсын өчен, бишек җыры җырларга кирәк. Балалар, тыңлагыз әле: нинди тавыш килә соң? (Песи мияулаган тавыш ишетелә.) Дөрес, ишек артында песи мияулый. (Барып карыйлар.) Балалар, әйдәгез, песине курчакны тирбәтергә чакырыйк. (Тәрбияче бер-ике тапкыр бишек җырын җырлый. Балалар, булдыра алганча, аны кабатлыйлар.) Балалар, әйдәгез, сез дә, курчакка тәмле йокы теләп, «бәлли-бәү» дип кабатлагыз әле. (ике-өч тапкыр кабатлыйлар.) Менә курчак йоклап та китте. Ә без хәзер сезнең белән тыныч кына урамга чыгарбыз. Песи дә безнең белән урамга чыгар.

# *Дүртенче бүлек.* МИНЕМ ӘЙЛӘНӘ-ТИРӘ

## Тема. М. ҖӘЛИЛНЕҢ «МАЭМАЙ» ШИГЫРЕН УКУ

**Бурычлар:**

1) шигъри әсәрне аңлап кабул итүләренә ирешү, бармак театры элементларын өйрәтүне дәвам итү, сүз байлыгын арттыру;

2) кабул итү, хәтердә калдыру сәләтен үстерү;

3) йорт хайваннарына карата шәфкатьлелек тәрбияләү.

**Җиһазлар:** уенчык эт.

**Эшчәнлек барышы.**

Тәрбияче балаларга уенчык эт яшерелгән кәрзин күрсәтә.

Тәрбияче. Балалар, кәрзин эченә бер уенчык яшерелгән. Хәзер мин сезгә табышмак әйтәм, җавабын тапсагыз, кәрзин эчендә нинди уенчык барлыгын белерсез. (Кәрзин эченнән этнең селкенгән койрыгы күренә.) Бу нәрсә койрыгы икән? (*Эт, көчек, маэмай.*) (Активлаштыру. Тәрбияче кәрзин эченнән этне алып күрсәтә, балалар эт белән исәнләшәләр, аны карыйлар.) Эт нинди? (*Йонлач, йомшак, кечкенә* һ.б.) Балалар, эт ничек өрә? (*«Һау-һау!»*) Сез дә эт кебек өреп карагыз. (*«Һау-һау!»*) Эт нәрсәләр эшли белә? (*Өрә, йөри, сөяк кимерә, йөгерә, утыра, койрыгын селкетә, исни.*) Хәзер эт турында шигырь тыңлагыз. (Тәрбияче шигырьне ике тапкыр укый.)

Минем бар бер маэмаем,
Кара борын Акбаем.
Күп йөгерә, күп өрә,
Күп ишетә, күп күрә...

Маэмайның кушаматы (исеме) ничек? (*Акбай.*) Аның борыны нинди төстә? (*Кара.*) Акбай нәрсәләр эшли белә? (*Йөгерә, өрә, ишетә, күрә.*)

(Тәрбияче шигырьне өченче тапкыр укый. Шигырьдәге кайбер сүзләрне тәрбияче балалардан әйттерә.)

Минем бар бер ... (*маэмаем*),
Кара борын ... (*Акбаем.*)
Күп ... (*йөгерә*), күп ... (*өрә*),
Күп ... (*ишетә*), күп ... (*күрә*).

Әйдәгез, кул бармакларыннан эт ясап карыйк: уң кулның учын кабыргасы белән үзегезгә каратып куегыз. Баш бармак өскә караган, имән бармак бөгелгән, калган ике бармак бергә кушылган, чәнти бармак аска таба тартыла. (Уен күнегүе берничә тапкыр кабатлана.)

Акбайның бар борыны,
Муены һәм койрыгы.

Балалар, эт — кешенең дусты, ул йорт саклый. Аны рәнҗетергә ярамый.

## Тема. М. ҖӘЛИЛНЕҢ «ӘТӘЧ» ШИГЫРЕН УКУ

**Бурычлар:**

1) күрсәтмәлелек кулланмыйча, әдәби әсәрне тыңлау һәм кабул итү күнекмәләре формалаштыру; тавышлары буенча йорт кошла-

рын таныргa һәм исемнәрен атарга өйрәтү; [к] һәм [к] авазларының әйтелешен ныгыту;

2) кабул итү сәләтен, игътибарны, тыңлау осталыгын үстерү;

3) йорт кошларына карата шәфкатьлелек тәрбияләү.

**Җиһазлар:** уенчык йорт кошлары (каз, тавык, үрдәк, әтәч).

### Эшчәнлек барышы.

Тәрбияче аудиоязмадагы йорт кошлары тавышларын тыңлата. Бер-бер артлы каз, тавык, әтәч тавышлары ишетелә.

Тәрбияче. Бу нәрсә тавышы? (*Каз.*) Каз ничек кычкыра? (*«Ка-ка-как!»*) Уенчыклар арасыннан казны күрсәтегез әле. (Һәр уенчык белән шундый ук эш башкарыла. Әтәч тавышы ишетелә, аны тыңлагач, тәрбияче әтәч турында шигырь тыңларга тәкъдим итә. Тәрбияче, шигырьне укыгач, сораулар бирә.) Әтәч ничек кычкыра? (*«Кикрикү-үк!»*) Әтәч иртән кычкыра. Әтәч таң атканда кычкыра дип тә әйтергә була. Әтәч кайчан кычкыра? (*Иртән. Таң атканда.*) Әтәч тавышына кемнәр уяна? (*Балалар, әниләр, әтиләр.*) Уянгач, сез нәрсә эшлисез? (*Битне юабыз, киенәбез, балалар бакчасына киләбез.*) Балалар, шигырьне тагын бер тапкыр тыңлагыз. (Тәрбияче шигырьне тагын бер тапкыр укый.) Әйдәгез әле, бармаклардан әтәч ясап карыйк. Кулны сузабыз, учны өскә каратабыз. Имән бармакны баш бармакка терәп куябыз. Калган бармакларны аерып, өскә каратабыз:

Нинди матур безнең әтәч!
Кычкыра ул, таң аткач:
«Кикрикү-үк! Кикрикү-үк!»

## Тема. Җ. ТӘРҖЕМАНОВНЫҢ «МАЭМАЙ» ШИГЫРЕН УКУ

**Бурычлар:**

1) шигъри әсәрне аңлап кабул итүләренә ирешү, аерым сүзләрне һәм зур булмаган фразаларны истә калдырырга өйрәтү;

2) балаларның игътибарын үстерү;

3) эткә карата миһербанлылык тәрбияләү.

**Җиһазлар:** уенчык эт, эт битлеге.

### Эшчәнлек барышы.

Ширма артыннан эт өргән тавыш ишетелә.

Тәрбияче. Балалар, бу нәрсә тавышы? (*Эт тавышы.*) Эт нәрсә эшли? (*Эт өрә.*) Этнең сезнең белән уйныйсы килгән. Бу этнең кушаматы — Акбай. Әйдәгез, бергәләп кабат-

лыйк: «Акбай». Балалар, Акбай белән уйнап алабызмы? Марат, син Акбай булырсың. (Тәрбияче Маратка эт битлеге кидерә.) Марат, син келәмгә ят. Күзләреңне йом, йоклаган булып ят. Ә без, балалар, аяк очларында гына Акбай янына барабыз. Минем белән бергә сүзләрне кабатлагыз. (Тәрбияче балалар белән бергә Акбай янына бара һәм сүзләрне бергә кабатлыйлар.)

Акбай йокларга яткан,
Күп йөгереп ул арыган.
Без аны уятабыз,
«Тор, Акбай!» — дип әйтәбез.

Тәрбияче бер балага Акбайны уятырга куша. Акбай уяна, өрә-өрә, балаларны куып тотарга тырыша.

Тәрбияче. Булдырдыгыз, балалар, Акбайга тоттырмадыгыз. Акбай да бик тырышты. Балалар, Акбай арыган. Ул да, сез дә ял итеп алыгыз әле. Урындыкларга (келәмгә) утырыгыз. Мин сезгә Акбай турында шигырь укыйм.

Тешләмәсен Акбаем,
Сезгә өрә маэмаем:
«Ташлар ыргытмагыз, ди,
Мине котыртмагыз», — ди.

Акбай нәрсә эшли? (*Өрә.*) Ул нәрсә ди? (*Ташлар ыргытмагыз.*) Ә тагын нәрсә ди? (*Мине котыртмагыз.*)

Шигырьне икенче тапкыр укыйлар.

Тешләмәсен ... (*Акбаем*),
Сезгә өрә ... (*маэмаем*):
«Ташлар ... (*ыргытмагыз*), ди,
Мине ... (*котыртмагыз*)», — ди.

Акбай: «Мине котыртмагыз», — ди. Ул дөрес әйтә. Этне котыртсаң, ул тешләргә мөмкин. Хайваннарны яратырга гына кирәк.

## *Бишенче бүлек.* ЯҢА ЕЛ БӘЙРӘМЕ

### Тема. Ә. БИКЧӘНТӘЕВАНЫҢ «БЕРЕНЧЕ АДЫМ» ШИГЫРЕН УКУ

**Бурычлар:**

1) балаларга шигырьнең эчтәлеген аңларга ярдәм итү, авыр әйтелешле кайбер сүзләрне дөрес әйтергә өйрәтү;

2) сорауларга җавап бирү күнекмәсен үстерү;
3) күмәк эшчәнлек күнекмәсе тәрбияләү.

**Җиһазлар:** рәсемнәр: 1) үрмәләп йөрүче малай; 2) чыршы янында басып торучы малай; татар бию көе аудиоязмасы.

**Эшчәнлек барышы.**

Тәрбияче. Балалар, тиздән Яңа ел бәйрәме җитә. Яңа ел бәйрәменә нинди агачны бизиләр?(*Чыршы.*) (Активлаштыру.) Балалар бу бәйрәмне бик яраталар, аны көтеп алалар. Камил исемле бер кечкенә малай Яңа ел бәйрәменә «тәпи-тәпи» килгән. Балалар, мин сезгә хәзер бу турыда шигырь укыйм. Игътибар белән мине тыңлагыз. (Тәрбияче шигырьне рәсемнәр күрсәтеп укый.)

Камил әле бик кечкенә,
Үрмәләп йөри инде,
Ә бәйрәмгә бүген менә
Ул «тәпи-тәпи» килде.

Балалар, малайның исеме ничек? (*Камил.*) (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар.) Камил зурмы, кечкенәме? (*Кечкенә.*) Камил ничек йөри? (*Үрмәләп.*) Камил бәйрәмгә үрмәләп килдеме, әллә «тәпи-тәпи» килдеме? (*«Тәпи-тәпи» килде.*) (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар.) «Тәпи-тәпи» ничек була ул, күрсәтегез әле. (Балалар тәрбияче белән йөреп күрсәтәләр.) Әйе, балалар, Камил зур үскән, тәпи йөри башлаган. Тәпи йөри башлаганчы, ул ничек йөргән?(*Үрмәләгән.*) (Активлаштыру.) Балалар, әйдәгез, келәмдә Камил кебек үрмәләп күрсәтегез әле. (Балалар үрмәлиләр.) Булдырдыгыз! Камил башта үрмәләгән, аннан йөри башлагач, аның аяклары ныгыган, биергә дә өйрәнгән, чыршы бәйрәменә килгән. Әйдәгез, без дә биеп алыйк. (Музыка яңгырый.)

Тып, тып итеп басабыз,
(Аякларны тыпырдатып басалар.)
Аннары әйләнәбез.
(Әйләнәләр.)
Башыбызны селкетәбез
(Ике кул белән башны тотып, башны уңга һәм сулга селкетәләр.)
Һәм сикереп алабыз.
(Сикерәләр.)

(Тәрбияче шигырьне тагын бер-ике тапкыр укый, шигырь укыганда, балалар үзләре дә катнашалар.) Булдырдыгыз, балалар, тиздән без дә Яңа ел бәйрәменә барырбыз. Әйдәгез,

кояш нурлары ясыйк әле. Кулларыгызны алга сузыгыз, бер-берегез белән кулга-кул тотышыгыз. Үзегезне җылы кояш нуры кебек тоемлап, тыныч кына басып торыгыз. Менә безнең бүлмәбезне нинди матур кояш яктырта. Аның җылысы нурлар аша бөтен бүлмәгә тарала. Бүлмәбез якты, җылы булсын!

## Тема. «КАРГА ӘЙТӘ» ЭНДӘШЕН УКУ

**Бурычлар:**

1) шигъри әсәрне аңлап кабул итүләренә ирешү, балаларның кошлар турында белемнәрен арттыру һәм ныгыту, аларның тышкы кыяфәтенә игътибар итү, сүз байлыгын арттыру; [к] һәм [қ] авазларының дөрес әйтелешенә ирешү;

2) балаларның игътибарын үстерү;

3) кошлар белән кызыксыну уяту.

**Җиһазлар:** мичкә куелган бәлеш һәм карга рәсеме; карга тавышы аудиоязмасы.

### Эшчәнлек барышы.

Тәрбияче. Балалар, тиздән нинди бәйрәм якынлаша? (*Яңа ел, чыршы бәйрәме.*) Әйе, балалар, тиздән Яңа ел бәйрәме җитә. Бәйрәмдә кунаклар килә, сез дә кунакка барасыз. Балалар, сез кунакка барырга яратасызмы? (Активлаштыру.) Кунаклар килүгә нәрсәләр пешерәләр? (Активлаштыру.) Әйе, кунаклар килгәч, бәлеш пешерәләр. Менә шундый бәлеш. (Рәсемнән күрсәтә.) Балалар, бәлеш исен карга да сизгән һәм кунакка килгән.

Тәрбияче эндәшне укый:

Карга әйтә: «Кар, кар,
Мичтә бәлеш бар, бар,
Мичтән бәлеш алыр идем,
Өйдә кунак бар, бар».

Балалар, карга нәрсә дип әйтә? (*«Кар-кар!»*) Әйдәгез, бергәләп кабатлыйбыз: «Карга әйтә: «Кар, кар!» Карга тагын нәрсә ди? (*Мичтә бәлеш бар, бар.*) Мичтән бәлеш алыр идем, өйдә кунак бар, бар. Әйдәгез, бергәләп кабатлыйбыз: «Мичтән бәлеш алыр идем, өйдә кунак бар, бар». (Тәрбияче эндәшне көйләп кабатлый. Балаларга да үзе белән бергә кабатларга куша.) Балалар, әйдәгез, уйнап алыйк әле. Мин эндәшне укыйм, ә сез һәр сүз саен карандаш белән идәнгә шакып алыгыз. (Һәр юлга дүрт шаку.) Балалар, әйдәгез, каргалар булып очып алыйк әле. Каргалар салмак кына, тыныч кына

очалар. (Балалар дулкын сыман хәрәкәтләр белән кулларын ян-яктан, учларын өскә каратып, баш очына күтәрәләр, учларын аска каратып төшерәләр.) Ә хәзер каргалар очалар, әйләнәләр. Кояш нурларында коеналар. Безгә рәхәт, җиңел, күңелле, иркен. Хәзер каргалар җиргә төшәләр. (Кулларын төшереп чүгәлиләр.)

## *Алтынчы бүлек.* КЫШ

### Тема. Ә. ЕРИКӘЙНЕҢ «БЕРЕНЧЕ КАР» ШИГЫРЕН УКУ

**Бурычлар:**

1) шигъри әсәрне аңлап кабул итүләренә ирешү, әсәр аша табигать дөньясына җәлеп итү, кышкы табигать турында мәгълүмат бирү; *йомшак, ап-ак* сыйфатлары хисабына сүз байлыгын арттыру һәм активлаштыру;

2) катлаулы сорауларга җавап бирү осталыкларын, хәтерен, уңай эмоцияләрен үстерү;

3) табигатькә мәхәббәт уяту.

**Җиһазлар:** кәгазьдән ясалган «кар бөртекләре».

**Эшчәнлек барышы.**

Тәрбияче. Балалар, хәзер елның кайсы вакыты? (*Кыш.*) Дөрес, кыш. Кыш көне урамда ничек була? (*Салкын була. Кар ява. Җил исә. Буран дулый.*) Балалар, кар нинди төстә? (*Ак.*) Ул катымы, әллә йомшакмы? (*Йомшак.*) Кар каян ява? (*Һавадан, күктән.*) Аны тотып буламы? (*Әйе.*) Хәзер мин сезгә кар турында шигырь укыйм.

Көне буе кар яуды,
Бөтен җирне каплады.
Ап-ак булды болыннар,
Ап-ак булды киң кырлар.

Балалар, җиргә нәрсә яуган? (*Кар.*) Нинди кар яуган? (*Ап-ак кар.*) Әйе, ап-ак кар яуган. (Тәрбияче «кар бөртекләрен» идәнгә яудыра.) Күрәсезме, монда күпме кар яуган. Бөтен җирне каплаган. (Тәрбияче бер «кар бөртеге»н ала һәм балаларга сорау бирә.) Бу нәрсә? (*Кар бөртеге.*) Әйе, кар бөртеге. Хәзер сез һәрберегез кар бөртекләрен алып биегез. (Музыка яңгырый.) «Кар бөртекләре»н чыршы төбенә куегыз да урыннарыгызга утырыгыз һәм шигырьне тагын бер кат тыңлагыз. (Тәрбияче балалардан шигырьнең кайбер сүзләрен әйттерә.)

Көне буе ... (*кар*) яуды,
Бөтен җирне ... (*каплады*).
Ап-ак булды ... (*болыннар*),
Ап-ак булды киң ... (*кырлар*).

Булдырдыгыз, балалар! Әйдәгез әле, чыршы төбеннән «кар бөртекләре»н алыгыз! Алар нинди матур, сырлы-сырлы, бизәкле! Хәзер аларны җепкә тезеп, гирлянда ясарбыз. Аны бүлмәгә элеп куярбыз. Безгә кергән һәр кеше аларны күреп сөенсен!

## Тема. Җ. ТӘРҖЕМАНОВНЫҢ «ЙОКЫ БАБАЙ» ӘКИЯТЕН СӨЙЛӘҮ

**Бурычлар:**
1) әкиятнең эчтәлеген аңлап кабул итүләренә ирешү;
2) балаларның игътибарын үстерү;
3) сорауларга дөрес җавап бирү омтылышы уяту.

**Җиһазлар:** кар белән капланган агачлар һәм өнендә йоклап ятучы аю рәсеме.

**Эшчәнлек барышы.**

Тәрбияче. Балалар, хәзер урамда кышмы, әллә җәйме? (*Кыш.*) Дөрес, балалар, хәзер кыш. Кыш икәнен каян белдегез? (*Кар ява, салкын.*) Балалар, кыш көне агачлар, күп кенә җәнлекләр йокыга талалар. Карагыз әле бу рәсемгә. (Тәрбияче балаларга кар белән капланган агачлар күрсәтә.) Бу рәсемдә агачлар кар белән капланган, алар шулай йоклыйлар. (Тәрбияче йоклаган аю рәсеме күрсәтә.) Бу рәсемдә аю үзенең өнендә тәмле йокыга киткән. Аюлар, шулай итеп, язга чаклы йокыга талганнар. Балалар, сез йокларга яратасызмы?(Активлаштыру.) Мин сезгә бүген йокларга яратмый торган бала турында әкият сөйлим.

(Тәрбияче «Йокы бабай» әкиятен сөйли. Балаларга сораулар бирә.) Баланың йокларга яратмаганын кем ишеткән? (*Йокы бабай.*) Йокламыйча бала дөрес эшләгәнме, сез ничек уйлыйсыз? (Активлаштыру.) Йокы бабай бала яныннан ни өчен китеп барган? (Активлаштыру.) Йокы бабай киткәч, мәчеләр нәрсә эшләгән?(*Мырылдаган.*) Әтәч, тавыклар нәрсә эшләгән? (*Йөгерешкәннәр.*) Сыерлар нәрсә эшләгән? (*Мөгрәгәннәр.*) Атлар нәрсә эшләгән? (*Кешнәгәннәр.*) Дуңгызлар нәрсә эшләгән? (*Мыркылдаганнар.*) Трактор нәрсә эшләгән? (*«Тыр-тыр» дигән.*) Ә кешеләр нәрсә эшләгән? (*Башларын мендәр астына тыкканнар.*) Балалар, Йокы бабай бала яны-

на тагын килгәнме? (Активлаштыру.) Әйе, бала үзенең йомшак мендәрен кочаклавы булган, Йокы бабай аның янына килеп тә җиткән. Йокы бабай «тылсымлы» таягын бер селтәп куйган һәм йокларга яратмаучы бала да, башка балалар да, әти-әниләр, әби-бабайлар, кошлар, хайваннар да йокыга чумганнар. Балалар, вакытында йокларга кирәк. Йокы ул файдалы, тынычландыра. Вакытында йокласагыз, сез бик тиз үсәрсез, акыллы булырсыз.

## Тема. С. ЛЕТОВАНЫҢ «КАР БАБАЙ» ХИКӘЯСЕН УКУ

**Бурычлар:**

1) күләме буенча зур булмаган әдәби әсәрне (хикәяне) күрсәтмәлелек кулланмыйча тыңлау һәм кабул итү, сорауларга аңлаешлы итеп җавап бирү осталыгын үстерүне дәвам итү, балаларның әңгәмә вакытында җиңел һәм иркен аралашуларына ирешү, сүз байлыгын арттыру;

2) игътибарны, бергәләп тыңлау күнекмәсен үстерү;

3) сүз сәнгате белән кызыксыну тәрбияләү.

**Җиһазлар:** уенчык кар бабай; фланелеграфта кар бабай рәсеме ясау өчен, ак төстәге төрле диаметрдагы өч түгәрәк, кишер, күмер, себерке сурәтләре.

### Эшчәнлек барышы.

Тәрбияче. Балалар, хәзер елның кайсы вакыты? (*Кыш.*) Дөрес, кыш. Кыш көне салкын була, кар ява, салкын җил исә. Балалар, кемдер ишек шакый. (Ишек шакыйлар.) Кем икән ул? (Тәрбияче уенчык кар бабай алып керә.) Балалар, кем килгән? (*Кар бабай.*) (Кар бабайны өстәлгә куя.) Мин дә бүген сезгә «Кар бабай» дигән хикәя укырмын. (Тәрбияче хикәяне укый. Укыганнан соң, балалар белән әңгәмә оештырыла.) Балалар, кардан нәрсә ясаганнар? (*Кар бабай.*) Борын урынына нәрсә куйганнар? (*Кишер.*) Күзләре урынына нәрсә ябыштырганнар? (*Күмер.*) Ә кар бабайның кулына нәрсә тоттырдылар? (*Себерке.*) Балалар, кар бабай ничек көлке килеп чыкты. Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: «көлке кар бабай». (Активлаштыру.) Балалар, Ира кар бабай янына эт баласы ясап куйган. Ул дөрес эшләгән. Кар бабай берүзе генә калгач курыкмасын өчен, Ира эт баласы ясап куйган. Менә, балалар, Ира — яхшы күңелле кыз. Ира нинди кыз? (*Яхшы күңелле.*) Әйе, яхшы күңелле. Тагын аны киң күңелле, йомшак күңелле дип тә әйтеп була. Мин дә сезнең яхшы күңелле булуыгызны телим.

## *Җиденче бүлек.* ӘТИЛӘР ҺӘМ ӘНИЛӘР, БАБАЙЛАР ҺӘМ ӘБИЛӘР

### Тема. Ш. МАННУРНЫҢ «ЯРАТАМ» ШИГЫРЕН УКУ

**Бурычлар:**

1) шигырьнең эчтәлеген аңлап кабул итүләренә ирешү; [ә] авазын дөрес әйтергә күнектерү;

2) балаларның игътибарын, кабул итү сәләтен үстерү;

3) әти-әниләргә, туганнарга мәхәббәт тәрбияләү.

**Җиһазлар:** гаилә рәсеме, курчаклар.

**Эшчәнлек барышы.**

Тәрбияче. Балалар, бүген безгә кунак килгән. (Тәрбияче курчак күрсәтә.) Балалар, бу нәрсә? (*Курчак.*) (Активлаштыру.) Балалар, курчак белән исәнләшегез әле. (Исәнләшәләр.) Гүзәл, кил әле, курчакның исемен сора. Курчак, синең исемең ничек? (*Әнисә.*) (Активлаштыру.) Балалар, Әнисә тартма алып килгән. Нәрсә алып килгән? (*Тартма.*) (Активлаштыру.) Әйдәгез, тартманы ачып карыйк әле. Тартма эчендә нәрсә бар? (*Рәсем.*) (Тәрбияче гаилә рәсемен мольбертка куя, балаларга карарга мөмкинлек бирә.) Балалар, бу рәсемдә әти, әни, абый, энекәш, бишектә ятучы сеңел сурәтләнгән. (Тәрбияче балаларны активлаштыра.) Марат, кил әле, әтине күрсәт. Бу кем? (*Әти.*) Әйдәгез, *әти* сүзен ягымлы итеп, әтием дип әйтегез әле. (Шул рәвешле, башкаларны да күрсәтеп һәм ягымлы итеп (*әнием, әбием, сеңлем*) әйтеп чыгалар.) Балалар, (рәсемгә күрсәтә) бу гаилә дус, тату. Алар күңелле яшиләр, бер-берсен бик яраталар. Балалар, мин сезгә тату гаилә турында бер шигырь укыйм.

Яратам мин үземне,
Әти белән әнине,
Абый белән энемне,
Бишектәге сеңлемне.

Шигырьдә кемнәр турында сөйләнә? (*Әти, әни, абый, энекәш, сеңел.*) Балалар, хәзер бу шигырьне тагын бер кат тыңлагыз. (Тәрбияче шигырьне икенче кат укый һәм балаларга үзе белән бергә кабатлап барырга тәкъдим итә.)

Яратам мин үземне,
Әти белән әнине,
Абый белән энемне,
Бишектәге сеңлемне.

Балалар, сезнең гаиләдә кемнәр бар?(Балаларның җаваплары.) Алсу, минем арттан кабатла әле: «Минем әтием бар». (Алсу кабатлый. Активлаштыру.) Алсу, синең әтиеңнең исеме ничек? (Башка балалар да әтиләренең исемен әйтәләр.) Гүзәл, кабатла әле: «Минем әнием бар». (Гүзәл кабатлый. Активлаштыру.) Гүзәл, синең әниеңнең исеме ничек? (Башка балалар да әниләренең исемен әйтәләр.) Әмир, кабатла әле: «Минем абыем бар». (Әмир кабатлый. Активлаштыру.) Дамир, кабатла әле: «Минем энем бар». (Дамир кабатлый. Активлаштыру.) Булат, кабатла әле: «Минем сеңлем бар». (Булат кабатлый. Активлаштыру.) Булдырдыгыз, балалар! Балалар, әти, әни, абый, энекәш, сеңел — бик якын кешеләр. Туганнарыгызны яратыгыз! Сез бүген сорауларга бик матур җавап бирдегез. Сез бик акыллылар. Алга таба да шундый булыгыз! Сезнең һәрберегезгә мин бүген елмайган кояш рәсеме бүләк итәм. Әйдәгез, бергәләшеп кояш нурлары ясыйк әле. Бер-берегез белән кулга-кул тотышыгыз. Үзегезне җылы кояш нуры кебек тоемлап, тыныч кына басып торыгыз. Менә безнең бүлмәбезне нинди матур кояш яктырта. Аның җылысы нурлар аша бөтен бүлмәгә тарала. Бүлмәбез тагын да якты, җылы була!

## Тема. «КӘККҮК—ЧЫПЧЫК» УЕНЫ

**Бурычлар:**

1) [ч] һәм [к], [к] авазларын дөрес һәм ачык итеп әйтергә өйрәтү, сүзлекне активлаштыру;

2) балаларның эмоциональлеген үстерү;

3) фольклор әсәрләре белән кызыксыну тәрбияләүне дәвам итү.

**Җиһазлар:** кәккүк һәм чыпчык рәсемнәре, кәккүк һәм чыпчык тавышлары аудиоязмасы.

### Эшчәнлек барышы.

Тәрбияче «Кәккүк — чыпчык» уены уйнаучы әти һәм малай рәсеме күрсәтә.

Т ә р б и я ч е . Балалар, бу рәсемдә кемнәрне күрәсез?(*Әти белән малай.*) (Активлаштыру.) Балалар, әти белән малай нишлиләр? (*Уйныйлар.*) Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: «уйныйлар». (Активлаштыру.) Дөрес, балалар, әти белән малай «Кәккүк — чыпчык» уены уйныйлар. Кәккүк һәм чыпчык — кошлар. Карагыз әле, менә алар. (Тәрбияче кәккүк һәм чыпчык рәсемен коврографка куя.) Бу кошның исеме —

кәккүк. (Тәрбияче кәккүк рәсеменә күрсәтә. Балалар «кәккүк» дип кабатлыйлар.) Балалар, аның тавышын тыңлап карагыз әле. (Күке тавышы ишетелә. Балалар әлеге тавышны башта күмәк, аннары индивидуаль рәвештә кабатлыйлар.) Ә бу кошның исеме ничек икән? (Тәрбияче чыпчык рәсеменә күрсәтә.) (*Чыпчык.*) Дөрес, чыпчык. Ул ничек кычкыра? (*«Чырык-чырык!»*) Балалар, әйдәгез, чыпчык тавышын да тыңлап карагыз әле. (Тыңлыйлар, хор белән һәм индивидуаль рәвештә кабатлыйлар.)

Балалар, «Кәккүк — чыпчык» уенын уйнаганда әйтелә торган сүзләрне тыңлагыз әле.

Кәккүк, чыпчык,
Тәрәзәдән очып чык,
Галиянең өстенә
Матур күлмәк биреп чык.

Тәрбияче балаларга «Кәккүк — чыпчык» уенының тәртибен өйрәтә. Бер баланы арка кочып, алга-артка селкенү хәрәкәтләре ясап, уен үткәрә.

Кәккүк, чыпчык,
Тәрәзәдән очып чык,
Галиянең өстенә
Матур күлмәк биреп чык.

Аннары тагын бер баланы чакыра, ә калганнары, үзләре утырып, алга-артка селкенү хәрәкәтләре ясап, тәрбияче белән бергә кабатлыйлар.

Тәрбияче. Балалар, бу уенны өйдә әтиләрегез белән уйный аласыз. Әтиләрегез сезне күтәреп тә, җилкәләренә утыртып та йөриләр. Сезнең әтиләрегез көчле. Алар сезне яраталар. Сезнең белән уйныйлар. Сез аларга, өйгә кайткач, «Кәккүк — чыпчык» уенын өйрәтегез һәм бергәләп уйнагыз.

## Тема. Г. ТАҺИРОВАНЫҢ «ЙОКЛА, КУРЧАК» ШИГЫРЕН УКУ

**Бурычлар:**

1) шигырьнең эчтәлеген аңлап кабул итүләренә ирешү, шигырьне [ә], [ү] авазларын дөрес әйтергә күнектерү;

2) балаларның игътибарын үстерү;

3) курчакка карата кайгыртучанлык тәрбияләү.

**Җиһазлар:** коляскада йокларга яткырылган курчак, һәр балага берәр курчак.

**Эшчәнлек барышы.**

Эшчәнлек уен почмагында үткәрелә. Коляскага курчак салынган.

Тәрбияче. Балалар, Мәрьямне йоклатырга кирәк. Аның йокысы килгән. Ә ни өчен йоклыйлар? (*Үсәр өчен, ял итәр өчен* һ.б.) Дөрес, балалар, үсәр өчен, ял итәр өчен йокларга кирәк. Ә сезне кем йоклата? Кич белән әниләрегез, әтиләрегез сезне йокларга яткыралар, сезне тирбәтәләр, бишек җырлары җырлыйлар, әкиятләр сөйлиләр, шигырьләр укыйлар. Алар сезнең турыда кайгырталар. Балалар, сез әле кечкенә. Сез әле йөри дә белмәгәндә, кем сезне күтәреп йөртте? Әйе, әти-әниләрегез. Әти-әниләрнең куллары көчле, ышанычлы, әти-әниләрегез турында нинди матур сүзләр әйтә аласыз? (Балаларның җаваплары.) Әйе, алар бик матурлар, тырышлар. Сез аларны бик мактадыгыз. Ә хәзер, әйдәгез, курчак йоклап китсен өчен, бер матур шигырь укыйк. (Тәрбияче шигырьне укый. Шигырьне укыганда, коляскаåны әкрен генә тирбәтеп тора.) Менә, балалар, Мәрьям йоклап китте. (Тәрбияче шигырьне икенче тапкыр укый.) Хәзер сез һәрберегез үзегезнең курчакларыгызны кулларыгызга алып тирбәтегез. Сезнең курчакларыгыз да йокласын. (Тәрбияче курчакны, кулга алып, ничек тирбәтергә кирәклеген күрсәтә.) Әйдәгез, бергәләп «бәлли-бәлли-бәү» дип җырлагыз! Менә шулай! Курчаклар йоклап китте. Алсуның да курчагы йоклый. Маратның да курчагы йоклый. Әйдәгез, аларны караватка салыгыз! Булдырдыгыз, балалар! Сез дә үзегезнең курчакларыгызны йоклата алдыгыз. (Тәрбияче шигырьне өченче кат укый. Шигырьне өченче тапкыр укыганда, тәрбияче *курчак, бәлли-бәлли-бәү, үсә* кебек сүзләрне кабатларга куша.) Балалар, әйдәгез, курчакларга тыныч йокы телик. Тыныч йокы сезгә, курчаклар. Аяк очларына басып, тыныч кына уен почмагыннан чыгыйк.

## Тема. Ә.КАРИНЫҢ «ТАВЫК» ШИГЫРЕН УКУ

**Бурычлар:**

1) шигъри әсәрне тыңларга өйрәтүне дәвам итү, фланелеграфта шигырь эчтәлегенә туры килгән рәсемнәр яки уенчыклар күрсәтү, кайбер фразаларны кабатлатып, балаларның сөйләмен активлаштыру;

2) балаларның игътибарын, кабул итү сәләтен, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;

3) әбиләргә карата ихтирам, ярату хисләре тәрбияләү.

**Җиһазлар:** уенчык тавык.

**Эшчәнлек барышы.**

Тәрбияче. Балалар, матур итеп утырыгыз әле. Менә минем кебек. Булдырдыгыз! Сез ишетәсезме? Нindидер тавыш бар. (Ширма артыннан тавык кытаклаган тавыш ишетелә.) Барып карыйм әле. (Тәрбияче әби белән керә.) Исәнмесез, балалар. (*Исәнмесез!*) Балалар, әби сезгә тартма алып килгән. Карагыз әле. (Тартма күрсәтә.) Бу нәрсә? (*Тартма.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, тартмада нәрсә бар икәнен аны ачып карамыйча әйтеп буламы? (*Юк.*) Әйдәгез, тартманы ачып карыйк. (Тәрбияче тартманы ача, аннан уенчык тавыкны ала.) Балалар, әби безгә нәрсә алып килгән? (Балаларның җаваплары.) Балалар, тавык әбинең ишегалдында яши. Әби тавык турында кайгырта, аны ярма белән сыйлый. Ә тавык, әбигә рәхмәт әйтеп, йомырка сала. Балалар, хәзер әби белән тавык турында мин сезгә шигырь укыйм. Ә син, әби, утырып тор, шигырьне тыңла. (Тәрбияче шигырь укый.) Балалар, бу шигырь нәрсә турында? (Активлаштыру.) Әйе, бу шигырь тавык турында. Тавык ничек кычкыра? (*«Кыт-кытыйк!»*) (Активлаштыру.) Дөрес, тавык «кыт-кытыйк» ди. Ул кытаклый. Тавык нәрсәгә шатлана?(Активлаштыру.) Йомырканы кемгә килеп алырга кушкан? (*Әбигә.*) Игътибар белән тыңлагыз әле, шигырьне мин тагын бер тапкыр укып чыгам. (Тәрбияче шигырьне укый. Укыганда, балаларга аерым сүзләрне кабатларга куша.)

Кытаклап чыкты ... (*тавык*),
Кытаклый ул ... (*мактанып*).
Нәрсәгә бик шатланган?
Чөнки ул ... (*күкәй*) салган.
«Әби килеп алсын, ди,
Балалар куансын»,— ди.

Балалар, әбиләр тәмле ризыклар пешерәләр, авылда яшәүче әбиләр кош-кортларны, хайваннарны тәрбиялиләр. Алар — бик зирәк кешеләр. Уеннар да беләләр. Оныклары белән уйнарга яраталар. Кунакка килгән әби сезгә бер уен күрсәтә.

Әби. Балалар, әйдәгез, бармаклардан тавык ясап карыйк әле. Учларыгызны менә шулай итеп (горизонталь) куегыз. Аннары баш һәм имән бармаклар кушылып, тавыкның күзен ясыйлар. Башка бармаклар, берсе өстенә берсе куелып, яртылаш бөгелгән хәлдә калалар.

Тавык бер күкәй салды,
«Чыгып алыгыз»,— диде.

Рәхмәт, синҗа, әби. Әбиләр безгә бик кадерле. Без аларны яратабыз. Аларга озын гомер телибез. (Балалар кул чабалар.)

## Тема. Э. ШӘРИФУЛЛИНАНЫҢ «ИҢ МАТУР ӘНИ» ШИГЫРЕН УКУ

**Бурычлар:**

1) шигъри әсәрне тыңларга өйрәтүне дәвам итү, кайбер фразаларны кабатлатып, балаларның сөйләмен активлаштыру;

2) балаларның игътибарын, кабул итү сәләтен, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;

3) әниләргә карата ихтирам, ярату хисләре тәрбияләү.

**Җиһазлар:** мольберт, елмаеп торган кояш рәсеме.

### Эшчәнлек барышы.

Тәрбияче. Балалар, тиздән әниләр бәйрәме җитә. Бу бәйрәмгә бар кеше дә әзерләнә. Әниләр бәйрәмен яз көне билгеләп үтәләр. Балалар, без бүген сезнең белән әниләр турында шигырь укырбыз.

Минем әни бу дөньяның
Иң чибәре, сылуы.
Нинди бәхет —
Һәр баланың
Үз әнисе булуы!

Балалар, бу шигырь кем турында? (*Әниләр турында.*) (Активлаштыру.) Балалар, әниләр нинди? (*Чибәр. Сылу.*) Балалар, бергәләп кабатлыйк әле: «чибәр, сылу». (Активлаштыру.) Әйе, балалар, сезнең һәрберегезнең әнисе бар. Сез бәхетле балалар. Нинди бәхет — һәр баланың үз әнисе булуы! Балалар, бергәләп кабатлыйк әле: «Нинди бәхет — һәр баланың үз әнисе булуы!» (Активлаштыру.) Балалар, шигырьне тагын укыйм. Сез игътибар белән тыңлагыз. (Тәрбияче шигырьне тагын ике тапкыр укый.) Булдырдыгыз, балалар! Мин сезнең өчен бик шат. Сезгә бүген дә кояш елмая. (Тәрбияче мольбертка кояш рәсемен куя.) Безнең әниләребез дә кояш кебек якты, җылы, ягымлы. Әйдәгез, кояш нурлары ясап, әниләргә җибәрик. Кулларны алга сузыйк, кулга-кул тотышыйк. Үзебезне җылы кояш нуры кебек тоемлап, тыныч кына басып торыйк. Менә безнең бүлмәбезне нинди матур кояш яктырта! Аның җылысы нурлар аша бөтен бүлмәгә тарала. Бүлмәбез тагын да якты, җылы була!

## *Сигезенче бүлек.* ХАЛЫК ИҖАТЫ

### Тема. «ЙОМРЫ ИКМӘК» РУС ХАЛЫК ӘКИЯТЕН УКУ

**Бурычлар:**

1) балаларны «Йомры Икмәк» әкияте белән таныштыру, әкиятнең эчтәлеген аңларга ярдәм итү, шар әвәләү күнекмәсен ныгыту, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;

2) кабул итү сәләтен, игътибарны үстерү;

3) әкиятләр белән кызыксындыру.

**Җиһазлар:** тәлинкәгә салынган камыр кисәкләре, фланелеграф яки коврограф, әкият эчтәлегенә туры килгән рәсемнәр.

**Эшчәнлек барышы.**

Тәрбияче һәр балага, тәлинкәгә салып, камыр кисәкләре биреп чыга. Камыр балаларның кулына ябышырлык булырга тиеш түгел.

Тәрбияче. Балалар, карагыз әле, сезнең алдыгызга куелган тәлинкәләргә нәрсә салынган икән? Алып карагыз әле. Балалар, бу — камыр. Әйдәгез, бергә кабатлыйк әле: «камыр». (Активлаштыру.) Балалар, камыр нәрсә өчен кирәк? (Балаларның җаваплары.) Дөрес, балалар, камыр тәмле әйберләр: өчпочмак, пәрәмәч, токмач пешерер өчен кирәк. Хәзер камыр кисәкләрен яңадан тәлинкәгә куегыз. Бүген мин сезгә Йомры Икмәк турында әкият сөйлим. Тыңлап карагыз әле. (Тәрбияче әкият сөйли. Сөйләгәндә, фланелеграфта (коврографта) рәсемнәр күрсәтә. Балаларга сораулар бирә, уй-кичерешләре белән уртаклашырга мөмкинлек бирә.) Ни өчен Йомры Икмәк качып киткән? (*Аның үзенә генә күңелсез булгандыр. Үзенә уйнарга иптәш эзләгәндер* һ.б.) (Әкиятне тагын бер тапкыр сөйли. Сөйләгәндә, Йомры Икмәкнең җырын балалар белән бергә җырлыйлар.) Әйдәгез, тәлинкәдәге камыр кисәкләрен алып, шар ясыйк әле. Сез дә Йомры Икмәк әвәләп карагыз. (Тәрбияче шар әвәләргә өйрәтә. Үзе күзләрен, авызын ясый.) Балалар, җәнлекләр ашамасын өчен, Йомры Икмәкне алып куйыйк. (Кич белән өйләренә алып китәләр.) Булдырдыгыз, балалар! (Балалар кул чабалар.)

### Тема. «ЙОМРЫ ИКМӘК» РУС ХАЛЫК ӘКИЯТЕН КАБАТЛАУ

**Бурычлар:**

1) әкиятне тәрбияче белән бергә сөйләргә өйрәтү, аерым фразаларны кабатлатып, балаларның сүз байлыгын активлаштыру;

2) балаларның игътибарын, кабул итү сәләтен үстерү;

3) әкият геройлары белән кызыксындыру.

**Җиһазлар:** «тылсымлы» капчык яки тартма, Йомры Икмәк җырының аудиоязмасы, өстәл театры өчен Йомры Икмәк, әби, бабай, куян, төлке, аю фигуралары яки рәсемнәр, өй макеты.

**Эшчәнлек барышы.**

Тәрбияче. Балалар, безгә бүген кунак килгән. Ул менә бу «тылсымлы» капчык (яки «тылсымлы» тартма) эченә кереп яшерелгән. Капчыкны ачып карамыйча гына, аның эчендә нәрсә барлыгын әйтеп буламы?(*Юк.*) Дөрес, әйтеп булмый. Балалар, кунагыбыз, җыр җырлап күрсәтәм әле, бәлки, мине кызлар һәм малайлар танырлар, ди. Тыңлап карыйк әле. (Тәрбияче Йомры Икмәк исеменнән үзе җырлый яки аудиоязма куя.)

Мин келәттән себерелгән,
Каймакка басылган,
Камырдан ясалган.
Әбидән дә качтым мин,
Бабайдан да качтым мин...

Балалар җырлаучының Йомры Икмәк икәнен ачыклыйлар һәм аны «тылсымлы» капчык эченнән алалар.

Тәрбияче. Балалар, Йомры Икмәкне кем ясаган? (*Әби белән бабай.*) Йомры Икмәкне нәрсәдән ясаганнар? (*Камырдан.*) Әйе, балалар, әби белән бабай, камырдан икмәк ясап, аны тәрәзә төбенә киптерергә куялар. Кипкәч, икмәк тәрәзәдән сикереп төшә һәм тәгәрәп китә, тәгәри-тәгәри, урманга җитә. Урманда аңа нәрсә очрый? (*Куян.*) (Балалар персонажларны әйтәләр, тәрбияче аларга туры килгән уенчыкларны яки өстәл театры җыелмасыннан тиешле фигураларны алып куя бара, һәм балалар белән әкият сөйләүне дәвам итәләр.) Балалар, әйдәгез, барыгыз да, Куян булып, Йомры Икмәк белән сөйләшегез әле. Куян әйтә: «Хәзер мин сине ашыйм!» (Барысы бергә әйтәләр.) Әйдәгез, хәзер Йомры Икмәк булыгыз. Ул нәрсә ди? «Син мине ашама, башта мин сиңа бер җыр җырлыйм!» (Балалар җырлыйлар.)

Мин келәттән себерелгән,
Каймакка басылган,
Камырдан ясалган.
Әбидән дә качтым мин,
Бабайдан да качтым мин,
Синнән качам да качам!

Т э р б и я ч е. Шулай итеп, Йомры Икмәк Куяннан качып китә. Йомры Икмәккә нәрсә очрый? (*Аю.*) Әйдәгез, хәзер барыгыз да Аю булып күрсәтегез әле! Аю Йомры Икмәккә нәрсә ди? Бергәләп әйтегез әле! (*«Мин сине ашыйм!» — ди.*) Йомры Икмәк нәрсә ди? (*«Син мине ашама, мин сиңа җыр җырлармын!» — ди.*) (Бергәләп җырлыйлар.)

Мин келәттән себерелгән,
Каймакка басылган,
Камырдан ясалган.
Әбидән дә качтым мин,
Бабайдан да качтым мин,
Куяннан да качтым мин,
Синнән качам да качам!

Йомры Икмәк качып китә. Бара-бара, Төлкегә очрый. Әйдәгез, хәзер Төлке булып күрсәтегез әле! Ул хәйләкәр, ялагай. Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: «хәйләкәр, ялагай». Төлке нәрсә ди? (*«Мин сине ашыйм!» — ди.*) (Бергәләп әйтәләр.) Йомры Икмәк нәрсә ди? (*«Син мине ашама, хәзер мин сиңа бер җыр җырлыйм».*)

Мин келәттән себерелгән,
Каймакка басылган,
Камырдан ясалган.
Әбидән дә качтым мин,
Бабайдан да качтым мин,
Куяннан да качтым мин,
Аюдан да качтым мин,
Синнән качам да качам!

(Бергәләп җырлыйлар.) Ә Төлке нәрсә дигән соң? (Берәр активрак баладан сорарга була.) Кем Йомры Икмәк белән Төлке кебек сөйләшеп күрсәтә?

Бер бала Төлке роленә керә.

Т ө л к е. Һай, матур да җырлыйсың икән! Яле, якынрак килеп, минем борын очына утырып, тагын бер җырлап бир әле!

Т э р б и я ч е. Йомры Икмәк, якынрак килеп, тагын җырлаган. Әйдәгез, Йомры Икмәк булып җырлагыз әле. (Балалар җырлыйлар.) Хәйләкәр Төлке аны капкан да йоткан. Шуның белән әкият тә беткән. Балалар, сез «Йомры Икмәк» әкиятен тыңладыгыз. Үзегез дә миңа әкиятне сөйләргә булыштыгыз. Булдырдыгыз, балалар! (Балалар кул чабалар.)

## Тема. «ТЕРЕМКӘЙ» РУС ХАЛЫК ӘКИЯТЕН УКУ

**Бурычлар:**

1) балаларны яңа әсәр белән таныштыру, әкиятне аңлап кабул итүләренә ирешү;

2) балаларның игътибарын үстерү;

3) халык иҗаты белән кызыксыну тәрбияләү.

**Җиһазлар:** өстәл театры фигуралары (куян, бака, тычкан, бүре, аю) яки фланелеграфта (коврографта) күрсәтү өчен әкият персонажларының сурәтләре.

### Эшчәнлек барышы.

Бу әкиятне балаларга уку түгел, ә сөйләү отышлырак булыр. Тәрбияче башта әкиятне күрсәтмәлелектән башка гына сөйләп чыга. Балаларга әкиятнең эчтәлеге буенча үз кичерешләрен белдерергә мөмкинлек бирә.

Тәрбияче. Балалар, әкият сезгә ошадымы?(Активлаштыру.) Әкияттә нинди хайваннар очрады? (Активлаштыру.) Әкияттәге Куян, Бака, Тычкан, Бүре, Аю дус яшәгәннәрме? (Активлаштыру.) Әйе, балалар, өйдә, гаиләдә дус яшәргә кирәк. (Әкиятне икенче кат сөйләгәндә, өстәл театры фигуралары кулланыла яки фланелеграфта (коврографта) әкият персонажларының сурәтләре күрсәтелә.)

## Тема. «ТЕРЕМКӘЙ» ӘКИЯТЕН СӘХНӘЛӘШТЕРҮ

**Бурычлар:**

1) әкият белән таныштыруны дәвам итү, сәхнәләштерү эшчәнлегенә җәлеп итү, уен барышында фразаларны дөрес әйтү осталыгын үстерү;

2) балаларның хәтерен, активлыгын үстерү;

3) әкиятләр белән кызыксыну тәрбияләү.

**Җиһазлар:** куян, бака, тычкан битлекләре, куян, бака, тычкан, бүре, аю костюмнары; рус бию көе аудиоязмасы.

### Эшчәнлек барышы.

Тәрбияче уен бүлмәсенә костюмнар алып керә. Куян битлеге кия.

Тәрбияче. Балалар, мин хәзер нәрсә булдым? (*Куян.*) Дөрес, Куян-Куркаккай. Күрсәтегез әле, нинди була ул куян? (Балалар күрсәтәләр.) Ә хәзер мин нәрсә булдым?(Бака битлеге кия.) Дөрес, Бака-Бакылдык. (Ул авызын зур итеп ача да бакылдый башлый.) Балалар, күрсәтегез әле, бака ничек кычкыра? (*«Бака-как!»*) Балалар, ә бу нәрсә икән соң? (Тычкан битлеге күрсәтә.) (*Тычкан.*) Дөрес, Тычкан-Чыелдык. Ул

чыелдый: «чи-чи-чи» килә. «Чи-чи-чи» дип кабатлагыз әле! (Балалар кабатлыйлар.) Балалар, безнең нәрсәләр бар? (*Куян-Куркаккай, Бака-Бакылдык, Тычкан-Чыелдык.*) Бик дөрес. Алар кайсы әкияттән әле? (*«Теремкәй» әкиятеннән.*) Дөрес, алар «Теремкәй»дә яшиләр. Тыңлыйсызмы, мин сезгә аны сөйлим. Җайлап утырыгыз. (Балалар келәмгә утыралар һәм әкият тыңлыйлар.) Сезгә әкият ошадымы? Әйдәгез, хәзер «Теремкәй» әкиятен уйнап күрсәтик. Башта, урындыкларны ярымтүгәрәк ясап куеп, «теремкәй» төзибез. (Тәрбияче балаларга ярдәм итә.) Балалар, кемнең Тычкан-Чыелдык буласы килә? Кем Бака-Бакылдык? Кем Куян-Куркаккай була? Кем Төлке-Хәйләбай? Ә кем Бүре-Сорыколак була? Балалар, бүре усалмы? (*Усал.*) Ул кычкырамы? (*Әйе.*) Балалар, бүре кычкыра дип түгел, ә бүре улый диләр. Бүре нәрсә эшли? (*Улый.*) Ул улаганда нинди аваз чыгара? (*«У-у-у!»*) Кабатлагыз әле: «у-у-у». Кемнең Аю-Камытаяк буласы килә?

Тәрбияче, рольләрне бүлеп бетергәч, балаларга костюмнар кияргә куша, аннары әкиятне сөйли башлый, кирәк булса, балаларга ярдәм итә. Сәхнәләштерү ахырында, яңа «теремкәй»не котлап, балалар рус халык көенә биеп алалар. Уен тәмамлангач, костюмнар берникадәр вакытка уен бүлмәсендә калдырыла. Теләгән балалар, аларны киеп, әкиятне уйный алалар.

## *Тугызынчы бүлек.* ЯЗ

### Тема. Ш. ГАЛИЕВНЕҢ «ЯЗ» ШИГЫРЕН УКУ

**Бурычлар:**

1) балаларның шигъри әсәрне аңлап кабул итүләренә ирешү, язгы табигать турында мәгълүмат бирү, [т] авазын, *тып* аваз ияртемен дөрес әйтергә күнектерү, сүз байлыгын киңәйтү һәм активлаштыру;

2) балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын, кызыксынучанлыгын үстерү;

3) язгы табигать күренешләре белән соклану хисе тәрбияләү.

**Җиһазлар:** язны, тамчылар тамганны сурәтләгән рәсем, «Яз җитә» җырының аудиоязмасы.

**Эшчәнлек барышы.**

Тәрбияче. Балалар, хәзер урамда яз. Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: «Яз килде». (Активлаштыру.) Яз турында сез нәрсәләр беләсез? (*Җылы, кояш елмая, кар эри, тамчы-*

*лар тама, сулар җыела.*) Балалар, ә менә бу рәсемгә игътибар белән карагыз әле. (Тәрбияче язны, тамчылар тамганны сурәтләгән рәсем күрсәтә.) Рәсемдә нәрсәләр күрәсез? (*Яз, кояш елмая, тамчылар тама, сулар җыелып тора.*) Әйе, яз ул менә шундый була, тыңлагыз әле!

Туктап сана,
Тамчы тама:
Тып, тып, тып!
Төшә-төшә,
Бозны тишә:
Тып, тып,тып.
Яз бу, ишет,
Кага ишек:
Тып, тып, тып!

Балалар, яз көне түбәдән нәрсә тама? (*Тамчы.*) Ул нинди тавыш чыгара? (*«Тып-тып».*) Алсу, тамчы нәрсә ди? (*«Тып-тып».*) Марат, тамчы ничек итеп җырлый? (*«Тып-тып».*) (Шигырьне икенче кат укый.)

Туктап сана,
Тамчы тама:
Тып, тып, тып.

(Тәрбияче белән бергә бер кул учына икенче кулның имән бармагы белән кагалар.)

Төшә-төшә,
Бозны тишә:
Тып, тып,тып.

(Икенче кулның учына бармак белән кагалар.)

Яз бу, ишет,
Кага ишек:
Тып, тып, тып.

(Аяклар белән тыпырдыйлар. Ахырдан «Яз җитә» җыры яңгырый. Балалар бииләр.)

## Тема. «ТОР-ТОР, ТУРГАЙ» ТАКМАГЫН УКУ

**Бурычлар:**

1) такмакның эчтәлеге белән таныштыру, [т] авазын дөрес әйтергә күнектерү, аваз ияртемнәре хисабына балаларның сүз байлыгын арттыру;

2) кабул итү сәләтен, игътибарны, хәтерне үстерү;

3) фольклор әсәрләре белән кызыксыну тәрбияләүне дәвам итү.

**Җиһазлар:** тургай һәм чыпчык рәсемнәре, тургай һәм чыпчык тавышлары аудиоязмасы.

**Эшчәнлек барышы.**

Тәрбияче иртәне күрсәтә: кояш чыга, кошлар уяна. Шушы күренешкә туры килгән музыка куярга була.

Тәрбияче. Балалар, мин сезгә бер такмак укыйм.

Тор-тор, тургай!
(Коврографка тургай рәсеме куя.)
Таң, таң ата бугай.
Син дә кил, чыпчык!
(Чыпчык рәсеме куя.)
Чырык, чырык, чырык.

Балалар, такмакта кайсы кошлар турында сүз бара? (*Тургай, чыпчык.*) (Активлаштыру.) Әйе, балалар, кошлар — тургайлар, чыпчыклар — йокыдан уяндылар. Таң атуга шатланалар, канатларын кагалар. (Тәрбияче такмакны тагын бер кат укый. Балалар белән бергә кош тавышларын кабатлыйлар.) Әйдәгез, кошлар, тургайлар, чыпчыклар булып уйнап алыйк әле.

Кош канатларын кага,
(Канатлар кебек итеп, салмак кына кулларын җилпиләр.)
Җиргә төшеп, җим чүпли.
(Уң кулның баш, имән, урта бармагыннан «томшык» ясыйлар һәм сул кулның учыннан җим чүплиләр.)
Ботаклар җыя,
(Вак ботаклар җыялар.)
Кош оя ясый.
(Бармакларын бер-берсенә кертеп, «оя» ясап күрсәтәләр.)

Балалар, булдырдыгыз! Матур итеп уйнадыгыз. Әйдәгез, үзебезне мактап кул чабыйк әле. (Балалар кул чабалар.)

## Тема. «ТУК-ТУК, ТУКРАН...» ЭНДӘШЕН УКУ

**Бурычлар:**

1) шигъри текстны тыңлау осталыгы формалаштыру, кошлар белән таныштыруны дәвам итү, аваз иярткемнәрен кабатлату; [т], [к] һәм [к] авазлары кергән сүзләрне дөрес әйтергә өйрәтү;

2) балаларның игътибарын үстерү;

3) кошларга карата шәфкатьлелек тәрбияләү.

**Җиһазлар:** тукран рәсеме, бәлеш рәсеме, тукран тавышы аудиоязмасы.

**Эшчәнлек барышы.**

Тәрбияче кечкенә чүкеч белән өстәлгә шакый.

Тәрбияче. Ишетәсезме, чүкеч шакыганда нинди тавыш ишетелә? Ул «тук-тук-тук» дип шакый. (Балалар өстәлгә шакып карыйлар.) Балалар, «тук-тук» дигән тавышны башка җирдә ишеткәнегез бармы? Кайда ишеткәнегез бар? (*Урманда.*) «Тук-тук» дип урманда нинди кош шакылдый? (*Тукран.*) (Тәрбияче коврографка тукран рәсеме куя яки уенчык, муляж күрсәтә.) Менә ул — тукран. (*Тукран* сүзен кабатлыйлар.) Балалар, тукран тавышын тыңлап карагыз әле. (Тәрбияче аудиоязманы тыңлата.) Әйдәгез, тукран чыгарган тавышны кабатлагыз әле: *«тук-тук-тук!»* (Тәрбияче эндәшне укый.)

Тук-тук, тукран,
Тукылдатып утырам,
Мичтә бәлеш пешәме?
Шуны көтеп утырам.

Эндәшне ике тапкыр укыйлар. Бу очракта күрсәтмәлелек кулланыла, фланелеграфта (коврографта) бәлеш рәсеме күрсәтелә. Балалар эндәшнең эчтәлегенә туры китереп хәрәкәтләр ясыйлар. Тәрбияче артыннан эндәшне кабатлыйлар.

## Тема. «КОЯШ, ЧЫК, ЧЫК!» ЭНДӘШЕН УКУ

**Бурычлар:**

1) балаларга эндәшнең эчтәлеген аңларга, сюжетны истә калдырырга ярдәм итү;

2) балаларның тыңлый белү осталыгын, уңай эмоцияләрен үстерү;

3) күмәк эшчәнлек белән кызыксындыру.

**Җиһазлар:** болытлар артыннан чыгып килүче кояш, казанда пешә торган ботка, базарга баручы әти, кашык рәсемнәре.

**Эшчәнлек барышы.**

Тәрбияче фланелеграфта рәсемнәр күрсәтә: болытлар артыннан чыгып килүче кояш, казанда пешә торган ботка, кашык, базарга баручы әти.

Тәрбияче. Балалар, рәсемдә сез нәрсә күрәсез? (*Болытлар.*) Кояш кайда? (*Кояш болытлар артына качкан.*) Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк: «Кояш болытлар артына качкан». (Активлаштыру.) Әйдәгез, кояшны чакырыйк. (Тәрбияче эндәшне укый һәм фланелеграфта күрсәтеп бара.)

Кояш, чык, чык, чык,
Майлы ботка казанда,
Тәти кашык базарда.
Әти китте базарга,
Тәти кашык алырга.
Тәти кашык саф алтын,
Кирәкми безгә салкын!

Тәрбияче эндәшне өч тапкыр кабатлый, күрсәтмәлелеккә мөрәҗәгать итә. Аннары эндәшне балалар белән бергәләп кабатлыйлар.

Кояш ... (*чык,чык,чык*),
Майлы ботка ... (*казанда*),
Тәти кашык ... (*базарда*).
Әти китте ... (*базарга*),
Тәти кашык ... (*алырга*).
Тәти кашык ... (*саф алтын*),
Кирәкми безгә ... (*салкын*)!

Тәрбияче эндәшнең башын әйтә, балалар дәвам итәләр. Тәрбияче, актив катнашкан балаларны мактап, фланелеграфка елмайган кояш рәсеме куя.

## Тема. Р. БАТУЛЛАНЫҢ «НУРБӘК» ӘКИЯТЕН УКУ

**Бурычлар:**

1) әкиятне игътибар белән тыңларга өйрәтүне дәвам итү; [а], [у], [ә] сузык авазларын дөрес әйтергә күнектерү, уенчыкларда әкият персонажларын танырга һәм атарга өйрәтү;

2) балаларның игътибарын үстерү;

3) әкият геройлары белән кызыксыну тәрбияләү.

**Җиһазлар:** фланелеграф, бака, каз һәм бозау сурәтләре яки өстәл театры фигуралары.

### Эшчәнлек барышы.

Тәрбияче, ашыкмыйча гына, әкиятне сөйли. Сөйләгәндә, өстәл театры фигуралары ярдәмендә күрсәтеп бара. Сөйләп бетергәч, тәрбияче әкият персонажларының кычкырганда барлыкка килгән тавышларын кабатларга куша.

Тәрбияче. Казлар ничек каңгылдый? (*«Ка-ка-ка!»*) Бозау ничек кычкыра? (*«Му-у-у!»*) Бака ничек сайрый? (*«Курыйк-курыйк!» «Бака-ка!»*) Балалар, ни өчен бака казларга, бозауга сәлам әйтеп җибәргән? (*Казлар да, бозау да ба-*

*кага сәлам әйткәннәр.*) Дөрес, җәнлекләр дә, кошлар да, кешеләр дә бер-берсен сәламлиләр, бер-берсенә сәламәтлек телиләр. Балалар, әйдәгез, сез дә баканы сәламләгез! (*Сәлам, бака!*) (Активлаштыру.) Балалар, бака да сезне сәламли: «Курыйк-курыйк», «Бака-ка!» Әйдәгез, бозауга сәлам әйтегез! (*Сәлам, бозау!*) (Активлаштыру.) Бозау да сезне сәламли: «Му-у-у!» — ди. Казларны да сәламләгез әле! (*Сәлам, казлар!*) (Активлаштыру.) Казлар да сезне сәламлиләр: «Ка-ка-ка!» — диләр. Шулай итеп, бака да, бозау да, казлар да сезнең исән-сау булып үсүегезне телиләр. Исән-сау булыгыз, акыллы балалар булып үсегез!

## Тема. К. УШИНСКИЙНЫҢ «КАЗЛАР» ХИКӘЯСЕН УКУ

**Бурычлар:**

1) казларны һәм үрдәкләрне аера белергә өйрәтү, хикәяне күрсәтмәлелек кулланмыйча, аңлап кабул итүләренә ирешү, күплек һәм берлек сандагы исемнәрне аерырга һәм дөрес кулланырга күнектерү;

2) балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын, хәтерен, тәрбияченең күрсәтмәләрен үти алу осталыгын үстерү;

3) йорт кошлары белән кызыксындыру.

**Җиһазлар:** уенчык үрдәк һәм каз; каз һәм казлар рәсеме; кәгазь бите; балалар санынча яшел карандашлар.

### Эшчәнлек барышы.

Балалар алдында уенчык үрдәк һәм каз.

Тәрбияче. Алмаз, казны күрсәт әле. Син нәрсә күрсәттең? (*Каз.*) Балалар, Алмаз нәрсә күрсәтте? (Активлаштыру.) Алия, үрдәкне күрсәт әле. Син нәрсә күрсәттең? (*Үрдәк.*) Балалар, Алия нәрсә күрсәтте? (Активлаштыру.) Балалар, каз ничек кычкыра? (*«Ка-ка-ка!»*) Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: «ка-ка-ка!» Балалар, бу нәрсә? (Каз рәсеме күрсәтә.) (*Каз.*) Балалар, бу нәрсә? (Казлар рәсеме күрсәтә.) (*Казлар.*) Хәзер мин сезгә казлар турында хикәя укыйм. (Тәрбияче хикәяне укый.) Хикәядә нәрсә турында сүз бара? (*Казлар турында.*) (Активлаштыру.) Дөгә-дөгә-дөгә! Килегез тизрәк монда! Балалар, нәрсәне шулай чакыралар? (*Казларны.*) Казларны чакырыгыз әле. (*«Дөгә-дөгә-дөгә!»*) (Активлаштыру.) Балалар, казларның муеннары нинди: кыскамы, озынмы? (*Озын.*) (Активлаштыру.) Казларның тәпиләре нинди төстә? (*Кызыл.*) (Активлаштыру.) Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле:

«кызыл тәпиләр». Бик дөрес, балалар. Балалар, казларның өйгә кайтасылары килгәнме? (*Юк. Кайтасылары килмәгән.*) Әйе, казларның өйләренә кайтасылары килми. Аларга су буенда рәхәт.

(Тәрбияче хикәяне тагын бер тапкыр укып чыга.) Балалар, судан чыккач, казларның яшел чирәм ашыйсы килә. Әйдәгез, аларга чирәм әзерлибез. Менә бу кәгазь битенә чирәм ясыйбыз. Чирәм нинди төстә? (*Яшел.*) Дөрес, яшел чирәм. Барыгыз да яшел карандашлар алыгыз. Карандашларны кулыгызга тотыгыз. Чирәмне өстән аска таба, менә шулай ясыйбыз. Чирәмне күп итеп ясагыз. (Балалар кәгазь битенә күп штрихлар сызалар.) Чирәм барлык казларга да җитсен. Казлар яшел чирәмгә сөенерләр. Булдырдыгыз, балалар! (Кул чабалар.)

## *Унынчы бүлек.* ҖӘЙ

### Тема. Ә. КАРИНЫҢ «ЧЕБИЛӘР» ШИГЫРЕН УКУ

**Бурычлар:**

1) күрсәтмәлелек кулланмыйча, шигъри әсәрне тыңларга өйрәтү, [ч] авазын дөрес әйтергә күнектерү;

2) балаларның уңай эмоцияләрен үстерү;

3) йорт кошларына карата кайгыртучанлык тәрбияләү.

**Җиһазлар:** «Чеп-чеп, чебиләрем» җырының аудиоязмасы, чеби битлекләре.

**Эшчәнлек барышы.**

Тәрбияче. Балалар, хәзер урамда җәй. Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: «Җәй килде». (Активлаштыру.) Җәй турында сез нәрсәләр беләсез? (*Көн җылы. Кояш елмая. Чирәмнәр, үләннәр, чәчәкләр үсә. Чебиләр, каз бәбкәләре чирәм ашыйлар.*) Балалар, мин сезгә бер табышмак әйтәм. Нәрсә турында икән ул?

Йомры йомшак сары йомгак
Йөгереп йөри чирәмдә.

Бу нәрсә? (*Чеби.*) (Активлаштыру.) Хәзер мин сезгә чеби турында шигырь укыйм, игътибар белән тыңлагыз. (Тәрбияче шигырьне укый.) Ни өчен чебиләр черелдәшкәннәр? (*Аларның ашыйсы килгән.*) Чебиләргә кем җим сипкән? (*Гөлфия.*) Гөлфия чебиләргә нәрсә дип эндәшкән? (*«Чеп-чеп!»*) (Активлаштыру.) Ә чебиләр Гөлфиягә нәрсә дигәннәр? (*«Чеп-*

*чеп!»*) (Активлаштыру.) Хәзер, балалар, сез чебиләр булырсыз. (Тәрбияче балаларга чеби битлекләре кидерә һәм «Чеп-чеп, чебиләрем» җырын тыңлата.) Чебиләр җим чүплиләр. Чебиләр нәрсә эшлиләр? (*Чебиләр җим чүплиләр.*) Ничек итеп чүплиләр, күрсәтегез әле. (Тәрбияче балаларга чебиләрнең ничек җим чүпләгәнен күрсәтә.) Нәрсә диләр чебиләр?(*«Чеп-чеп!»*) Чеп-чеп! Килегез монда. (Тәрбияче балаларны чакыра.) Әйдәгез, чебиләрне бергәләп чакырабыз: «Чеп-чеп! Килегез монда!» (Активлаштыру.) Булдырдыгыз, балалар! Гөлфия һәм чебиләр турындагы шигырьне тагын бер кат тыңлагыз әле. (Тәрбияче шигырьне тагын бер тапкыр укый, балаларга кайбер фразаларны әйттерә.) Балалар, рәхмәт сезгә, чебиләр турында бик матур итеп җавап бирдегез. Мине шатландырдыгыз. Булдырдыгыз, балалар! (Кул чабалар.)

## Тема. С. СӨЛӘЙМАНОВАНЫҢ «КЫЗЫЛ ӘТӘЧ» ШИГЫРЕН УКУ

**Бурычлар:**

1) шигъри әсәрне тыңларга өйрәтү, гади сорауларга җавап бирү теләге уяту, аваз ияртемнәрен өйрәтүне дәвам итү;

2) балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын, хәтерен, тәрбияче күрсәтмәләрен үтәү осталыгын үстерү;

3) йорт кошларына карата шәфкатьлелек тәрбияләү.

**Җиһазлар:** мольберт, ишегалдында чирәмдә йөрүче әтәч рәсеме.

### Эшчәнлек барышы.

Тәрбияче. Балалар, елның кайсы вакыты? (*Җәй.*) (Активлаштыру.) Балалар, җәй көне йорт кошлары авылда ишегалдында чирәм ашыйлар, җим чүплиләр. Сез нинди йорт кошларын беләсез? (*Каз, үрдәк, тавык, әтәч.*) (Активлаштыру. Мольбертта әтәч рәсеме эленеп тора. Тәрбияче балаларның игътибарын әтәчкә юнәлтә.) Бу рәсемдәге әтәч тә, җәй килгәнгә шатланып, ишегалдында йөри. Әтәч зур, матур. Әтәчнең кызыл тәпиләре, кызыл кикриге бар. Койрыгы бигрәк матур! Әтәчнең койрыгында кызыл, яшел, сары каурыйлары бар. Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз әле: «Әтәчнең койрыгында кызыл, яшел, сары каурыйлары бар». Балалар, әтәч ничек кычкыра? (*«Кикрикү-үк!»*) (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) Балалар, әтәч сезгә шигырь укуымны тели. Тыңлагыз әле. (Тәрбияче шигырь укый.) (Икенче тапкыр укыгач, сораулар бирә.) Нәрсә иртүк торган?(*Әтәч.*) Әтәч ничек кычкыра? (*Кикрикү-үк!»*) Әтәч кайчан торган? (*Иртән.*) Әйе, балалар, әтәч, иртүк торып, балаларны, әниләрне, эти-

ләрне, кешеләрне уята. Эшкә чакыра. Әтәч торгач, балалар да бакчага килә.

(Өченче тапкыр шигырьне укыганда, тәрбияче балаларга кайбер сүзләрне (*иртүк, кикрикүк, күп*) әйтергә куша.) Хәзер уйнап алабыз. Кулыгызны алга куегыз, имән бармак баш бармакка терәлә, бүтән бармаклар аерылган һәм өскә күтәрелгән.

Нинди матур бу әтәч!
Кычкыра ул, таң аткач.
Кикрикүк! Кикрикүк!

Балалар, сез әтәчне яратасызмы? Әйе, әтәчне яратырга кирәк. Әтәчкә зыян китерергә ярамый. Булдырдыгыз, балалар! Әйдәгез, үзебезне мактап кул чабыйк әле! (Бергәләп кул чабалар.)

## Тема. Д. ГАРИФУЛЛИННЫҢ «МЫРАУБИКӘ» ШИГЫРЕН УКУ

**Бурычлар:**

1) шигырь ярдәмендә песи белән таныштыруны дәвам итү, песи турында мәгълүматларны ныгыту һәм киңәйтү; *мыр-мыр, гыр-гыр* аваз ияртемнәрен өйрәтү;

2) сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;

3) песиләргә карата кайгыртучанлык тәрбияләү.

**Җиһазлар:** уенчык песи.

### Эшчәнлек барышы.

Тәрбияче. Балалар, карагыз әле, безгә кунак килгән. Нәрсә ул? (*Песи.*) Алсу, бу нәрсә? Марат, бу нәрсә? Әйе, бу — песи, пескәй. Балалар, карагыз әле, песи нинди? (Балалар тәрбияче белән бергә песине карыйлар.) Нинди матур, йомшак, йонлач песи. (Тәрбияче балаларга песине тотып карарга, сыйпарга куша, песинең тәпиләре белән балаларга тиеп ала.) Карагыз әле, песинең нинди матур койрыгы бар. Алмаз, песинең койрыгын күрсәт әле. (Тәрбияче песинең койрыгы белән балаларның битен кытыклый.) Менә бу — песинең койрыгы! (Хәрәкәтләр берничә тапкыр кабатлана.) Нинди матур песи! Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз әле: «Нинди матур песи!» (Балалар кабатлыйлар.) Балалар, кунак килгәч, аны сыйлыйлар. Песи нәрсә ярата? (*Сөт, балык, ит* һ.б.) Әйдәгез, песигә сөт бирәбез. Сөтне тәлинкәгә салабыз. (Тәрбияче тәлинкәгә сөт сала.) Песи, сөт эч! Әйдәгез, бергәләп әйтик әле: «Песи, сөт эч!» Песи нишли? (*Сөт эчә.*) Булдырдыгыз, балалар! Ә хәзер

песи турында шигырь тыңлагыз. Песи дә тыңласын. (Песине утыртып куя.)

Мыраубикә кызык та соң:
«Мыр-мыр-мыр» итә-итә,
Әбиемнең итәгендә
«Гыр-гыр-гыр» йоклап китә.

Балалар, песинең кушаматы ничек? (*Мыраубикә.*) Ул нинди тавыш чыгара? (*«Мыр-мыр-мыр».*) Йоклаганда нинди тавыш чыгара? (*«Гыр-гыр-гыр».*) Балалар, кулларыгыз песи булсын. Бер кул белән икенче кул аркасын «Песием-песием, прес!» дип, «песи» итеп уйнагыз. Хәзер песи ял итә. Ул да шигырь тыңлый.

Шигырь икенче кат укыла. Икенче кат укыганда, тәрбияче балаларга аерым фразаларны кабатларга куша.

Балалар, әйдәгез, кулларыгыз тагын «песи» булсын. «Песи»не яратып сыйпагыз. Песи сыйпаганны бик ярата. Яратсаң, шатланып, песи мияулый башлый. Ничек мияулый? (*«Мияу-мияу!»*) Менә шулай! Песиләрне яратыгыз, рәнҗетмәгез!

# БЕРЕНЧЕ КЕЧЕ ЯШЬТӘГЕЛӘР ТӨРКЕМЕНДӘ БАЛАЛАРНЫҢ СӨЙЛӘМ ТЕЛЕН ҮЗЛӘШТЕРҮ ДӘРӘҖӘСЕНӘ ДИАГНОСТИКА

## ДИАГНОСТИК БИРЕМНӘР (5—14 НОЯБРЬ)

### 1. БАЛАЛАРНЫҢ СҮЗ БАЙЛЫГЫ

**1. «Бу нәрсә?» дидактик уены**

**Материал:** уенчыклар, җиләк-җимеш, яшелчәләр сурәтләнгән предметлы рәсемнәр.

***Диагностик биремнең эчтәлеге***

Тәрбияче балага уенчык (машина, курчак, туп) рәсемнәре күрсәтә һәм аларның нәрсә икәнлеген әйтергә куша. Аннары предметларның өлешләрен күрсәтергә тәкъдим итә. Мәсәлән: «Машинаның кабинасын күрсәт. Кузовын күрсәт. Тәгәрмәчләрен күрсәт».

Тәрбияче балага җиләк-җимешләр (алма, груша, слива) рәсемнәре күрсәтә һәм аларның нәрсә икәнлеген әйтергә куша: «Бу нәрсә?» Балалардан җиләк-җимешләрнең төсләрен (кызыл, яшел, сары) сорый.

Тәрбияче балага яшелчәләр (кишер, кыяр, помидор) рәсемнәре күрсәтә һәм аларның нәрсә икәнлеген әйтергә куша: «Бу нәрсә?» Аннары яшелчәләрнең төсләрен сорый.

**2. «Син кем?» дидактик күнегүе**

***Диагностик биремнең эчтәлеге***

Тәрбияче баланы үзе янына чакыра, аңа сораулар бирә: «Синең исемең ничек?» «Ә минем исемем ничек?» «Ул — кыз, ә син кем?» «Башыңны күрсәт әле. Кая синең борының (күзләрең, колакларың, кулларың, аякларың)?»

**Бәяләү критерийлары**

Бала, предметларның исемен атаганда, төсләрен билгеләгәндә, хаталар җибәрә. Тәрбияченең сорауларына җавап бирә алмый — **1 балл;**

бала предметларның исемен дөрес атый, төсләрен билгеләгәндә, хаталар җибәрә. Тәрбияченең сорауларына өстәмә сораулар ярдәмендә генә җавап бирә — **2 балл;**

бала предметларның исемен дөрес атый, төсләрне дөрес билгели. Тәрбияченең сорауларына теләп, ышанычлы итеп җавап бирә — **3 балл.**

## 2. СӨЙЛӘМНЕҢ ГРАММАТИК ЯГЫ

**1. «Кем нәрсә эшли?» дидактик уены**

**Материал:** табибә, шофёр, сатучы сурәтләнгән сюжетлы рәсемнәр.

***Диагностик биремнең эчтәлеге***

Тәрбияче балага табибә төшерелгән сюжетлы рәсем күрсәтә һәм сораулар бирә: «Бу кем?» (*Табибә.*) «Ул нәрсә эшли?» (*Тыңлый.*) «Ул кемне дәвалый?» (*Малайны дәвалый.*)

Тәрбияче балага шофёр төшерелгән сюжетлы рәсем күрсәтә һәм сораулар бирә: «Бу кем?» (*Шофёр.*) «Шофёр кайда утыра?» (*Кабинада утыра.*) «Ул нишли?» (*Машина йөртә.*)

Тәрбияче балага сатучы төшерелгән сюжетлы рәсем күрсәтә һәм сораулар бирә: «Бу кем?» (*Сатучы.*) «Сатучы кайда эшли?» (*Кибеттә.*) «Ул нәрсә эшли?» (*Ул әйбер сата.*)

**Бәяләү критерийлары**

Бала биремнәрне үти алмый. Тәрбияченең сорауларына җавап бирә алмый. Тәрбияче актив ярдәм күрсәткәндә дә, хаталар ясый — **1 балл;**

бала биремнәрне үтәргә тырыша, тәрбияченең сорауларына бер сүз белән генә җавап бирә — **2 балл;**

бала биремнәрне дөрес үти. Тәрбияченең сорауларына җавап биргәндә, исем белән фигыльне, алмашлык белән фигыльне яраклаштыра ала. Тәрбияченең сорауларына теләп, ышанычлы итеп җавап бирә — **3 балл.**

## 3. АВАЗ КУЛЬТУРАСЫ

**1. «Бу нәрсә? Ул ничек кычкыра?» дидактик уены**

**Материал:** песи, эт, әтәч, сыер, күгәрчен, чыпчык рәсемнәре.

***Диагностик биремнең эчтәлеге***

Тәрбияче балага песи (эт, әтәч, сыер, күгәрчен, чыпчык) рәсемнәре күрсәтә һәм сораулар бирә: «Бу нәрсә?» (*Эт.*) «Эт ничек өрә?» (*«Һау-һау!»*) «Бу нәрсә?» (*Песи.*) «Песи ничек

кычкыра?» (*«Мияу-мияу!»*) «Бу нәрсә?» (*Әтәч.*) «Әтәч ничек кычкыра?» (*«Кикрикү-үк!»*) «Бу нәрсә?» (*Сыер.*) «Сыер ничек мөгри?» (*«Му-у!»*) «Бу нәрсә?» (*«Күгәрчен.*) «Күгәрчен ничек гөрли?» (*«Гөр-гөр!»*) «Бу нәрсә?» (*Чыпчык.*) «Чыпчык ничек чыркылдый?» (*«Чырык-чырык!»*)

**Бәяләү критерийлары**

Бала 1—2 биремне генә үти ала — **1 балл;**

бала биремнәрне тәрбияче ярдәме белән башкара, аның артыннан кабатлый — **2 балл;**

бала биремнәрне теләп башкара, аваз иyртемнәрен дөрес һәм ачык итеп әйтә — **3 балл.**

### 4. БӘЙЛӘНЕШЛЕ СӨЙЛӘМ

**1. Сюжетлы рәсем буенча әңгәмә**

**Материал:** уйнаучы балалар сурәтләнгән сюжетлы рәсем.

***Диагностик биремнең эчтәлеге***

Тәрбияче балаларның игътибарын рәсемгә юнәлтә һәм сораулар бирә: «Карагыз әле, Йомшаккай бик матур бер рәсем ясаган. Бу рәсемдә кем ясалган? Балалар нәрсә эшлиләр? Рәсем сиңа ошыймы?»

**Бәяләү критерийлары**

Бала сорауларга ишарәләр яки бер сүз белән генә җавап бирә — **1 балл;**

бала, җавап биргәндә, 2—3 сүздән торган гади җөмләләргә өстенлек бирә — **2 балл;**

бала гади (кем? нәрсә?) һәм катлаулы (кемгә? нинди? кайчан? кайда? кая?) сорауларга җавап бирә. Үз инициативасы белән яки тәрбияче кушуы буенча, рәсемдә сурәтләнгәнне сөйли ала — **3 балл.**

10—12 балл: **югары дәрәҗә**

6—9 балл: **уртача дәрәҗә**

3—5 балл: **түбән дәрәҗә**

## ДИАГНОСТИК БИРЕМНӘР (21—31 МАРТ)

### 1. БАЛАНЫҢ СҮЗ БАЙЛЫГЫ

**1. «Бу нәрсә?» дидактик уены**

**Материал:** савыт-саба, йорт җиһазлары, йорт хайваннары, кыргый хайваннар, киемнәр сурәтләнгән рәсемнәр.

***Диагностик биремнең эчтәлеге***

Тәрбияче балага савыт-саба (тәлинкә, чынаяк, чәй тәлинкәсе, табак) сурәтләнгән рәсемнәр күрсәтә һәм андагы предметларны атарга куша: «Бу нәрсә?» «Бу предметлар бер сүз белән ничек атала?» (*Савыт-саба.*)

Тәрбияче балага йорт җиһазлары (караватт, өстәл, урындык, шкаф) сурәтләнгән рәсемнәр күрсәтә һәм андагы предметларны атарга куша: «Бу нәрсә?» «Бу предметлар бер сүз белән ничек атала?» (*Йорт җиһазлары.*)

Тәрбияче балага йорт хайваннары (эт, песи, сыер, кәҗә) сурәтләнгән рәсемнәр күрсәтә һәм андагы предметларны атарга куша: «Бу нәрсә?» «Бу хайваннар бер сүз белән ничек атала?» (*Йорт хайваннары.*)

Тәрбияче балага кыргый хайваннар (куян, төлке, аю) сурәтләнгән рәсемнәр күрсәтә һәм андагы хайваннарны атарга куша: «Бу нәрсә?» «Бу хайваннар бер сүз белән ничек атала?» (*Кыргый хайваннар.*)

Тәрбияче балага киемнәр (күлмәк, куртка, башлык) сурәтләнгән рәсемнәр күрсәтә һәм предметларны атарга куша: «Бу нәрсә?» «Бу предметлар бер сүз белән ничек атала?» (*Киемнәр.*)

**Бәяләү критерийлары**

Бала, предметларның исемен атаганда, авырлыклар кичерә, гомумиләштерүче сүзләрне куллана белми — **1 балл;**

предметларның исемен дөрес атый, гомумиләштерүче сүзләрне белдергәндә, хаталар җибәрә — **2 балл;**

предметларның исемен дөрес атый, гомумиләштерүче сүзләрне дөрес билгели — **3 балл.**

## 2. СӨЙЛӘМНЕҢ ГРАММАТИК ЯГЫ

**1. «Кем нәрсә эшли?» дидактик уены**

**Материал:** китап укучы әни, өреп торган эт, уйный торган малай, рәсем ясаучы кыз сурәтләнгән рәсемнәр.

***Диагностик биремнең эчтәлеге***

Тәрбияче балага китап укучы әни төшерелгән рәсем күрсәтә һәм сораулар бирә: «Бу кем?» (*Әни.*) «Әни нәрсә эшли?» (*Укый.*) «Әни нәрсә укый?» (*Әни китап укый.*)

Тәрбияче балага өреп торган эт төшерелгән сюжетлы рәсем күрсәтә һәм сораулар бирә: «Бу нәрсә?» (*Эт.*) «Эт нәрсә эшли?» (*Эт өрә.*) «Ул ничек өрә?» (*Эт «һау-һау» дип өрә.*)

Тәрбияче балага уйный торган малай төшерелгән рәсем күрсәтә һәм сораулар бирә: «Бу кем?» (*Малай.*) «Малайның исеме ничек?» (Бала малайга исем биреп карый.) «Малай нишли?» (*Малай уйный.*) «Ул нәрсә белән уйный?» (*Ул машина белән уйный.*)

Тәрбияче балага рәсем ясаучы кыз төшерелгән рәсем күрсәтә һәм сораулар бирә: «Бу кем?» (*Кыз.*) «Кызның исеме ничек?» (Бала кызга исем бирә.) «Кыз нәрсә эшли?» (*Кыз рәсем ясый.*) «Ул нәрсә белән рәсем ясый?» (*Ул карандаш белән рәсем ясый.*) «Кыз нәрсә рәсеме ясый?» (*Кыз кояш рәсеме ясый.*)

### Бәяләү критерийлары

Бала биремнәрне үти алмый. Тәрбиячедән сорауларына җавап бирә алмый. Тәрбияче актив ярдәм күрсәткәндә дә, бала хаталар ясый — **1 балл;**

бала биремнәрне үтәргә тырыша, тәрбиячедән сорауларына бер сүз белән генә җавап бирә — **2 балл;**

бала биремнәрне дөрес үти. Тәрбиячедән сорауларына җавап биргәндә, җөмләләрне грамматик яктан дөрес төзи. Җөмләләрнең иясе һәм хәбәре бар. Тәрбиячедән сорауларына теләп, ышанычлы итеп җавап бирә — **3 балл.**

## 3. АВАЗ КУЛЬТУРАСЫ

**1. «Бу нәрсә? Ул ничек кычкыра?» дидактик уены**

**Материал:** ат, кәҗә, тавык, каз, карга рәсемнәре.

***Диагностик биремнең эчтәлеге***

Тәрбияче балага ат (кәҗә, тавык, каз, карга) рәсеме күрсәтә һәм сораулар бирә: «Бу нәрсә?» (*Ат.*) «Ат ничек кешни?» (*«Ми-һа-һай!»*) «Бу нәрсә?» (*Кәҗә.*) «Кәҗә ничек кычкыра?» (*«Ми-ки-ки!»*) «Бу нәрсә?» (*Тавык.*) Тавык ничек кыткылдый? (*«Кыт-кытыйк!»*) «Бу нәрсә?» (*Каз.*) «Каз ничек каңгылдый?» (*«Ка-ка-ка!»*) «Бу нәрсә?» (*Карга.*) «Карга ничек каркылдый?» (*«Кар-кар!»*)

### Бәяләү критерийлары

Бала 1—2 биремне генә үти ала — **1 балл;**

бала биремнәрне тәрбияче ярдәме белән башкара, аның артыннан кабатлый — **2 балл;**

бала биремнәрне теләп башкара. Аваз иялтемнәрен дөрес һәм ачык итеп әйтә — **3 балл.**

## 4. БӘЙЛӘНЕШЛЕ СӨЙЛӘМ

**1. Сюжетлы рәсем буенча әңгәмә**

**Материал:** кар бабай ясаучы балалар сурәтләнгән сюжетлы рәсем.

***Диагностик биремнең эчтәлеге***

Тәрбияче балаларның игътибарын рәсемгә җәлеп итә һәм сораулар бирә: «Карагыз әле, Йомшаккай бик матур бер рәсем ясаган. Бу рәсемдә кемнәр ясалган? Балалар нәрсә эшлиләр? Рәсем сиңа ошыймы?»

**2. «Йомры Икмәк» әкиятен сәхнәләштерү**

Тәрбияче өстәл театры фигуралары куллана, балаларны сәхнәләштерүдә катнашырга чакыра.

**Бәяләү критерийлары**

Бала сорауларга ишарәләр яки бер сүз белән генә җавап бирә. Әкиятне сәхнәләштерүдә авырлыклар кичерә. Тәрбияче артыннан аерым сүзләрне генә кабатлый — **1 балл;**

мәсәлән:

Тәрбияче. Балалар, әби белән бабай пешергәннәр ...

Бала. Йомры Икмәк.

Тәрбияче. Йомры Икмәкне тәрәзә төбенә ...

Бала. Куйганнар.

Тәрбияче. Камыр кипкәч, тәрәзәдән ...

Бала. Сикереп төшә.

Тәрбияче. Йомры Икмәк йөгереп китә, йөгерә-йөгерә, урманга ...

Бала. Җитә.

Бала, җавап биргәндә, 2—3 сүздән торган гади җөмләләргә өстенлек бирә. Тәрбияче ярдәм иткәндә, таныш әкиятне сәхнәләштерүдә катнаша — **2 балл;**

мәсәлән:

Тәрбияче. Балалар, әби белән бабай ...

Бала. Йомры Икмәк пешергәннәр.

Тәрбияче. Йомры Икмәкне ...

Бала. Тәрәзә төбенә куйганнар.

Тәрбияче. Камыр кипкәч, ...

Бала. Тәрәзәдән сикереп төшә.

Тәрбияче. Йомры Икмәк йөгереп китә, йөгерә-йөгерә, ...

Бала. Урманга җитә.

Бала гади (кем? нәрсә?) һәм катлаулы (кемгә? нинди? кайчан? кайда? кая?) сорауларга җавап бирә. Үз инициативасы

яки тәрбияче үтенече буенча, рәсемдә сурәтләнгәнне сөйли ала. Әкиятнең эчтәлеген сөйләгәндә, эзлеклелекне саклап, сәхнәләштерүдә теләп катнаша — **3 балл.**

10—12 балл: **югары дәрәҗә**

6—9 балл: **уртача дәрәҗә**

3—5 балл: **түбән дәрәҗә**

**Туган телгә өйрәтү һәм сөйләм үстерү буенча баланың персональ картасы**

| Баланың исеме, фамилиясе | Сүз байлыгы | Сөйләмнең грамматик ягы | Аваз культурасы | Бәйләнешле сөйләм | Гомуми үсеш дәрәҗәсе | Индивидуаль эш өчен тәкъдимнәр |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

# КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

1. *Алексеева М. М.* Методика развития речи и обучения родному языку дошкольников / М. М. Алексеева, В. И. Яшина. — М.: 2000. — 400 с.

2. *Алексеева М. М.* Речевое развитие дошкольников / М. М. Алексеева, В. И. Яшина. — М., 1998.

3. *Алешина Н. В.* Ознакомление дошкольников с окружающим и социальной действительностью. Младшая группа : конспект занятий / Н. В. Алешина. — Изд. 4-е. — М.: УЦ ПЕРСПЕКТИВА, 2008. — 96 с.

4. *Арушанова А. Г.* Речь и речевое общение детей : развитие диалогического общения : методическое пособие для воспитателей.— 2-е изд., испр. и доп. / А. Г. Арушанова.— М.: Мозаика-Синтез, 2005. — 128 с.

5. Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программасы / төз.: К. В. Закирова, Р. А. Борһанова. — Казан : Хәтер, 2000.

6. *Бородич А. М.* Развитие речи дошкольников. — М., 1969.

7. *Вагыйзов С. Г.* Башлангыч мәктәптә татар телен укыту методикасы / С. Г. Вагыйзов, Р. Г. Вәлитова. — Казан : Мәгариф, 2001.

8. *Венгер Л. А.* Восприятие и обучение. — М., 1969.

9. *Винникова Г. И.* Занятия с детьми 2—3 лет : развитие речи, художественная литература, изобразительная деятельность. — М.: ТЦ Сфера, 2009. — 128 с.

10. *Виноградова Н. Ф.* Умственное воспитание детей в процессе ознакомления с природой. — М., 1982.

11. *Выготский Л. С.* Сочинения.— Т. II: Мышление и речь. — М., 1973.

12. *Гвоздев А. Н.* Вопросы изучения детской речи. — М., 1961.

13. *Гербова В. В.* Занятия по развитию речи в первой младшей группе детского сада : планы занятий.— 2-е изд., испр. и доп.— М.: Мозаика-Синтез, 2008. — 112 с.

14. *Гербова В. В.* Развитие речи в детском саду : программа и методические рекомендации. — М.: Мозаика-Синтез, 2006. — 56 с.

15. Гөлбакча : балалар бакчалары өчен хрестоматия : балалар бакчаларында эшләүче тәрбиячеләр өчен кулланма. — Казан : Татар. кит. нәшр., 1990.

16. Гөлбостан : балалар бакчасында телләр үстерү өчен методик кулланма / Ф. Г. Агнабаева, Г. Р. Елкыбаева, А. З. Нарынбаева, М. Р. Харисова, Р. И. Әминева. — Өфе : Китап, 2010. — 416 б.

17. *Давыдов В. В.* Проблемы развивающего обучения. — М., 1988.

18. *Зубарева Н. М.* Дети и изобразительное искусство. — М., 1968.

19. Игры с детьми раннего возраста : методические рекомендации / сост. М. А. Аралова. — М.: ТЦ Сфера, 2008. — 128 с.

20. *Козлова С. А.* Дошкольная педагогика / С. А. Козлова, Т. А. Куликова. — М., 2005.

21. *Короткова Э. П.* Обучение рассказыванию в детском саду. — М., 1982.

22. Кроха : метод. рекомендации к программе воспитания и развития детей раннего возраста в условиях дошкольных учреждений / Г. Г. Григорьева, Н. П. Кочетова, Д. В. Сергеева и др. — М.: Просвещение, 2007. — 207 с.

23. *Лифиц Е. А.* Развитие речи, движения и мелкой моторики. Комплексные занятия : практическое пособие. — М.: Айрис-пресс, 2010. — 160 с.

24. *Лурия А. Р.* Речь и мышление. — М., 1976.

25. *Люблинская А. А.* Воспитателю о развитии ребёнка. — М., 1972.

26. *Мелик-Пашаев А.* Общение и речь : развитие речи у детей в общении со взрослыми / А. Мелик-Пашаев, З. Новлянская. — М., 1985.

27. Методические рекомендации к «Программе воспитания и обучения в детском саду» / сост. Л. В. Русскова. — М., 1986.

28. *Мөбарәкшина Р. М.* Балалар бакчасында җырлар, уеннар: методик кулланма / Р. М. Мөбарәкшина, В. К. Вәлиева. — Яр Чаллы, 1997. — 68 б.

29. *Мөбарәкшина Р. М.* Беренче кечкенәләр төркемендә музыкаль-эстетик тәрбия : методик кулланма / Р. М. Мөбарәкшина, В. К. Вәлиева. — Яр Чаллы, 2004. — 55 б.

30. *Мухина В. С.* Детская психология. — М., 1985.

31. *Немов Р. С.* Психология. — М., 1995.

32. От рождения до школы : примерная основная общеобразовательная программа дошкольного образования / под ред. Н. Е. Ве-

раксы, Т. С. Комаровой, М. А. Васильевой. — М.: Мозаика-Синтез, 2010. — 304 с.

33. *Петрова В. А.* Методика занятий по развитию речи с детьми второго и третьего года жизни . — М.: Просвещение, 1965. — 138 с.

34. *Пиаже Ж.* Речь и мышление ребёнка. — М., 1978.

35. *Поддьяков Н. Н.* Мышление дошкольника. — М., 1977.

36. Развитие речи дошкольников / под ред. Ф. А. Сохина. — М., 1984.

37. Раушан көзге : татар балалар әдәбиятыннан хрестоматия: педагогия училищеларының мәктәпкәчә яшьтәге балаларны тәрбияләү бүлеге өчен кулланма. — Казан : Мәгариф, 1993. — 255 б.

38. *Родари Дж.* Грамматика фантазии. Введение в искусство придумывания историй.— М., 1978.

39. *Рубинштейн С. Л.* К психологии речи// Проблемы общей психологии. — М., 1973.

40. *Рубинштейн С. Л.* Сочинения. — Т. I : Основы общей психологии. — М., 1989.

41. *Смирнова Е. А.* Использование наглядности в формировании повествовательной речи дошкольников / Е. А. Смирнова, О. С. Ушакова // Развитие речи детей и обучение языку : тезисы выступлений на научном совещании. — М., 1989.

42. Содержание и методы умственного воспитания дошкольников / под ред. Н. Н. Поддьякова. — М., 1980.

43. *Стародубова Н. А.* Теория и методика развития речи дошкольников. — М.: Изд. центр «Академия», 2006. — 256 с.

44. *Сухомлинский В. А.* Йөрәгемне балаларга бирәм. — Казан : Татар. кит. нәшр., 1976.

45. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. — Казан : «Матбугат йорты» нәшр., 2005. — 848 б.

46. *Тихеева Е. И.* Развитие речи детей (раннего и дошкольного возраста). — М., 1981.

47. *Тумакова Г. А.* Ознакомление дошкольника со звучащим словом. — М., 1981. — 128 с.

48. *Ушакова О. С.* Методика развития речи детей дошкольного возраста : учеб.-метод. пособие для воспитателей ДОУ / О. С. Ушакова, Е. М. Струнина. — М.: ГИЦ ВЛАДОС, 2003.— 288 с.

49. *Ушинский К. Д.* Сочинения. — Т. II: Родное слово.— М.; Л., 1948.

50. *Федоренко Л. П.* Методика развития речи детей дошкольного возраста. — М., 1984. — 240 с.

51. *Флёрина Е. А.* Эстетическое воспитание в детском саду. — М., 1961.

52. *Фонарёв А. М.* Развитие ориентировочных реакций у детей. — М., 1977.

53. *Чуковский К. И.* От двух до пяти. — М., 1966.

54. *Шанский Н. М.* Лексикология современного русского языка. — М., 1972.

55. *Шәрәфетдинова З. Г.* Хәзерге татар телендә ияртемнәр : монография. — Казан : «Дом печати» нәшр., 2007. — 208 б.

56. *Эльконин Д. Б.* Развитие речи детей. — М., 1958.

## ЭЧТӘЛЕК

*Аңлатма язуы* ............ 3

Эшчәнлекнең тематик планы ............ 7

Эшчәнлекне оештыруның кыскача эчтәлеге ............ 10

Эшчәнлекне оештыру ............ 32

Танып белү эшчәнлеге ............ 32

Сөйләм үстерү ............ 96

Матур әдәбият белән таныштыру ............ 142

Беренче кече яшьтәгеләр төркемендә балаларның сөйләм телен үзләштерү дәрәҗәсенә диагностика ............ 180

Кулланылган әдәбият исемлеге ............ 187

Учебное издание

**Хазратова** Фируза Вакиловна
**Шарафутдинова** Земфира Габдрахмановна
**Хабибуллина** Ильсияр Зиганшовна

**ГОВОРИМ НА РОДНОМ ЯЗЫКЕ**

**Воспитание и обучение в детском саду**

(*первая младшая группа*)

Методическое пособие для воспитателей

Казань. Татарское книжное издательство. 2012

На татарском языке

Уку-укыту басмасы

**Хәзрәтова** Фирүзә Вәкил кызы
**Шәрәфетдинова** Земфира Габдрахман кызы
**Хәбибуллина** Илсөяр Җиһанша кызы

**ТУГАН ТЕЛДӘ СӨЙЛӘШӘБЕЗ**

**Балалар бакчасында татар телендә тәрбия һәм белем бирү**

*(беренче кече яшьтәгеләр төркеме)*

Тәрбиячеләр өчен методик кулланма

Мөхәррирләре *В. Г. Гомәрова, Л. Р. Гатауллина*
Тышлык рәссамы *М. Д. Вәҗиева*
Бизәлеш мөхәррире *Р. Х. Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда
биткә салучысы *М. И. Данилевская*
Корректорлары *Г. Г. Мөхәммәтҗанова, А. М. Закирова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 28.08.2012. Форматы $60\times90^{1}/_{16}$.
Шартлы басма табагы 12,0. Тиражы 3000 д. Заказ

«Татарстан китап нәшрияты» ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс: (843) 519-45-22.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

ООО «Фолиант» типографиясендә басылды.
420111. Казан, Профсоюзная урамы, 17в.
Тел./факс (843) 292-27-25.